Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

02

февраль 2020

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Истанбул хатирәләре

16 нчы бит

Балдаклы хыянәт

66 нчы бит

Ул – халык Илһамы!

Илһам Шакировның тууына 85 ел

Архивы барның киләчәге бар

17 гыйнварда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Федераль архив агентлыгы җитәкчесе Андрей Юрасов Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты коллегиясенең киңәйтелгән утырышында катнашты. «Хәзерге заманда Татарстан Республикасы Архив фондын формалаштыру» дип аталган әлеге утырышта төп доклад белән ТРның Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе Гөлнара Габдрахманова чыгыш ясады.

ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үтү кысаларында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт архивы 1920 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр республика җитәкчеләре турында электрон китап әзерләгән. Хәзер архивларда 7 миллион 800 берәмлектән артык эш саклана, ел саен саклауга 129 мең эш алына.

Фотолар tatarstan.ru сайтыннан алынды

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

02 (314)

февраль 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

102

39 **ҺАВАЛАРДА ОЧА ИКЕ АККОШ...**

Фәйзелхак Ислаев

87 **ХАЛКЫ ӨЧЕН БИРЕП БАР КӨЧЕН.**

Фарук Нәфиев

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Сәгыйть Рәмиев**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Этрусклар – Рим остазлары.** *С.Шәмси*
9 **Гөләйза кыйссасы.** *Г.Хисамиев*
16 **Истанбул хатирәләре.** *М.Рәхмәт Паташева*
25 **«Тәтеш оешмасы» газетасы.** *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
30 **Мирхәйдәр Фәйзи: «Уразалар мөкатдәс миңа!»**
39 **Һаваларда оча ике аккош...** *Ф.Ислаев*

ТАТАР ГАМЕ

46 **Буыннардан күчкән якты мирас.** *Г.Гатауллина*
48 **Музыка белән язылган язмышлар.** *М.Гәрәев*

ДИНИ МИРАС

52 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

58 **Мөһаҗирлектәге татар китабы.** *Х.Миңнегулов*
66 **Балдаклы хыянәт.** *Хәйдәр*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

72 **Мәшһүрләребез: Бакый Урманче һәм Нури Арслан**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

74 **Халкыбыз Илһамы.** *Г.Рәхим*
83 **Беренче укытучыларым.** *И.Таһиров*
87 **Халкы өчен биреп бар көчен.** *Ф.Нәфиев*
94 **Әти.** *Ә.Шакиров*
100 **Истә, һаман да истә!**
102 **Милли музейда – ПО-2 самолеты**

СӘНГАТИ МИРАС

104 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
108 **Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында.** *З.Гыйльметдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

110 **Манкорт.** *Р.Сәфәров*
113 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ШАЯН МИРАС

114 **Көлке куа килә...**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия
Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-120. Тираж – 1300 данә. Формат 70х108 $^{1}/_{16}$.
Басарга кул куелды: 24.01.2020.
Чыгу көне: 30.01.2020.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Бу сан «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, А Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров.

Сәгыйть Рәмиевнең тууына 140 ел

Сәгыйть Рәмиев

(24.02.1880-17.03.1926)

Алла

Кем ул – белмим вә нәрсәдер
Белим, дип, юл да эзләнмим.
Мәгәр аннан бүтән затка
Җегенмим мин вә тезләнмим.

Олуг, дим, мин аны һәм Ул
Мине аңлар вә ишетер, дим,
Ни сөйлим йә ни уйлыйм, Ул
Йолыр, онтыр вә кичерер, дим.

Була үпкәм аңа бәгъзан,
Дунәм хәтта, җитәм чиккә,
Тәмам иркә, очынган бер
Бала төсле китәм читкә.

Ләкин күңлем аны һәр дәм
Үз иткән, ул даим бергә.
Газап чикмәс җаным бер дә,
Мәгәр чиксә чигәр бергә.

Мөкатдәсмен[1], әминмен[2] бар
Көфердән, бар гөнаһлардан,
Аяк баскан җирем барсы
Гөлстан бер, җинанлардан[3].

Кем ул андый, сәгыйд[4] иткән
Мине һәм урнымы, белмим,
Беләм тик: бу җаным аннан
Яратылган, мин –Ул, Ул – мин. ■

[1] Мөкатдәс – изге, бөек.
[2] Әмин – имин, ышанычлы.
[3] Җинан – җәннәтләр, җәннәт шикелле пакь урыннар мәгънәсендә.
[4] Сәгыйд – бәхетле.

ЭТРУСКЛАР – РИМ ОСТАЗЛАРЫ*

Солтан Шәмси

Сәясәттә дуслар юк, мәнфәгатьләр генә бар, диләр. Корсика утравындагы колония Алалия янындагы сугыштан соң күпмедер вакыт үткәч, б.э.к. VI гасырның ахырында – V гасырның башында Урта диңгездә үз мәнфәгатьләрен кайгырткан Карфаген белән Этрурия һәм яр буйларын сырып алган грек колонияләре арасында каршылыклар килеп чыга. Эш шунда ки, Италия белән Сицилия арасындагы Мессина бугазы диңгез сәүдәсе алып бару өчен әһәмиятле роль уйный. Ул сәүдә юлын кыскарта. Аның аша үтсәң, зур Сицилия утравын көньяктан әйләнеп узарга туры килми, ачык диңгездә пиратларга юлыгу ихтималы да бермә-бер кими. Әмма көтмәгәндә барлыкка килгән вазгыять этрускларның мәнфәгатьләренә бик нык суга. Эш нәрсәдә соң? Моның сәбәпләрен аңлату өчен, А.И.Немировский китабыннан бер өзек китерәбез, чөнки ул конфликтны кыска һәм аңлаешлы итеп тасвирлап биргән: «Бу конфликтның характерын аңлау өчен, борынгы Халкида (Борынгы Грециядәге Эвбея утравының башкаласы. – С.Ш.) колониясе булган Регий тарихына мөрәҗәгать итәргә туры килә. Б.э.к. 494 еллар тирәсендә чыгышы белән Мессинадан булган Анаксилай Регий каласында тирания урнаштыра. Антик чорның барлык тираннары кебек үк, ул актив тышкы сәясәт алып бара һәм тар диңгез бугазының ике ягында үз дәүләтен төземәкче була. Б.э.к. 480 еллар тирәсендә ул Регий каласы каршында, Сицилия утравында урнашкан Занкле шәһәрен басып ала һәм аңа Мессина исеме куша.

Стробон (грек тарихчысы һәм географы. – *С.Ш.*) хезмәтендә сакланып калган хәбәргә караганда, Анаксилай Мессина бугазының иң тар җирендәге Скиллей борынында, тиррен (этруск) пиратлары белән көрәшү өчен, ныгытма төзи» (Нем., 155).

Бу хәл этруск диңгезчеләре өчен Мессина бугазының тулысынча бикләнеп куелуына китерә. Алар хәзер, Греция яки Эгей диңгезе бассейнындагы күп шәһәрләр һәм утрауларда яшәүчеләр белән сәүдә итү өчен, Сицилия утравын көньяктан әйләнеп узарга, озын һәм хәтәр юл үтәргә тиеш булалар. Тиран Анаксилай шулай ук б.э.к. 510 елда «Италия итеге»нең табан астында урнашкан Фурия (икенче исеме Сибарис) колониясен дә тар-мар итә. Ә бит этрусклар грек колонияләре урнашкан, «Бөек Греция» исемен алган Таррент култыгына кереп тә сәүдә итә алган булырлар иде.

Шулай итеп, Мессина бугазы аша үтеп сәүдә иткән этрусклар, Карфаген һәм

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2019) санында.
*Фәнни-популяр тарихи бәян.

Грециянең вак дәүләтләре өчен зур кыенлыклар туа. Моннан бигрәк тә этрусклар зур зыян күрә. Барысы да тар бугазны бикләп куйган Регий шәһәре тираны Анаксилай аркасында килеп чыга.

Әмма кыенлыклар моның белән генә тәгалләнми. Сицилия утравы тирәсендәге диңгездә Дионисий атлы пират Карфаген һәм этрускларның сәүдә корабларына һөҗүм итә: талый һәм аларны батыра башлый. Каян килеп чыкты соң әле бу афәт? Кем ул Дионисий? Исеменә караганда, ул грек булырга тиеш. Соңрак ачыклана – Дионисий Сицилия утравындагы Сиракуза шәһәре тираны икән (Нем., 160). Пиратлыкны үзенең төп шөгыле итеп сайлаган Дионисий да чыгышы белән Кече Азиядәге Лидия патшалыгы ярында урнашкан Фокея каласыннан. Геродот хәбәренә караганда, ул әүвәл Финикия корабларын талау белән шөгыльләнгән, аннан соң гына Урта диңгезнең көнбатышына юнәлгән һәм Сицилия утравы тирәсендәге диңгездә Карфаген һәм этрусклар корабларына һөҗүм итәргә тотынган, әмма үз халкына – грек корабларына тимәгән. Шулай итеп, Корсика, Сардиния һәм Сицилия утраулары тирәсеннән узган этрусклар һәм карфагенлыларның сәүдә кораблары өчен шактый хәтәр хәл барлыкка килә.

Тиррен диңгезендә пират Дионисийның шулай беркемнән курыкмыйча юлбасарлык итүе карфагенлылар белән этрусклар арасында әүвәлге аркадашлык килешүенең юкка чыгуы турында сөйли. Бергәләп эш итсәләр, алар Дионисийга алай узынырга ирек бирмәсләр иде.

Б.э.к. 480 елда Карфаген белән Сицилиядә ныклап урнашкан греклар арасында булган зур сугыш та элекке берлекнең юкка чыгуы хакында сөйли. Бу сугыш тарихка «Гимера сугышы» исеме белән кереп калган.

Зур сугышны тәфсилләп тасвирлау безнең максатка керми, шуңа күрә аның нәтиҗәсен генә әйтеп узабыз. Б.э.к. 480 елда булган Гимера сугышында Карфаген флоты тар-мар ителә. Бу хәл Урта диңгезнең көнбатышында вазгыятьнең тулысынча үзгәрүенә китерә. Сугышта Карфагенның гаскәре һәм флоты гына тар-мар ителеп калмый, этрускларның дошманы Анаксилай үзе дә җиңелүгә дучар була. Әмма этруск диңгезчеләренең хәле аңа карап кына яхшырмый. Регий тираны Анаксилай җиңелгәннән соң, аның урынын этрусклар өчен тагын да хәтәррәк дошман – Сицилиядәге греклар колониясе Сиракуза ала. Күп тә үтми, этрускларга Сиракуза греклары белән каршылыкка керергә туры килә. Эш шунда ки, Кум – Көньяк Италиянең Кампанья өлкәсендәге этрусклар шәһәре, анда шулай ук греклар да яши. Шуңа да карамастан, бу шәһәр этрускларның дошманы Сиракуза колониясе белән килешү төзи. Табигый, әлеге килешү этрускларга һәм аларның колонияләре урнашкан Кампаньяга каршы ясалган адым була. Шул сәбәпле туган каршылыклар этрусклар белән Сиракуза арасында диңгез сугышы башлануга китерә. Сугышта Сиракуза грекларының көчле флоты этрускларны җиңүгә ирешә. Карфаген исә, грекларның дошманы саналса да, этрускларга ярдәмгә килми. Алар арасындагы элекке килешү бу вакытта инде үз көчен югалткан, сәяси вазгыять үзгәргән була. Шушы җиңелү аркасында этрусклар Неополитан култыгындагы Искья утравында урнашкан хәрби базаларын да югалталар. Соңрак анда греклар хәтта ныгытма да төзеп куялар.

Әмма элегрәк диңгез киңлекләрендә хуҗа булып яшәгән этрускларның югалтулары моның белән генә чикләнми. Греклар Көньяк Галлиядә Массалия колониясен (хәзерге Марсель) һәм Көнчыгыш Иберия (Испания) ярларында да күп колонияләр төзиләр. Карфаген диңгезчеләрен дә кысрыклый башлыйлар. Билгеле булганча, Карфаген Иберия белән дә актив сәүдә алып барган. Карфагенны Ибериядән кысып чыгару өчен, Массалия греклары аларга каршы сугыш башлый. Ул сугыш б.э.к. 490-485 елларда Ибериянең көнчыгышындагы Нао борыны (хәзерге Валенсия территориясе)

Безнең мирас №2 февраль 2020

Этруск сугышчысы каберенә куелган таш

тирәсендә була. Дәһшәтле сугыш Массалия греклары файдасына тәмамлана, карфагенлылар җиңелә һәм шуннан соң Иберия белән сәүдә итүне туктатырга мәҗбүр була. Сугыш нәтиҗәләре этрускларның диңгез сәүдәсенең кысылуына китерә. Аларга хәзер Этруриядән әллә ни ерак китмичә, Корсика белән Сардиния утравы тирәләрендә генә хәрәкәт итәргә туры килә. Көньяк Галлия һәм Иберия якларына сәүдә белән йөрү хәтәр нәрсәгә әверелә.

«Этрускларның диңгез киңлекләрендә хуҗаларча йөрүенә б.э.к. V гасырда Сиракуза флоты ясаган һөҗүм чик куя. Б.э.к. 452 елда Сиракуза греклары этрускларга каршы зур экспедиция оештыралар. Аның максаты этрускларның Популония шәһәре каршында урнашкан Эльба утравы янындагы Аргоос гаванында торган этрусклар флотын юк итү була. Бу яу уңышлы башкарылса да, көтелгән нәтиҗәне бирми. Сиракуза флоты наврахы (флот башлыгы. – *С.Ш.*) Фаилның этрусклар тарафыннан сатып алынуы ачыклана. Шуннан соң наварх Апеллес идарәсендә яңа флотилия җибәрелә. Ул Эльба утравын басып ала, Этрурия белән Корсика ярларын бөлгенлеккә төшерә, бик күп коллар һәм башка байлыклар алып кайта» (Нем., 158).

Шулай итеп, этрускларның сәүдә итү мөмкинлекләре бик нык кысыла. Бу хәл Этрурия икътисадына зур зыян сала. Шуннан соң алар диңгез сәүдәсе белән иркенләп шөгыльләнүдән баш тартырга мәҗбүр булалар.

Китерелгән өзектә Сиракуза флоты навархының исеме игътибарны җәлеп итә. Аның

Фаил дип аталуы төрки кавемнән булуы турында сөйли. Бу очраклы хәл түгел. Борынгы заманда Урта диңгез бассейны тирәсендә яшәгән халыкларның тарихы белән кызыксына башласаң, еш кына төрки исемнәргә тап буласың. Бу нәрсә турында сөйли соң? Димәк, Урта диңгез буйларына һинд-аурупа телле халыклар үтеп кергәнче, иң борынгы заманнарда анда төрки кавемнәр яшәгән булган. Иберия, Италия, Греция, Кече Азиядәге Троада, Мисия, Лидия, Кария, Крит утравында без борынгы замандагы төрки эзләргә юлыгабыз. Гомумән, Урта диңгез бассейнында ерак заманнарда төрки кавемнәр яшәвен алардан калган артефактлар һәм һинд-аурупа телле халыклар телендәге төрки сүзләр катламы саклану күрсәтеп тора. Берәр территориядә яшәгән һәм соңыннан аннан кысрыклап чыгарылган халыкның эзе бөтенләй юкка чыкмый, ул топонимикада, елга, тау, кала, кеше исемнәре һәм башка нәрсәләрдә саклана. Этрусклар яшәгән заманда Урта диңгез буйларында әле төрки кавемнәр шактый булган. Шуңа күрә без анда төрки сүзләрне, исемнәрне еш очратабыз.

Диңгез сугышындагы соңгы җиңелүдән соң, этрускларның сәүдә кораблары үз диңгезләре булган Тиррен диңгезен гизә алсалар да, аларга инде Көньяк Галлия (Альп тауларының бу ягы) белән көнчыгыш Иберия ярларына таба йөзү, бигрәк тә грекларның Сиракуза колониясе кул астындагы Сицилия утравына якынлашу һәм, тар Мессина бугазы аша үтеп, Көнчыгыштагы илләр белән сәүдә итү хәтәр нәрсәгә әверелә. Этрурия икътисадының әһәмиятле бер тармагын тәшкил иткән диңгез сәүдәсе бик нык кысылганнан соң, этруск диңгезчеләре бу авыр хәлдән ничек чыкканнар соң? Унике шәһәр-дәүләттән торган Этруриянең яшәешен дәвам итәргә, тормышын алып барырга кирәк бит.

Бу авыр хәл этруск диңгезчеләрен юлбасарлык-пиратлык юлына басарга мәҗбүр итә. Б.э.к. IV-III гасырларда этрусклар күрше халыкларга яманаты чыккан пиратлар буларак танылалар. Диңгез юлбасарлары сыйфатында алар инде Тиррен диңгезендә генә бикләнеп ятмыйлар, ә Италиядән ерак җирләргә кадәр барып җитәләр. Этрусклар Адриатик диңгездә дә, Эгей диңгезендә дә бу хәтәр эш белән актив шөгыльләнәләр. Аларның һөҗүмнәреннән зур зыян күргән греклар, тиррен (этруск) пиратларыннан саклану өчен, хәтта төрле чаралар да күрә башлыйлар. Мәсәлән, Эгей диңгезендәге Делос утравы хакимияте б.э.к. 299 елда тиррен (этруск) пиратлары һөҗүменнән саклаучыларга акча түләү турында карар да кабул итә. Ә Афина шәһәре б.э.к. 325 нче елда, тирреннар (этрусклар) һөҗүменнән саклану өчен, Адриатик диңгез буйларына колонистлар җибәрә (Нем., 159).

Б.э.к. IV-III гасырларда тиррен (этруск) пиратларының төп базалары Адриатик диңгезнең төньягындагы шәһәр-колонияләрендә урнаша. Әйтелгәнчә, биредә аларның Адрия, Спина һәм башка шәһәрләре була. Сиракуза греклары хакимлек иткән Тиррен диңгезеннән ерактa, Апеннин таулары артында аларга хәрәкәт итү иминрәк була. Моннан Урта диңгезнең көнчыгышына чыгу да бернинди кыенлык тудырмый. Хәер, ул заманда диңгез юлбасарлыгы белән этрусклар гына шөгыльләнми. Финикиялеләр дә, диңгез сәүдәсе белән беррәттән, пиратлыктан да баш тартмыйлар.

Этрускларга диңгез юлбасарлары – пиратлар кушаматы тагылуда күпмедер дәрәҗәдә борынгы заман авторларының да гаебе бар икән. Берәүләр Эгей диңгезе пиратларын «тирреннар» дип атаса, икенчеләре этрускларның Рим кул астына кергән чорда пиратлык белән шөгыльләнүен күз алдында тоткан. Шул сәбәпле, Урта диңгездә пиратлык белән шөгыльләнгән байтак халыкларның гаебе «тиррен-этрусклар» өстенә төшкән һәм ул тарихта теркәлеп калган. Этрусклар исә пиратлык белән бары тик б.э.к. IV-III гасырларда гына шөгыльләнә башлыйлар. Моның сәбәбе болай аңлатыла: *«Этрускларның диңгездәге кодрәтле чагы этруск шәһәрләренең берлек төзеп яшәгән дәверенә туры*



Этруск сугышчысының шлемы

килә, бу хәл аларның пиратлык белән шөгыльләнүе турында сөйләми. Мондый вазгыять, Страбонның фикерен дөрес аңлаганда, этрускларның кодрәте кимегәч, ягъни аларның Римга буйсынган заманында гына барлыкка килә» (Нем., 161).

Этрускларның пиратлык белән актив рәвештә шөгыльләнә башлавын аңлавы кыен түгел. Рим, бераз көчәя төшкәч, йөз ел дәвамында Италиядә яшәүче халыкларга каршы яулап алу сугышлары алып бара. Шул исәптән, берәм-берәм Этруриянең шәһәр-дәүләтләрен дә буйсындыруга ирешә, этрускларда изге саналган чикләрне юк итеп, аларның җирләрен үзенә куша, үз кануннарын урнаштыра. Римга нигез салган, аны матур һәм төзек шәһәр итеп кордырган этруск патшаларының тарихи хезмәте онытыла башлый. Этрусклар үзләре төзеп биргән дәүләттә икенче сортлы халыкка әйләнә. Алар үз кырларында Рим җирбиләүчеләренең хезмәтчеләренә әверелә. Этруск халкы шулай үз илендә хуҗа булып яшәү хокукыннан мәхрүм ителә. Рәхимсез империягә әверелә барган Римның комсыз планнарын тормышка ашыруда бу халык та катнашырга мәҗбүр ителә.

Б.э.к. IV-III гасырларда этрускларның диңгез юлбасарларына әверелүендә Римның да гаебе бар. Үз җирләрендә Рим колонияләре барлыкка килү, этрусклар диңгез сәүдәсенең бик нык кысылуы, хәтта тукталу дәрәҗәсенә җитүе иректе тормыш алып барырга күнеккән этруск диңгезчеләрен билгеле бер дәрәҗәдә пиратлык белән шөгыльләнүгә этәрә. Беренчедән, алар диңгез киңлекләрендә үзләрен элеккечә иректе хис итсәләр, икенчедән, пиратлык белән кулга төшергән колларны Рим алардан бик теләп сатып ала, чөнки көчәя барган империягә, агрессив ниятләрен тормышка ашыру өчен, бик күп коллар кирәк була. Шулай итеп, этрускларның бер өлеше тормышны диңгез юлбасарлыгы белән шөгыльләнеп алып баруга күчә. Бу хәтәр шөгыль, хөрмәткә лаек булмаса да, зур табыш китерә. Иң мөһиме – этруск пиратлары, аларның акыл иясе, «пәйгамбәре» Таг күрсәтмәләренә нигезләнеп төзелгән изге ватаннары Этрурияне ташлап чыгып ерак диңгезләрдә йөзгәндә, Рим кануннарына буйсынмыйча, үзләрен иректе хис иткәннәрдер.

Әйтергә кирәк, кораблар төзергә, алар белән идарә итәргә, диңгезгә чыгарга да, аңа кадәр иген игеп, хайван асрап көн күргән римлыларны этрусклар өйрәтә. Римлыларның диңгезчеләр буларак беренче тапкыр танылуы Рим тәхетендә утырган соңгы патша этруск Горур Тарквини заманында була. Әйтелгәнчә, ул вакытта Карфаген белән Рим арасында Килешү төзелә һәм анда, Римның диңгездә йөзү хокукларын бик нык чикли торган маддәләр теркәлсә дә, Римның диңгезгә чыгуы этрусклар тәҗрибәсе һәм ярдәменә таянып башкарыла. ■

Гөләйза кыйссасы

Галим Хисамиев

XVIII гасырда «Әби патша» биргән дин ирегеннән файдаланып хак исламга кайтып барган, хәтта мөселман икәнлекләрен ачыктан-ачык белдерә башлаган яңа чукындырылган татарлар белән XIX гасырда чиркәү әһелләре аеруча кызыксына башлый. Аларның ислам диненә ябышып ятулары, хәтта, каршылык белдереп, мөселманлыкка күчүне сорап гаризалар яудырулары дәүләтнең дә империячел сәясәтенә туры килми. Мәхкәмәләр яңа чукындырылганнарга, керәшенлектән язып, исламга күчкәннәргә каршы шикаятьләр белән тула, тикшерү эшләре ачыла. Татарстан Республикасы Милли архивында сакланган шундый эшләрнең берсе ярдәмендә ислам дине өчен көрәшкән татар кызы Гөләйза (чукындырылганнан соң – Пелагея) һәм аның гаиләсенең фаҗигале язмышын ачыклыйк.

«Яңа туган баласы белән суд каршына бастырырга!»

1837 елның 13 ноябрендә Казан рухани консисториясе, архиепископ Владимир күрсәтмәсе буенча, Чистай өязендәге Кыр Шонталасы авылында яшәүче, мөселманлыкка кайткан Гөләйзаны (Пелагеяны) баласы белән полиция ярдәмендә чиркәүгә китертеп, чукындыру турында карар чыгара, әлеге эшне башкарып чыгуны Чистай земствосы мәхкәмәсенә йөкли. Карарның үтәлешен Биләр рухани округының баш атакае Михаил Лавров күзәтеп торырга тиеш була. Бу руханиның Чистай һәм

ПО ОБЩЕМУ НАСТОЛЬНОМУ №24.
постолу №24.
Секретное
ДѢЛО
И. А. Арх. № 22

«Гөләйза эше» – «Секретное дело №24 по рапорту Чистопольского уездного суда об отпадении от православия в магометанство крещеной из татар девки деревни Степной Шенталы Пелагеи, по отцу неизвестной». ТР МА, 17 ф. (Өяз судлары.Чистай өязе), 48 тасв., 22 нче эш

Галим Гыйльметдин улы Хисамиев – техник фәннәр кандидаты, Казан дәүләт медицина университетының гомуми һәм органик химия кафедрасы доценты, төбәкне өйрәнүче.

Спас өязләрендә мөселманлыкка кайткан татарларны күзәтүче, аларны янәдән көчләп чукындыру вакыйгаларының башында торучы, бик югары даирәләргә, шул исәптән, Казан рухани консисториясенә (чиркәү мәхкәмәсенә) әләк-хәбәрләр җиткереп торучы вазыйфаи зат икәнен искәртеп узу мәслихәт. М.Лавров 18 ноябрьдә Чистай земство мәхкәмәсенә тиешле хөкем карарын чыгаруны һәм аның үтәлеше турында үзенә хәбәр итүне сорап яза.

Мөрәҗәгать земство мәхкәмәсенә 19 ноябрьдә килә. Мәхкәмә шул ук көнне: *«Гөләйзаны яңа туган баласы белән суд каршына бастырырга, улын чукындырмауның сәбәпләрен ачыклау максатыннан сорау алырга һәм аннары тиешле урыннарга җибәрергә»*, – дигән карар чыгара.

Гөләйза-Пелагея: «Мин христиан динен танымыйм!»

Полиция Гөләйза белән аның әнисе Гөлзәданы эзләп табып, кулга ала һәм Чистай земство мәхкәмәсенә китерә. 1838 елның 21 февралендә гаиләдәге һәр кешедән аерым-аерым сорау алына. Гөлайза: *«Исемемнең чыннан да Пелагея икәнен белмим* (күрәсең, аңа берничә мәртәбә Пелагея дип эндәшкәннәр), *чөнки мин бервакытта да рус исеме белән йөрмәдем, элек тә, хәзер дә минем атым Гөләйза. Этиемнең кем икәнен, әнием Фекла Тимофееваның да кая һәм кемгә тормышка чыгуын белмим. Ул, русча исем белән йөрсә дә, мине тумыштан ислам динендә тәрбияләде, христиан кагыйдәләренә өйрәтелмәгәнмен, рус гореф-гадәтләрен үтәмәдем, христиан диненең нәрсә икәнен дә белмим. Мин ничек христиан булыйм? Яшемне дә әйтә алмыйм. Кечкенә чакта Кыр Шонталасы авылында төрле кешеләрдә яшәдем, эшләп ашадым. 30 яшьләр тирәсендә мине Чирүле Шонталасы авылыннан татар мөселманы Хәким Камаевка димләделәр. Әнием, христиан исемле булу сәбәпле, татар мөселманына кияүгә бирергә икеләнеп, Кызылъярдагы атакайга (попның исемен белмим) барып, аннан рөхсәт сорады. Атакай, үзенең язмаларында минем исемемне тапмагач, кияүгә чыгарга рөхсәт бирде һәм мин менә дүртенче ел инде Камаев белән торам. Ярлы булуыбыз сәбәпле, никах укытмадык*. Шушы иремнән Габделвахит һәм Габделҗаббар исемле улларымны таптым. Беренчесенә – өч яшь, икенчесенә – ике ай ярым. Аларга Чирүле Шонталасы авылы мулласы Әхмәт мөселманча исем кушты. Үземнең нинди боерык буенча һәм нинди приходка беркетелүемне белмим. Ни өчен балаларымны чукындырмадыммы? Тиешле дип санамадым, чөнки мин христиан динен танымыйм! Аннары беркем дә миннән аны таләп итмәде! Үзем өчен кул куярга рөхсәт итәм»*, –дип җавап бирә һәм кемдер аның урынына имза куя.

Гөлзәда-Фекла: «Мөселманча гына эш йөртәм!»

Гөләйзаның әнисе Гөлзәда исә: *«Минем атым Фекла, Тимофей кызы* (күрәсең, соңрак, мөселманлыкка чыккач, ул Гөлзәда исемен алган. – *Авт.*), *50 яшемдә, язык әйтүдә* (тәүбә-истигъфар исповедь. – *Авт.*) *һәм өлеш алуда* (причастия. – *Авт.*) *булганым юк, аларның нәрсә икәнлеген дә белмим, чөнки үзем дә, туган-тумачам кебек, христиан гореф-гадәтләрен тотмыйм, мөселманча гына эш йөртәм. Штрафка һәм хөкемгә тартылга-*

*Барлык җавапларда да «никах укытмадык» яки «зина кылдым» дип әйтелгән. Керәшен татарлары һәм чукындырылып та исламга кире кайтканнар белән никах өчен сөрген яки үлем җәзасы янаган. Җавапка тартылганнар бу хакта бик яхшы белгән һәм, мөселман ирләренең яки мулланың гомерен саклап калу өчен, шундый ялганга барырга мәҗбүр булган.



Гөләйзаның («татарская дочка Пелагея»ның) Чистай земство мәхкамәсендә биргән күрсәтмәсеннән фрагмент. 1838 елның 21 феврале

ным юк, укый-яза белмим, 8 нче ревизия буенча Кыр Шонталасында язылган. Әтием чукындырылган татар Тимофей (әтисенең исемен белми) шушы авылдан. Башта әти, аннары әни үлеп китте. Яшьли ятим калгач, Петр исемле, икенчесенең исемен хәтерләмим, энемнәрдә яшәдем.

Энемнәрне Дёмкино авылына күчереп утырткач, анда тордым. Алар үлгәч, кеше өстендә йөрдем, зина кылдым, йөккә узгач, 28 ел элек янәдән элгәре торган урыныма – Кыр Шонталасына кайттым. Шунда беренче кызымны таптым. Бала тугач, Кызыльяр авылына 3 тапкыр барып, атакайдан аңа исем кушарга сораган идем, тик ул вакыттагы рухани (исемен белмим): «Үзеңнең дә, кызыңның да чыгышы билгесез», – дип, кире какты, шуннан соң кызыма татарча Гөләйза дип исем куштым. Шушы авылда яшәп, никахсыз малай таптым, тик атакай Трифон аны чукындырды, русча исем кушты. Хәзер ул баланы авылдашым «иске татар керәшене» Ишук үзенә асрамага алды, ревизия вакытында үз гаиләсенә яздырды. Дүрт ел элек Чирүле Шонталасыннан Хәким Камаев дигән кеше кызыма димче җибәрде. Тик, чукындырылган булганга, мөселманча никах укытырга шикләнеп, хәзерге Кызыльяр авылы атакаена бардым. Китаплары буенча эзләнеп, кызымны таба алмагач, аны татар мөселманына кияүгә бирергә рөхсәт итте. Мин шулай иттем дә», – дип сөйли. Моннан тыш, Фекла Тимофееваның соңгы күрсәтмәләре кызыныкы кебек, дип язылган. Русча укый һәм яза белмәве сәбәпле, аның урынына Чистай мещаны Ермолай Бабушкин имза куйган. Мәхкәмә Гөләйза-Пелагея эшен, төгәл нәтиҗә чыгара алмау сәбәпле, кичектерергә карар кыла.


№ 2774.

19. Ноября 1837

Въ Чистопольскій Земскій Судъ

Иерей М.Лавровның Чистай земство мәхкамәсенә мөрәҗәгате. 1837 елның 18 ноябре

1763 елгы документка караганда, чиркәү әһелләре Гөлзәданың этисе Бикмөхәммәд Вәли улына, чукындырылганнан соң, Тимофей Моисеев; уллары Ишмөхәммәдкә – Василий, Әлмөхәммәдкә – Федот, Бикмөхәммәднең энесе Бикморзага Иван Моисеев исемен такканнар. 1798-1838 елларда чиркәүгә язык әйтүгә (тәүбә-истигъфарга) йөрүчеләр арасында Фекла Тимофееваның һәм аның балаларының исемнәре юк. Димәк, алар, чыннан да, анда теркәлми калганнар.

2 нче мәхкәмә: «Атакай белән муллага тикшерү эше ачарга!»

Гөләйза эше Чистай земство мәхкәмәсендә кабат бер айдан соң – 1838 елның 19 мартында тыңлана. Анда Гөләйза-Пелагея һәм Гөлзәда-Фекла Тимофеевалардан тагын бер мәртәбә сорау алына. Мәхкәмә бу очракта да җәза карары кабул итми, ә депутатлар җәлеп итеп, Кызылъяр авылы атакае белән Шонтала авылы мулласына тикшерү эшләре ачарга һәм «Гөләйза эше»н 2 нче стан приставына тапшырырга дигән карар чыгара.

Бу елларда Чистай һәм Спас өязендә «яңа чукындырылган» татарларның мөселманлыкка күпләп кайтуы сәбәпле, суд органнары, өяз управалары төрле тикшерүләр белән күмелеп, барысына да өлгерә алмаган. Күпмедер дәрәҗәдә моңа Казан шәһәрендәге зур янгын да сәбәпче булгандыр дип уйларга мөмкин. Шуңа күрә



Гөлзәданың (Фекла Тимофееваның) Чистай земство мәхкамәсендә биргән күрсәтмәсе. 1838 елның 21 феврале

Чистай мәхкәмәсе татар хатын-кызының эшенә әллә ни игътибар да итми. Нәтиҗәдә, «Гөләйза эше»нә дүрт елдан соң гына кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр булганнар.

Өяз стряпчие Книгин: «Эшне тизрәк тәмамларга!»

...1842 елның 12 августында Чистай өяз стряпчие Книгин (суд эшләре тәртибен күзәтеп торучы чиновник. – Авт.), яшерен рәвештә 2 нче стан приставына мөрәҗәгать итеп, 1838 елда баш атакай Лавров шикаяте буенча башланган эшнең тәмамланмый ятуын искәртә. Шикаятьтә: *«Вазыйфаларыма таянып, галиҗәнап Юстиция министры һәм губерна прокуратурасы күрсәтмәләре буенча эшне тизрәк тәмамлап, земство мәхкәмәсенә тапшырырга үгетләп мөрәҗәгать итәм. Өяз стряпчие Книгин»*, – диелгән. Әмма «Гөләйза эше» буенча Юстиция министры һәм губерна прокуратурасыннан күрсәтмә булуы бик тә шикле. Шулай ук стряпчийның үзен бик мөһим һәм югары даирәләр исеменнән эш йөртүче зат итеп чагылдырырга тырышуы да аңлашылып бетми. 10 сентябрьдә дә стряпчий янәдән 2 нче стан приставына мөрәҗәгать итә. Анда: *«12 августта Сезгә җибәргән рәсми кәгазьдәгеләрне кабатлап, Кыр Шонталасы авылыннан христиан диненнән тайпылган Гөлайза турындагы тикшерүләрне тизрәк тәмамлауны*



Мулла Әхмәров алып барган метрика кенәгәсеннән күчермә. Документта Габделвахитның – 1835 елның 22 гыйнварында, Габделҗаббарның – 1837 елның 7 декабрендә, Гайнетулланың 1842 елның 16 августында Чирүле Шонталасында туувы, әтиләре Габделхәким, әниләре Гөләйза икәне язылган.

һәм эшне земство мәхкәмәсендә карауны бертуктаусыз үтенәм. Стряпчий Книгин», – дип язылган. Чистай стряпчие 1 октябрьдә дә, 1843 елның 22 мартында да приставка үзенең шушы үтенечен җиткерә.

Күрәсең, мәхкәмә карары нигезендә, Дәүләт милке округыннан депутатлар билгеләнмәү сәбәпле, пристав тикшерү эшен бөтенләй алып бармаган. Книгин үтенечен истә тотып, пристав аларны җибәрү турында югары даирәләргә мөрәҗәгать итә. 1843 елның мартында Чистай земство мәхкәмәсенең приставка юллаган җавап хатында: *«Сезнең 17 марттан ясалган рапортыгызга җавап итеп, земство мәхкәмәсе, мөселманлыкка кайткан чукындырылган татарлар турында тикшерүләр алып бару өчен, тиздән депутатлар җибәрeләчәге турында хәбәр итә. Тикшерүләрдә катнашу өчен депутатларның җибәрелүе турында өлкән атакай Василий Орловка да, Чистай округы мәхкәмәсенә дә хәбәр ителде», – диелә. 22 мартта Дәүләт милке министрлыгының Чистай округы идарәсеннән киткән документта: «Сезнең 17 марттагы хатыгызга карата округ идарәсе Урманасты Шонталасы, Кыр Шонталасы, Караваево, Дума һ.б. авыллардагы чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайтулары турындагы эшләрне тикшерүдә катнашу өчен депутатлык вазыйфасы Мейснерга йөкләнгәнлеген белдерә»*, – дип язылган.

Депутат Мейснер вакытында барып җитмәгәнме яки җибәрелмәгәнме – анысы безгә билгесез. Шул сәбәпле, стан приставы депутатлар җибәрүне кабат таләп итә. Нәтиҗәдә, округ идарәсе башлыгыннан мондый эчтәлектәге хат алына: *«Сез галиҗәнапнең 28 марттагы үтенеченә җавап итеп, мөселманлыкка кайткан татарларның эшен тикшерү өчен, Дәүләт милке ведомствосыннан депутат итеп округ башлыгының ярдәмчесе Г.Мейснер җибәрелә. Аңа бу турыда хәбәр ителгән. 30нчы март, 1843 ел»*.

Шулай да тикшерү эше озакка сузылган. Бу вакытта Чистай өязенең 2 нче стан приставы да алышынырга өлгерә. Пристав вазыйфаларын Кызылъяр алпавыты, отставкадагы корнет Александр Иванович Шахт үти башлый. Моны күзәтеп торган әрсез һәм сабырсыз өяз стряпчие Книгин, приставка эшне тизләтү турында, кат-кат – 24 май, 19 декабрь, 1844 елның 20 гыйнварында язган гаризиларында искәртеп торган.

***

Ниһаять, 1844 елның февралендә Чистай өязе 2 нче стан приставы вазыйфаларын башкаручы корнет Шахт, депутатлар округ башлыгы ярдәмчесе, флот лейтенанты Мейснер, Кутуш авылы атакае Николай Казанцев, берләшеп, Кызылъяр авылына килеп төшә. Түрәләр, алпавытлар утарына урнашып, халыкны ике катлы идарә бинасына җыя. 24 февральдә алар Гөләйзадан, аның ире Хәким Камаевтан, Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәровтан, Кыр Шонталасы авылы халкыннан сорау, Кызылъяр авылы атакае Алексей Мефодьевтан аңлатма ала. Гөләйза сорау алу барышында 1838 елның 20 февралендә земство мәхкәмәсендә биргән мәгълүматны кабат раслый, Чирүле Шонталасында Хәким Камаев белән никахсыз яшәве, өченче улын табуы турында әйтә, Чирүле Шенталасы мулласы Әхмәтнең аңа Гайнетулла дип исем кушуы, балага инде 1 яшь тә 7 ай, ә Гөләйзаның үзенә 37 яшь булуын хәбәр итә. 55 яшьлек Фекла Тимофеева да элегрәк биргән күрсәтмәләрен үзгәртмичә кабатлый. Аның урынына Юшков хуҗалыгы крестьяны Николай Адамов имза куя.

Хәким Камаев: «Аның чукындырылуы турында хәбәрем юк!»

Гөләйзаның ире: *«Минем атым – Хәким Камаев, миңа 37 яшь, мөселман, хөкемгә һәм штрафка тартылганым юк, Чирүле Шонталасы авылының дәүләт крестьяны, 8 нче ревизиядә теркәлгәнмен. Якынча 9 ел элек, Кыр Шонталасында яшәүче Фекла Тимофееваның никахсыз туган кызын Гөләйзаны хатынлыкка алып, шул вакыттан бирле бергә яшәп, өч бала тудырдык. Хәзерге вакытта улыбыз Габделвахитка – 8 яшь, Габделҗаббарга – 5 яшь, Гайнетуллага – 1 яшь тә 7 ай. Гөләйза белән никах укытмадык, аның чукындырылуы турында хәбәрем юк. Балаларыбызга мөселман исемнәрен, минем чакыруым буенча килеп, авылыбызның мулласы Әхмәт Әхмәров кушты. Исем кушкан чакта хатынымның чыгышын сорашмады, мин дә әйтмәдем. Балаларыбыз чукындырылмаган»*, – дип җавап бирә.

Пристав Чирүле Шонталасы авылында яшәүче дәүләт крестьяны Хәкимнең чын исеме Габделхәким Ташаев икәнен һәм аның гаиләсе 8 нче ревизия документында 10 нчы номер белән теркәлүен, ул вакытта Ташаевка 25 яшь булганын ачыклый.

Мулла Әхмәт Әхмәров: «Мөселман диненә өндәмәдем!»

Чирүле Шонталасы мулласы Әхмәт Әхмәров сорау алганда: *«Исемем – Әхмәт. Миңа 48 яшь, мөселман, хөкемгә һәм штрафка тартылганым булмады, татарча яза һәм укый алам. 8 нче ревизиядә Спасс өязенең Түбән Тигәнәле авылында ясаклы татар дип теркәлгәнмен. Мөселманнарның Диния нәзараты указы буенча, Чистай өязе Чирүле Шонталасы авылының манарасыз (биш вакыт намазлы) мәчетенә мулла итеп билгеләндем. Мин шушы авыл мәхәлләсеннән Хәким Камаевның балалары Габделвахитка, Габделҗаббар һәм Гайнетуллага, аталарының чакыруы буенча барып, исемнәр куштым. Хәким хатынының чукындырылуын, аның чыгышын сорамадым, үзләре дә миңа әйтмәделәр. Гөләйзаны мөселман дип санап, балаларын метрика кенәгәсенә теркәп куйдым. Шушы кенәгәдән күчермәне китерәм. Хәким белән Гөләйзага никах укымадым, мөселман диненә өндәмәдем»*, – дип җавап бирә. Метрикадан китерелгән, гарәп шрифты белән язылган күчермәне русчага Кутуш авылы атакае Николай Казанцев тәрҗемә иткән.

Дәвамы бар ■

Мәрьям Рәхмәт Паташева

Истанбул хатирәләре



III

Мөхтәрәм газетагызда төрекләрнең гаилә мәсьәләсе вә аның уңайсыз җәһәтләре хакында, балалар тәрбиясе ни рәвештә вә ул тәрбиянең Төркия киләчәгенә ничек тәэсир итәчәге турында бераз язган идем. Бу турыда язганда, төрекләр арасында катыш никахлар хәтергә килә.

Христиан кызларына өйләнү төрекләрдә гадәт булып киткән – модага әйләнгән. Бу эштә шәригать рөхсәт итә дигән сылтау белән, төрекләр бу юлда сүи истигъмаль иту[1] дәрәҗәсенә киләләр. Ләкин, миңа калса, катыш никахларның зарары бик күп һәм төрекләрнең киләчәге өчен хәвефледер.

Бер гаилә рәхәт яшәсен өчен, аның әгъзалары арасында берлек булу һәм берсенең башрак булып, башкаларының аңа бераз итагать итүе кирәк. Минемчә, бер дәүләт, гадәттә, бер зур гаилә хөкемендә булып, анда булган һәр милләтләр дә бер тормыш илә яшәргә, һәммәсе бер кеше кеби булырга, гаиләне идарә итүче баш әгъза урынындагы хөкүмәт аталган бер төркемнең тәдбирләренә күнәргә һәм тәрәкъкый вә мәдәният юлында ул төркемгә милләт ярдәм итәргә тиештер. Табигый, һәр дәүләттә хөкүмәт түрәләре шул дәүләттә күпчелек тәшкил иткән милләт кешеләреннән булып, дәүләт аның исеме илә исемләнә, ул милләт тә хаким милләт санала. Төркиядә хаким милләт – төрекләр.

Төркия мөстәкыйль, куәтле, бәхетле булсын өчен, төрекләр аны ватан дип танып,

---

*Ахыры. Башы журналның 1 нче (2020) санында. Мәкалә 1913 елгы «Вакыт» газетасының 1223, 1245 нче саннарыннан алынды һәм хәзерге татар әдәби теленә якынайтылып тәкъдим ителә.

[1] Сүи истигъмаль иту – урынсыз куллану.



Кадырга хастаханәсе. Истанбул, 1915 ел

аны саклауны үзләренә мөкатдәс вазыйфа санарга, аның үсеше өчен һаман тырышырга, кирәк булганда аның өчен җан бирүдән дә курыкмаска тиешләр. Юкса төрекләр, истикъляляне *(бәйсезлекне)* саклый алмый, башка бер милләт кул астына кереп, тереклекне югалтулары шөбһәсездер.

Күп төрекләр, хәтта зур гына урында торганнары да, мөстәкыйль булып тору илә икенче бер милләт кул астында торуның аермасын аңламаганнар. «Бер зур дәүләт безне үз химаясенә алса иде дә, без дә аякка басар идек...» – шикелле гакыл аңламастай сүзләр сөйлиләр. Мондый сүзләрне ишетү бик авыр була иде.

Бичаралар, «химая»ны һаман аңламыйлармы? Ислам дәүләтләреннән шундый «химая» астына кергәннәре азмы? Аннан бер файда өмет итү мөмкинме? Мөстәкыйль яшәү мөмкин икән, аз гына иҗтиһад итүгә иренгән шикелле: «Башкалар ярдәм итсә иде!» – дип көтеп тору тәмам гаҗиз булу түгелме?

Истикъляль бик газиз булган шикелле, бер мәртәбә кулдан китсә, аны кайтару да бик читен, хәтта мөмкин дә булмыйдыр. Төрекләр дә, теләсәләр, бер дәүләтнең химаясенә керә калсалар, аннан котылулары бик шөбһәле, бәлки, өметсездер. Кызганыч, яхшы бер тормышка чыгу өчен, иҗтиһад кылу без мөселманнарда юк. Бер мәртәбә кол булса, шул көе калына һәм шул хәл табигый санала. Шул юлда төрле кыенлык, читенлекләр күренсә, һәммәсе дә тәкъдиргә йөкләтелеп, эш шуның илә тәмам була, яхшылатырга тырышылмый.

Бәйсезлекне бер югалткач, аны кире кайтара алмый даими кол булып калган милләтләр аз түгел. Бер вакытлар азатлыкны югалтып та, соңыннан мөстәкыйль булган милләтләр дә юк түгел. Русияне татарлар яулап алдылар. Ике йөз ел татарлар хуҗа булып торсалар да, руслар һәммәсе бер кеше шикелле иҗтиһад иттеләр. Татарлар исә бер-бере илә сугышудан бушамадылар. Ниһаять, руслар хаким, татарлар исә мәхкүм *(буйсынучы)* булдылар. Икенче мәртәбә Русия французларның явыннан котылды. Әмма Төркиядә болай булу ихтималы юк, чөнки төрекләрдә ватан хисе, берлек юк.

«Инсан үз милләтен онытмаска, миллиятне югалтмаска тиеш!».

Коллыктан курку вә аны уйлап, дошман илә көрәшерлек гайрәт юклыкны янә исбат иттеләр.

Төрекләр берничә сәяси партиягә бүленгәннәр, бере-берен һич яратмыйча, кулыннан килсә, бере-беренә зарар итәргә тырышалар, хәтта ватаннарына шулкадәр зур фаҗига килгән вакытта да берләшә алмадылар, һаман партия низагы дәвам итте һәм боларның үзара низаглары Төркиягә дошманыннан артыграк зарар китерде.

Кырым ханнары, Польша кенәзләренең үтенүе илә, анда ярдәм өчен үз гаскәрләрен җибәргән иделәр. Бу мөселман гаскәре Польшада озак торганлыктан, поляклар илә катыша-катыша, ниһаять, алар поляк кызларына өйләнә башладылар. Алардан балалар туды. Бу

Татар кызлары төрек яралылары арасында. Истанбул, 1912 ел. Фото «Аң» журналыннан алынды (1913, №16)

балалар христиан ана тәрбиясендә булу сәбәпле, татар телен, гадәтләрен һәм ватаннары булган Кырымны белми үстеләр. Ватаннарына мәхәббәтләре булмады, шулай итеп, тәмам мөселман түгел, тәмам христиан түгел, татар да түгел, поляк та түгел – милләтне югалткан бер литва татары булып калдылар. Бөтен бер милләт үз телен, гореф вә гадәтен югалтып, бөтенләй бер чит милләт арасында үзе дә югалу дәрәҗәсенә килде. Бичаралар бу хәлгә үзләре дә кайгыра, уңайсызлана, хакыйкать аяныч хәлдер!

Литва татарларының бу аяныч хәлгә килүләренә сәбәп ни? Минемчә, ачык бер сәбәп – ул да аналарының христиан кызы булуы.

Катыш никах хәзерге Төркиядә бик күбәеп бара.

Төрек яшьләре электән уку өчен Яуропага бара иделәр һәм хәзер дә баралар. Боларның кайберләре, Яуропада озак торулары сәбәпле, шунда христиан кызларына өйләнергә мәҗбүр булалар. Анда өйләнми кайтканнары исә, Төркиядә үзләренә сөйләгән сүзләрен аңларлык, укыган, тәрбия күргән төрек кызы таба алмаганлыкларыннан, чарасыз, яхшы укыган, тәрбия күргән христиан кызы алырга мәҗбүр булганнар.

Төрек кызлары исә хөррият дәверенә кадәр чит мәмләкәтләргә чыгып йөрү хакыннан мәхрүм, үзләрендә яхшы тәрбия алырлык мәктәпләр булмаганлыктан, әлбәттә, читтә укып кайткан яшьләргә үзләрен яраттыра алмый иделәр. Чөнки хөр, тәрбия күргән, яхшы укыган христан кызы илә, һичбер җиргә чыкмый, һаман хәрәмдә *(гаремда)* генә утырган, бернәрсә дә күрмәгән, яхшы тәрбия һәм мәгълүмат алмаган төрек кызы арасында, әлбәттә, аерма булырга тиеш. Әүвәлгеләр никадәр хәятле булса, соңгыларының шулкадәр рухсыз, төшкен күңелле булучылыгы бик табигыйдыр.

Укыган яшьләрдә күренгән бу хәл, килә-килә гадәт, мода шикелле булып, һич кирәкмәгән кешеләр дә, ягъни гади, һич Яуропаны күрмәгән төрекләр дә шулай

кылана башлаганнар. Шулай итеп, әүвәл чарасыз эшләнгән бер эш хәзер миллият вә милләт кирәкләрен оныттырыр дәрәҗәдә бер гадәткә әйләнгән.

Бер дәүләтнең тәрәккыйсе андагы хатыннарның мәгълүматлы, яхшы ана булуларына баглыдыр.

Инсан үз милләтен онытмаска, миллиятне югалтмаска тиеш. Хәлбуки, катыш никахлар исә моның киресенә хезмәт итә һәм милләтнең нигезен какшата. Төрекләрдә күренгән катыш никахларны арада булган сөешү һәм тирән хиссиятнең мәгънәви нәтиҗәсе, дип тә булмый, бәлки, һичбер фикергә нигезләнмәгән җиңелчә генә бер хәрәкәттер.

Христиан кызына өйләнгән гади, аз-маз гына укыган бер төректән: «Ни өчен төрек кызын алмадың? Хатыным, балаларымның анасы, диярлек бер мөселман кызы юкмыни?» – дип сорагачтын, һич тартынмастан, эреләнеп кенә: «Кызганыч, милләтебез кызларыннан үземә тиң, үзем яратырлык бер кыз таба алмадым!» – җавабын бирде.

Бөтен һөнәре матур киенүдән артмаган төрек, үзен шулкадәр мәдәни санап, мөселман кызын хатын итеп алуны бер түбәнчелек хисап итә. Шуларны күрү кешегә бик авыр була, хәттә елыйсы килә...

Христиан кызын алып, мөселман баласын христиан ана тәрбиясенә бирә вә моның илә милләтенә әйтеп бетергесез зарар китерә, ислам һәм Төркиянең зәгыйфьләнүенә сәбәп була. Бичара шуны аңламый яки аңларга теләми?!

Анасы христиан икән, баласының чын мөселман, ватанпәрвәр булып тәрбия кылынуы читен, гадәттә, мөмкин түгелдер. Чөнки бала, карында икән, анасына газиз, дөньяга килгәч исә, аралары бигрәк тә якынлаша: ана, сөте илә баланы туйдыра, мәхәббәт илә тулы күкрәгенә кыса, һич арымастан, балага һаман йомшак, хәлим сүзләр генә сөйли. Шунлыктан, бала һаман христиан ананың сүзләрен генә ишетә, аның телен аңлый һәм ул тел бала өчен газиз ана теле булып кала. Бер генә христиан кызының да Төркиягә вә төрекләргә мәхәббәт күзе илә карау ихтималы юктыр. Моңа һич ышанып та булмый, киресенчә, христиан кызы Төркиягә дошман, аны сөйми һәм үзендәге дошманлык хисен баласына да күчерә.

Искедән бирле һаман зәхмәт эчендә килгән бичара Төркиянең тышында һәм эчендә дошманнары аз түгел. Катыш никахлар исә төрекләрнең үз араларында ватанга дошманнарны күбәйтүдән башка бер файда бирми, һаман эшне авырлаштырадыр. Шуңа күрә төрекләрдә мондый катыш никахлар бетәргә тиеш. Белүемчә, бер дәүләтнең тәрәккыйсе андагы хатыннарның мәгълүматлы, яхшы ана булуларына баглыдыр.

Форсат бар икән, төрек хатыннары укырга, мәгълүмат алырга, тәрбиядә христиан кызларыннан югары торып, ирләрне үзләрнә багларга, мөселман балаларын ислам рухында ватанга мәхәббәт белән тәрбия итәргә тиеш. Шулай иткәндә төрек балалары ватан баласы булырлар, Төркиянең коллыктан котылуына хезмәт итәрләр һәм, шөбһәсез, Төркия дә бәхетле дәүләт, төрекләр дә бәхетле милләт булырлар, инша Аллаһ.

IV

Истанбулга сугышта яраланганнарны карар өчен баруыбыз сәбәпле, әлбәттә, төрекләрнең күп офицерларын һәм солдатларын күрергә туры килде. Бөтен вакыт шулар илә үтә иде. Хуш вә күңелле хәлләр күрәсең – шатланасың, ләкин, күңелсез, яраксыз нәрсәләр күреп тә хафаланасың.

Никадәр авыр булса да, төрек гаскәре арасында укый-яза белмәгәннәрнең күплеген әйтергә туры килә. Укый-яза белмәгәннәр гаскәрдә бик күп, хәтта укый-

Төрек гаскәре камил, батыр, гайрәтле һәм шулкадәр дә шәфкатьлеләр.

яза белми торган унтер-офицерлар, офицерлар да очрый. Әлбәттә, алар хезмәт күрсәткәннәр, шуңа күрә аларга беркадәр дәрәҗә бирелгән. Шулай булса да, алар укый-яза белми торган кеше булып, алардан зур эшләр күтәргә туры килми.

Офицерлар илә гади солдат арасында, аңлавымча, бәйләнеш юк, мәгънәви берлек, кардәшчә мәхәббәт һәм бер-беренә хөрмәт юк.

Офицерларның күбесе үзләрен солдатлардан бик аерым тоталар. Кечкенә кәрдәшләре булган солдатка якын булырга һич тырышмыйлар. Моның сәбәпләрен офицерлардан сорашкаладым, белергә тырышсам да, канәгать итәрлек җавап ала алмадым. «Әгәр якын, кардәш кеби мөгамәлә итә башласаң, алар бик үзсенеп китәләр, санга санамый, хөрмәт итми башлыйлар. Шул юл илә гаскәрдә иң мөһим, иң кирәкле дисциплина бетә, югала», – кеби сүзләр сөйләделәр. Бу мәсьәләне мин аңламыйм, бәлки, аларның бу сүзләре тугрыдыр, әмма офицер илә солдат арасындагы яхшы, кардәшчә мөгамәләдән дисциплина югалуны аңлау бик читен, хәтта мөмкин түгел, чөнки үзең хөрмәт иткән, сөйгән кешенең әмеренә буйсыну кеше өчен бик күңелле, рәхәт булырга тиеш. Офицерлар дисциплина өчен солдатларның мәхәббәтен корбан кылып, файда итмәсләр. Чөнки офицерларга «дошманнарыбыз» дип тә әйткәннәрен ишетә идек. Аралары шулкадәр бозылган вә ераклашкан икән, офицерлар илә солдатларга бер-берен аңлап эш итүләре уңайсыз булырга тиеш.

Һәрвакыт кеше кайнап торган Яңа күпердән карап торсаң, күренә иде: үткән-барган солдатлар офицерга честь бирми. Берәр бичара солдат чын күңелдән, хөрмәт илә офицерга честь бирә, әмма тегесе, үзен гаять югары тотып, аны күрмәгән шикелле җавап бирми узып китә. Бу бичара солдатның күңелен төшерә, җәрәхәтли. Бер мәртәбә шулай булгач, икенчедә ул аңа хөрмәт илә честь бирми. Әлбәттә, бирмәс, чөнки аның гыйззәте нәфесе *(үз-үзен сөючәнлеге)* бер мәртәбә аяк астында тапталып калды.

Соңгы җиңелүле сугышта төрек гаскәрен сүктеләр, куркак, дип тә гаепләделәр, ләкин бу бик тугры булмаса кирәк. Минемчә, төрек гаскәрендә гаеп юк. Гаскәр – камил, батыр, гайрәтле һәм шулкадәр дә шәфкатьле. Гаеп бары гаскәрнең башлыкларындадыр.

Хәтеремдә калды: хастаханәбезгә өч офицерны китерделәр. Доктор яныннан чыгып барганда боларны беренче мәртәбә күрдем, әмма һич хастага охшамаганнар – бөтенләй сәламәт кеше кеби күренделәр. Гаҗәпләнеп: «Боларда нинди хасталык бар икән?» – дигән уйга килдем. Хастаханә башлыгы доктордан: «Бу өч офицер ни илә авырыйлар?» – дип сорагач, ул: «Боларның хасталыгы куркыныч хасталыктыр. Боларда «ялкаулык» хасталыгы бар! Башка бернәрсә дә юк, хастаханәгә кабул итмәс идем, ләкин Кадырга хастаханәсенә урнаштырырга әмер алдым, чарасыз кабул итәргә мәҗбүрмен», – диде. Җавапны биргәч тә, мин, доктор уйнап сөйли, дип уйладым, ләкин доктор дөресен сөйләгән.

Кич бу өч офицер янына палатага кердем. Яннарыннан узганда, бераз туктап, баш очларына куелган хаста кәгазенә күз салдым. Кәгазьдә туйганчы ашарга, хорурәт *(калория)* юк, дип язылган, бәйләнгән җәрәхәт-фәлән дә күренми... Ниһаять: «Сездә ни чир бар соң?» – дип, үзләреннән сорадым. Бере – бераз саңгырау, икенчеләрендә бизгәк шикелле нәрсә, имеш. Соңрак гаять таза бер кеше кычкырып көлә, хәтта ул көлгәндә, колак авыртадыр. Бераз сөйләштек. Сүз арасында ялкау сез, фәлән кеби сүзләр илә бераз үзләрен ачуландым да. Соңрак, бер сүз дә тапмагач: «Без бик ардык, ял итәргә хастаханәгә кердек», – диделәр. Димәк, болар һич хаста түгел, фәкать эштән

качып, монда килгән булалар. Мин дә алардан көлеп: «Аллаһ сезгә тизрәк сәламәтлек бирсен дә, мөкаддәс вазыйфагызга кайтыгыз!» – дип киттем.

Берничә көннән соң боларның саңгырауларын офицер киемендә коридорда күрдем. «Янә сугышка китәм», – диде. Бераз рәхәт булып китте...

Моннан берничә көн узгач, тыйббия *(медицина)* мәктәбенә барырга туры килде. Мәктәп бакчасында хасталар йөри иделәр (мәктәп бакчасында лазарет бар). Ни күрим: хасталар арасында теге саңгырау офицер да йөри. «Сез мондамы? Ни эшлисез?» – дип, гаҗәпләнеп сорадым. Саңгырау офицер бераз гаҗәпләнеп торды да уйлаган сымак булып: «Бу хастаханәдә ятам, Кадырга хастаханәсеннән Сез безне кудыгыз бит!» – диде. Мин дә аның яныннан киттем. Бәлки, хастаханәдә мондый хасталар болар гына булмагандыр, боларның ишләре күп булгандыр, кем белсен...

وقت

«Вакыт» газетасы Балкан вакыйгаларын даими яктыртып барган

Бу язганнар һәммә офицерлар хакында түгел. Әлбәттә, мондый яраксызлары булган шикелле, тырыш, гайрәтле, ватан юлында җан фида кылудан тартынмаганнары да аз түгел. Андыйлар гади солдатлар арасында күп. Бер солдат алты мәртәбә җәрәхәтләнеп, җәрәхәте төзәлгәч тә, кире сугыш полкына китә иде.

Бер таныш төрек ханымы – офицер хатыны бар иде. Сугышка кадәр гаиләсе илә (ире һәм кечкенә углы) Әдрәнәдә торганнар. Сугыш башланды, Балкан ярымутравының күп өлеше канга буялды. Дошманнар да Әдрәнәгә якынлашып киләләр иде. Ул вакытта Әдрәнә халкы шәһәрне ташлап китә башлады. Әлеге төрек ханымы да китүгә әзерләнгән. Шул вакытта бу ханым кан илә буялган бу җирләрдән тизрәк читкә китәргә ирен никадәр димләсә дә, ялынса да, ире күнмәгән, үзенең туган шәһәрен, ислам илә Төркияне саклаудан качмыйча, Әдрәнәдә калган. Төрек ханымы баласы илә Истанбулга килгән. Кем белсен, бу бичара, бәлки, актык тамчы канга кадәр шул Әдрәнәне саклап, шунда шәһид булгандыр. Ире шундый фидакярлеккә хәзер икән, аны шул мөкаддәс эшеннән аерырга тырышкан бу хатын шуны сөйләгәндә бик ямсез, сөйкемсез күренә иде. Мин дә бу мөгамәләсе өчен аны (хакым булмаса да) шелтәләүдән үземне тыя алмадым. Хатын да, кәефсезләнеп, минем янымнан чыгып китте.

Хастаханәдә авыру саклаган төннәрнең берендә бер палатага кердем. Ягылган мич янында Зәйнәп ханым-карчык утыра иде. Шулкадәр тирән уйга чумган, хәтта минем

керүемне һич сизмәде. Хасталар рәхәт йокыларында. Башка бер эшем булмагач, Зәйнәп ханым янына килеп утырдым. Матур кара күзләренең карашы моңлы, кайгылы булып, мәрхүмә сөекле әбиемне хәтеремә төшерде. Шулвакыт, уянган хиссиятемә каршы тора алмый, Зәйнәп ханымны сөя-сөя үбүдән үземне туктата алмадым... Күзләреннән яшьләр китте... Мин аптырап калдым. Нидән елаганын аңлый алмадым. Соңрак, тәгәрәп-тәгәрәп төшкән яшьләрен сөртә-сөртә, сүзгә кереште: «Бу вакытка кадәр бер кайгым барлыгын бер кешегә дә сөйләгәнем юк иде әле, сезнең һәммәгезне үз балаларым шикелле сөйгәнлегемнән, хәзер сиңа сөйлисем килә», – диде һәм хәлен аңлата башлады. Сугышка киткән дүрт улыннан өчесе өйләнгән, бала-чагалары булып, Зәйнәп ханым тәрбиячесез калган. Шул мескин балаларның хәлләре ничек булачагы хакында уйлап утыра икән. Үзеннән туган балалар сугыш мәйданында һәр минут үлемгә хәзер булган вакытта, шулардан калган ятимнәр хакында мескинәнең аналык шәфкате илә уйлап утыруы миңа бик нык тәэсир итте. Шул вакытта Зәйнәп ханым үзе дә гөнаһсыз фәрештә шикелле күренә иде. Зәйнәп ханым саф җанлы төрек хатыныдыр. Андыйлар чын мәгънәсе илә ана һәм чын мәгънәсе илә хатыннардыр. Аллаһ бирсен дә, Төркиядә болар кеби хатыннар күп булсын!

Анатулының саф төрекләре – гаять шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм инсаниятле бер милләттер.

Бер-бер эш илә хастаханәдән чыгып китсәң, тизрәк кайтасы, шул саф күңелле яралыларны күрәсе килә. Хасталар арасында рәхәт була. Боларда булган дин, ватан мәхәббәте, бер-беренә шәфкать сөйләп бетергесез. Кешедәге кайгыдан тәэсирле булу боларда бик куәтле. Иртә берлә палатага керсәң, һәммә нәрсәне онытасың, гакылыңда фәкать шул сөекле хасталар гына буладыр. Бере артыннан бере уяна баралар. «Сабах шәрифләр *(иртәләр)* хәерле булсын!» – дип, безгә һәм дә бер-беренә хәерхаһлык телиләр. Иртә берлән ишетелгән шул сүзләр көн буена, музыка шикелле, колактан китми тора. Күзләрендә мәхәббәт, шәфкать күренеп тора. Боларны күргән инсан шатлана, шулар шикелле шәфкатьле, рәхимле буласы килә. Начар мөгамәләдә булган булсаң, үкенәсең, көн буе бик яхшы гына булып, бер-бер кешегә авырлык килердәй эш эшләмәскә тырышасың. Болар гаҗәп халык: беренең шатлыгы – икенчесенә шатлык, беренең кайгысы – икенчесенә кайгыдыр.

Ватаннары дошман кулына төшкән, харап ителгән яралылар да аз түгел иде. Бичаралар үзләре хастаханәдә, әмма гаиләләре, Аллаһ белсен, кайдадыр, бәлки, бөтенләй дөньяда да юктыр. Бу кеби мескиннәрдән безнең палатада икесе бар иде. Бере – өйләнмәгән, яшь кенә Танаш исемле бер рум (грек) баласы, икенчесе – гаилә хуҗасы Мөхәммәд ага. Боларның караватлары янәшә иде. Бу бер мөселман илә бер грек арасындагы дуслык бик куәтле иде. Боларны аерым куярга кирәк булган вакытлар булды исә дә, еглый-еглый, безне аермагыз, дип ялынып, һаман бергә калдылар. Хастаханәдә мөселман солдатлары илә христиан солдатлары арасында нәфрәт шикелле хиснең әсәре дә сизелми иде.

Мөхәммәд ага күп вакытлар уйга чума, зур күзләре яшь илә тула. Ахрысы, гаиләсе хакында уйлана иде. Танаш вә башкалар исә аның кайгысын таратырга тырышалар, чәй эчерәләр яки, янына утырып, берәр нәрсә сөйләргә тотыналар. Шулай итеп, Мөхәммәд аганың кайгысын таратып, үзләре дә шат була иделәр.

Иттифакчыларның[2] сугышып кергән җирдәге халык илә ничек мөгамәлә итүләрен

---

[2] Иттифакчылар – Сербия, Черногория, Греция һәм Болгариянең Төркиягә каршы хәрби-сәяси берләшмәсе (Балкан союзы).

Балкан төрекләренең Истанбулга качуы

Мөхәммәд ага үз күзе илә күргәнлектән, гаиләсе дә шул дошманнар тарафыннан юк ителгән дип уйлый вә бик җәфалана иде. Мөхәммәд ага бер көн хастаханәдән китәчәк. Кайтыйм дисә – гаиләсе юк, кайда барырга да белми. Бу уйлар да аны борчый иде булса кирәк. Анатулы хасталарының күбесе, гаять шәфкать илә һәм аның җәрәхәтләрен яңартмас өчен, бик сакланып кына, Мөхәммәд аганы хастаханәдән чыкканда, үзләренә – кайсы шәһәргә, кайсы – авылга кунакка чакыра: «Аллаһ бирер дә, гаиләң булыр», – дип әйтә иделәр. Кулларыннан килгән кадәр Мөхәммәд агага ярдәм итәчәкләренә, вакытлыча булса да, аны яхшы мосафир итеп, шәфкать-мәхәббәт илә тәрбия итүләренә һич шөбһә итәргә туры килмидер. Чөнки Анатулының саф төрекләре – гаять шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм инсаниятле бер милләттер.

Хәлил исемле бер хаста да һич хәтеремнән чыкмый. Гаҗәеп бер кеше! Һәркемгә лаек, йомшак сүз таба, кешене һич рәнҗетмәс. Аның җанының сафлыгы кешене хәйран итәдер. Укымаган-нитмәгән шул төрек мужиклары үзләренең саф күңелле вә шәфкатьле табигыятьләре илә кешене хәйранга калдыралар. Аларның мөгамәләләрендә нindидер йомшаклык, матурлык, инсанлык бар ки, ул, башка кешеләргә дә тәэсир итеп, инсанны рәхәт хәлгә китерә: яшьләре картларына, атага лаек хөрмәт күрсәтә, картлары яшьләренә угыллары кеби бик сөеп мөгамәлә итәләр.

«Әдернә китте!» – хәбәре килгән вакыт хасталар бик уңайсызландылар, елаганнары да булды. Хәтта хаста көенчә янә сугышка китәргә, Әдернәне кире алыр өчен барырга теләгәннәре дә аз түгел иде.

Рус газетасы укыганны күрсәләр: «Чит ил газеталары ни язалар?» – дип сорашырга тотыналар. Бервакыт рус газеталары: «Төрек гаскәре сугыш мәйданыннан кача», – дип язалар, дидем. Бичараларның күзләре яшь илә тулды. Соңрак: «Сугышның иң кызу вакытында офицерлар гаскәрне ташлап качалар, офицерсыз гаскәр нәрсә эшләргә дә белми, мәгънәсез җан корбан иткәнче, алда берәр җиргә ярармын фикере илә, табигый, кача башлый. Шуңа күрә бөтен гаеп офицерларда», – дип сөйли иделәр.

Кайбер гаскәр һичбер тупсыз калган, дошман исә туплардан яңгыр кеби яудырып тора. Шул хәлдә дә төрекләр качмый, тәмам кырылып беткәнгә кадәр сугышкан җирләр дә булган. Чөнки башлыклары булган офицерлар яхшы кешеләр туры килеп, үзләре дә ут эчендә йөреп, гаскәргә үрнәк булганнар. Шуңа күрә төрек гаскәренең башына килгән хурлыкларның сәбәбен, минемчә, гаскәрдән эзләргә кирәкми. Ул сәбәпләр башка җирдәдер, чөнки төрек гаскәре куркак түгел, батырдыр.

Күп вакытта, операция ясаганда, хасталарның сабырлыгына докторлар хәйран кала иделәр. Исмәгыйль исемле бер хастаның кул сөякләрен шрапнель ватып бетергән, җәрәхәтенә карарга куркыныч. Бер көн доктор Исмәгыйльнең җәрәхәтен бәйләгәндә эчтә бер ватык сөяк барлыгын аңлаган. Шуны алырга кирәк булган. Сөяк ватылган булса да, бер кырые бөтенләй тәннән аерылмый, сеңергә бәйләнеп тора икән. Доктор, сөякне кыскыч илә эләктереп, бора башлады. Ниһаять, сеңгер өзелеп, сөяк алынды. Шул вакытта бичара Исмәгыйль һич тавыш чыгармый сабыр итеп торды. Моның кеби хасталар бик күп. Боларның һәркайсы хакында язачак булсаң, әлбәттә, бик озын булачактыр. Кайвакыт, аптырап: «Операция вакытында бик тыныч кына тордың, бик авыртмады булса кирәк», – дип сорасаң: «Авыртмасмы, бик авыртты! Әмма зәхмәт чигүеңне кешегә белдерергә ярамый, аны ачык бер Аллаһ белергә тиеш. Безнең дошман белән сугышучыларның бөтен чиккән зәхмәтләре бер Аллаһ өчендер», – дип әйтәләр.

Бу кадәр яхшы сыйфатларга ия булган төрек гаскәре бераз укыган булып, укый-яза да белә торган булса, болар хакыйкатьтә беренче гаскәр булыр иделәр.

Хасталар арасында Траблистан кайткан гаскәриләр дә була иде. Бичаралар, ватаннарыннан еракта, ватан, дин юлында сугышып зәхмәтләр чигеп, Истанбулга кайтканнар. Боларның бераз ял итәргә, әлбәттә, хаклары бар иде. Ләкин ватан бу кадәр куркыныч астында икән, алар үзләренең арганлыкларын, хәлсезлекләрен онытканнар. Һич шикаять итмәстән, ватанны саклар өчен, Балканда булган сугышка киткәннәр.

***

Бу сугыш төрек гаскәре өчен никадәр фаҗига булмасын, гаскәрнең яхшылыгына, аның тарихи шөһрәтенә һич зарары тимәскә тиештер. Төрекләр әүвәлдә ялгыз булсалар, бу сугышта да алар үзләре генә калдылар. Балкан иттифакы бу сугышка изелгәннәрне коткару төсе бирде. Сугыш максатын һич җир-фәлән алу түгел, бары тик салибне *(тәрене)* – ай коллыгыннан, җәберсетелгәннәрне залим кулыннан коткару өчен итеп күрсәттеләр. Бөтен дөнья шуңа ышанды! Шуңа күрә күпчелек Балкан иттифакы тарафында булды. Ләкин бу алдану озакка бармады: төрек белән сугыш бетәр-бетмәс, иттифакчылар алынган җирләрне бүләргә керештеләр. Башта бер-беренә, кардәш, дип йөргән булсалар да, соңрак, сөяк өчен талашып, үзара сугышырга керештеләр һәм үзләренең кем булуларын бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Мәдәни Яуропа гәзитләре: «Исламның соңгы көннәре, ислам инде үлем түшәгендә, ислам инде бетсен...» – дип, исламга авыр нәрсәләр яздылар, аны хур иттеләр. Яуропада ислам дигән сүз мәгънәсез бер сүз булып, мәйданда фәкать христиан булырга тиеш дигән фикерне ачыктан-ачык әйтеп күрсәттеләр. Без, шәрыклылар да, мәдәни Яуропаның инсан дигән сүзгә биргән мәгънәсен аңлап калдык. Бу да – зур дәрестер.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Татар матбугаты тарихы

«ТӘТЕШ ОЕШМАСЫ» ГАЗЕТАСЫ

Газета 1917 елның 15 маенда Казанда чыга башлый. Шигаре – «Йир һәм ирек!» Нашире һәм мөхәррире – «Казанда Тәтеш өязе мөселманнары оешмасы» идарәсе.

«Тәтеш оешмасы»н чыгаручылар арасында мәгърифәтчеләр **Маһруй Мозаффария, Мозаффар Мөштәриев, Солтан Гарифуллин, Исхак Казаков**лар була. *«Тәтеш өязендә укытучы мөгаллим вә мөгаллимәләргә үтенеч. Иптәшләр! Авылыгызда һәм тирә-якта булган хәбәрләрне, вакыйгаларны «Тәтеш оешмасы»на язып йибәрегез! Өязебезнең караңгы почмакларын үзегезнең тугры каләмегез берлән бергә яктыртып бирегез! «Тәтеш оешмасы» идарәсе сездән шуны үтенә»,* – дигән язмадан газетаның хәбәрчеләре җирле укытучылар булган дип уйларга нигез бар.

«Татар энциклопедия»сендә 1917 елда Казанда Тәтеш өязе мөселманнары оешмасы рәисе, «Тәтеш оешмасы» газетасы мөхәррире **Гыйльметдин Шәрәф** (1885-1942) булганлыгы хакында әйтелә.

Җир, Учредительное собрание сайлауларында катнашу кебек сәяси язмалар белән бергә, «Тәтеш оешмасы»ның һәр санында да «Ил хәбәрләре», «Казан хәбәрләре», «Тәтеш хәбәрләре», «Авылдан тавышлар» исемле сәхифәләрне күрәбез. Барыннан да

№ 4 1917
ТЕЛЕФОНЪ № 11-38
Казань, Евангелистовская улица
ТИП. „МААРИФЪ". „ТЕТЮШЪ ЮЮШМАСИ"

«Тәтеш оешмасы» газетасы. 1917 ел

Гыйльметдин Шәрәф (1885-1942) – Тәтеш өязенең Кишер Аксуы авылыннан. Казанда «Матбагаи Шәрәф» (1906-1913) басмаханәсен оештыручы һәм аның җитәкчесе. Милли Шура әгъзасы. 1920-1927 елларда Казан хосусый коммерция банкы идарәсендә рәис урынбасары.

Хәмид Мозаффар улы Мөштәри (1900-1981) – 1917 елда Тәтештә ачылган мөгаллимнәр курсында укыта. Соңрак татарлар арасында беренче физика-математика фәннәре докторы, профессор булып танылa. 1946-1972 елларда – СССР ФА Казан филиалының физика-техника институты директоры.

бигрәк, газета Тәтеш өязендәге мәгариф мәсьәләсен күз уңында тоткан. Газетаны чыгаруда катнашкан һәм Тәтешкә китеп укытучылар әзерли торган ике айлык курсларда белем биргән Маһруй Мозаффария *«өязнең кырыклап авылында булган, хатын-кызларны үз хаклары һәм азатлык өчен көрәшергә, укырга, белем алырга өндәгән»*[1]. Тәтеш өязе мөселман укытучыларының өч мәртәбә булган җыены, Тәтеш мөселман укытучылары курсы, «Тәтеш өязе укытучыларының оешмасы», Тәтеш мәктәпләр шурасы, «Тәтеш мөселман укучы яшьләре берегенең эшчәнлекләре дә газетада даими яктыртылган.

Исмәгыйль Рәмиев «Тәтеш оешмасы» хакында: *«Милли-демократия гәзитләреннән берсе һәм сулрагы. Күләме бик кечкенә: 20х13, наборы 18х11 квадрат. Замандашлары арасында җиңел, простой тел белән язган гәзитләрдән берсе. Техникасы матур, курчактай гәзит иде. Атнага бер тапкыр чыкты. Казанда «Мәгариф» типографиясендә басыла иде. Еллык бәясе 5 сум, берәмләп 6 тиен»*, – дип язган[2]. Газетаның аерым саннары, сәяси эчтәлекле китаплар белән бергә, Тәтеш өязендәге 120 мөселман авылына берәр данә таратылуы мәгълүм. Басманың кайбер нөсхәләре уртасына: *«Гәзитәне җыелып укыгыз – үзегез укыгач, башкаларга бирегез!»* – дип тә язылган.

«Тәтеш оешмасы»ның 1917 елның 22 декабренә кадәр барлыгы 18 саны дөнья күргән.

ТӘТЕШ ӨЯЗЕ МӨСЕЛМАН УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ ҖЫЕЛЫШЫ

1918 елда 25 июньдә Тәтеш өязе укытучыларының съезды булды. Шул мәҗлесне алып барыр өчен, рәислеккә Мозаффар әфәнде Мөштәриев, аңа могавинлеккә (*урынбасарлыкка*) Кариб әфәнде Вәли, сәркатиплеккә Фәйрүзә ханым Маликова, аңа могавинлеккә Маһруй ханым Мозаффария сайландылар.

Җыелыш түбәндәге карарларга килде: 1) Тәтеш өязе укытучыларының оешмасын тәшкил кылырга, идарә әгъзалары сайланып, устав төзүне идарәгә тапшырырга; 2) Тәтеш укытучыларына Казандагы «Мәркәз бюро»га кушылырга; 3) әгъзалык бәдәле *(хакы)* өчәр сум алынып, шуннан 50шәр тиен «Мәркәз бюро»га бирелергә; 4) укытучылардан Мәктәп шурасына сайланган әгъзалар: Мозаффар әфәнде Мөштәриев, Кариб әфәнде Вәлиулла, Нәгыймә туташ Байдамшина, Латыйф әфәнде Маликов, Сафа әфәнде Бакый; 5) Тәтеш өязе мәктәпләренең эчке һәм тышкы

[1] Мәхмүтова А. Вакыт инде: без дә торыйк... – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – Б 360.
[2] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. – Казан: Гажур, 1926. – Б.65.

Тәтеш шәһәре. Абдулла Дубин архивыннан

эшләрен юлга салуны Мәктәпләр шурасы карамагына тапшырырга; 6) Тәтеш өязендә булган мәктәпләрнең хисабын җыеп алу, ил мөселман комитетлары аркылы алынып, мәктәпләр шурасына тапшырылыр; 7) сәркатипкә айга 30 сум бирергә, идарә әгъзаларына җыелыш вакытларында өчәр сум көнлек бирергә (өйләреннән чыкканнан кайту көненә кадәр); 8) Тәтеш өязе укытучыларының сайланган идарә әгъзалары: Мозаффар әфәнде Мөштәриев, Латыйф әфәнде Маликов, Кариб әфәнде Вәли, Нәгыймә туташ Байдамшина, Сафа әфәнде Бакый. Наибләр *(ярдәмчеләр)*: Кадыйр Хәлидов, Исмәгыйль Мөштәриев, Фәйрүзә Маликова, Шәһит Гаделшин, Гобәйдулла Хәбип; 9) Тәфтиш *(тикшерү)* комиссиясенә сайланган әгъзалар: Солтан Гариф, Кәрим Җәгъфаров, Маһруй Мозаффария. Наибләр: Каһир Заһиров, Сәгадәт Габдуллина, Әбелмәхҗән Шәфигуллин.

Солтан Гарифуллин.
Тәтеш оешмасы. – 1917. – 7 июль.

ТӘТЕШ ХӘБӘРЛӘРЕ

Тәтештә 15 июльдә мөгаллимнәр курсы ачылды. Курска сиксәнгә якын укучы килде. Инде укучыларны үзләренең белемнәренә карап ике бүлеккә аердылар.

Ошбу көннәрдә Тәтештә Сафа әфәнде Бакый һәм **Хәмид әфәнде Мөштәриев**ләр тарафыннан уку-язу белмәгән дәү агайлар өчен кичке курслар ачылачагы ишетелде.

Тәтеш оешмасы. – 1917. – 3 август.

***

Тәтеш өязе мөселман мәктәпләре мөдире Исхак Казаков тарафыннан өязгә ошбу кешеләр чыгарылды: Шиһап Шәрәф, Җәләл Таһиров, Шаһит

Мозаффар Таҗетдин улы Мөштәриев (1863-1937) – Тәтеш өязенең Үтәмеш авылыннан. Истанбулда белем ала. 1915 елга кадәр Казанда мөгаллимлек итә. Аннан соң Тәтештә, Келәнче авылында укыта, 1917 елда Тәтеш өязендә укытучылар курсы оештыра. Соңрак мөгаллимлек эшен Оренбург, Ташкент, Казан шәһәрләрендә мәктәп мөдире, татар һәм рус телләре укытучысы буларак дәвам итә.

Гаделшин, Мозаффар Мөштәриев, Сабир Салихов һәм Абдуллиннар. Бу әфәнделәр, мөселман авылларында йөреп, авылларның мәктәпләре хакында мәгълүмат җыеп, Мәктәпләр шурасына доклад бирәчәкләр.

Тәтештә 14 сентябрьдә Тәтеш укучы мөселман яшьләре, бердән, тәтешлеләрнең күңелләрен ачар өчен, икенчедән, Тәтеш мөселман укучы яшьләренең береген матди җәһәттән «боекмас» хәлгә китерер өчен, кичә ясадылар. Кичә күңелле генә барып чыкты.

Тәтеш оешмасы. – 1917. – 26 сентябрь.

ӨЯЗДӘ УКЫТУГА СУСАУ

Авыллардан 262 укытучы сорыйлар. Тәтеш өязендә бу ел яздан башлап өяздә мәктәпләр ачарга йөрүчеләр земстводагы мөселманнар акчасын үз илләремезгә кайтарырга гайрәт итүчеләр, өязнең мондый хәлгә әйләнүен һич көтмиләр иде.

Бу нинди гаҗәп эш! Рус кулына кергәннән бирле бер уянмый йоклаган бөтен Тәтеш өязе мөселманнары бүген уянганнар. Бүген үзләренең дөньяда яшәргә омтылуларын күрсәтәләр, бүген үзләренең өстенә капланган кара пәрдәләрне ертып, ак, пакь дөньяга чыгарга ашкыналар. Өяздә укытырга теләп, Мәктәпләр шурасына 250 мөгаллим вә мөгаллимә укытырга урын сорыйлар!

Гаризаларында шундыйлары бар: «Мин әлегә кадәр чит өязләрдә укытып йөрдем, инде мин үз илемдә агарту өчен җаным-тәнем берлән бирелеп хезмәт итәргә үз-үземә сүз бирдем. Миңа бер урын күрсәтеңез», – ди.

Янә берсе: «Мин 6 ел мөгаллимлек иттем. Мәдрәсәне бетергән идем. Инде мин, андагы жалуниянең күплегенә дә карамый, үземнең туган илемә кайтып, бирелеп хезмәт итәргә чын иман берлән керешәм. Жалуния нинди генә булса да мин разый», – ди.

Бер карт остазбикә Мәктәпләр шурасына яза: «Сезне һәр җирдә мәктәп ачасыз, дип ишеттем. Безнең авылымызны кызлар мәктәбе ачудан мәхрүм итеп калдырмасаңызла. Мин үзем картайдым, укыта да алмыйм, күзем дә күрми. Безнең авылга кызлар мәктәбе ачсаңыз, Аллаһ ризалыгы өчен, мин дә картымнан калган йортымның яртысын кызлар мәктәбе өчен бушлай биреп торыр идем. Зинһар, кызларымызны укытудан мәхрүм итмәсәңезлә», – ди. Бу нинди изге карчык! Бу – Аллаһның җиргә төшкән бер фәрештәсе! Бу гаризаны укыгач, шатлыгымнан ике күземә мөлдерәп яшьләр килде. Бөтен вөҗүдем шатлык берлән, өяземезнең алга атлавына ышанган бер рәхәт берлә тулды.

Шул кузгалган авылларны бер күз белән барысын күрәсем килә башлады. Күңелем аның каршысына барып кулларны үбеп рәхмәт укырга хәзерләнә башлады.

«Бәгъре Янган».
Тәтеш оешмасы. – 1917. – 10 октябрь.

ТӘТЕШТӘ УКЫТУЧЫЛАР ҖЫЕНЫ

Сентябрьнең 27ендә Тәтеш өязе мөселман укытучыларының 3нче гомуми җыелышы булды. Гариф әфәнде Халиди рәислеге белән мәҗлесне ачып, гомуми җыелыш өчен президиум сайларга кушты. Президиумга Исхак Казаков, Кариб Вәли, Шәһит Гаделшин, Кадир Халидовлар сайландылар. Казаков мәҗлесне тыныч алып бару тугрысында байтак сүз сөйләгәч, Кариб әфәнде гомуми җыелышта каралачак мәсьәләләрне укып чыкты. Куелган мәсьәләләр тыныч кына мәхкәмә вә мөзакәрә соңында, түбәндәге карарлар чыгарылды:

Бу сәнәдән *(елдан)* муллаларны рәсми мөгаллим итеп таныргамы? Бу мәсьәлә

Маһруй Габделвәли кызы Мозаффария (1873-1945) – Тәтеш өязенең Олы Тормы авылында мулла гаиләсендә туа. Казанда «М.Мозаффариянең абыстайлар мәктәбе»ндә, Хәдичә Әхмәрованың хосусый рус-татар мәктәбендә татар теле һәм дин сабагын укыта. «Мәшһүр хатыннар» исемле шигыре «Әл-Ислах»та басылып чыга. 1917 елда Тәтештә ачылган укытучылар курсында татар теле укыта. Мөгаллимәнең «Тәтеш оешмасы»ның беренче санында «Тәтеш өязе мөслимә кардәшләрем дикъкатенә» исемле мәкаләсе дөнья күрә.

аерым секция тарафыннан тикшерелеп, 4 маддәле резолюция кабул ителде: 1) рәсми укытучы булып мөгаллим-мөгаллимәләрдән башка кешеләрнең укытуга катнашырга һич хаклары юк; 2) әүвәлдән яңа тәртип белән укыткан бер мулла, моннан соң да рәсми мөгаллим булып калырга теләсә, ул мулла үзенең муллалык лөзүмен ташларга тиешле; 3) әгәр бер мулла моңар кадәр кимчелексез яңа тәртип белән укытып килгән булса, рәсми рәвештә ачылачак мәктәпләргә аңлы укытучылар җитешкәнчегә кадәр, аңар шул авылда мөгаллимлек итеп торырга имкян *(мөмкинлек)* бирелер; 4) һәр мулла, үз мәхәлләсендәге рәсми мәктәпкә дин мөгаллиме сыйфаты белән керергә хаклы булып, земство тарафыннан үзенә билгеләнгән вазифәсен *(хезмәт хакын)* алыр, укытучы вазифәсенә катнашмас...

Гомуми җыелышны алып баручылар: Исхак Казаков, Карибулла Вәли, Шәһит Гаделшин, Габделкадир Халидов.

Тәтеш оешмасы. – 1917. – 1 ноябрь.

*Кереш мәкалә һәм текстларны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■



М.Фәйзи көндәлегенең 1922 елгы февраль аеннан башланган бите

Мирхәйдәр Фәйзи: «Уразалар мөкатдәс миңа!»

1922 ел, гыйнвар

Максим Горькийның «Ана»сын укый башлап, 200 бит укыгач ташладым. Революционный булганга яратмадым. Мин халыкларның табигый гадәт-җолаларына гаид нәрсәләрне яратам. Төрекчә «Ягъкуб һәм Зурия» исемле тарихи пьеса укыдым.

Орскига кайтып яшәгән алты айлык тормышымда алты якын кешем җир куенына керде. Әни, Шакирҗан абзый, Нурания, Назим, Сабира җиңгиләр янына Әхмәтгәрәй абзыйның да рухы кушылды. Һич чара юк. Калганнар тәгәлрәк яшик инде.

Ачлык көчле. Халык эт, песи итләре, сөякләр, тиреләр ашый. Үлүченең хисабы юк. Нинди бер газапка килеп кумдең, Ходаем. Тимер юл йөрми. «АРА» килеп, эшен юлга куя алмады. Хәлләр мөшкел. Тук кеше аз. Ай, бер туйганчы күмәч ашасаң! Тик шушы кадәренә дә шөкер. Күмәчтән бөтенләй өзелмәү дә – бер бәхет. Бик тук булмасам да, ач түгелмен әле. Күз – дәрья бит, нәфес – марҗа бит – төрле нәрсәләрне сагынып, үзәкләр өзелеп китә.

Онның поты ике миллионга сәлам бирә, кадагы – 50 мең. Ак бодай күмәче – 40 мең; арыш ипие – 30 мең; ит: кадагы – 20-25 мең; шикәр – 120 мең; монпасье – 160 мең; өрек – 90 мең; манный ярмасы – 100 мең; тизәк: йөге – 100 мең; печән – 700 мең; сөтнең бутылкасы – 12 мең; кәрәсин: кадагы – 40 мең.

21ендә иртәнге чәйне ап-ак базар күмәче белән эчтек. Нинди зур бәхет! Төштә пилмән пешердек. Эчләр тулды. 50шәр пилмән ашадык. Җомганы шулай бәйрәм иттек.

Кыйраәтханәгә *(китапханәгә)* барып утырдым. Үземнең Юлыктагы кыйраәтханәмне сагынам. Ах, нинди дус идек без аның белән, ничек яратадыр идем мин аны. Рәхәтләнеп, рухланып утырадыр идем. Сагынам, җаным!

Маһруйларга бардым, сөйләшеп рәхәтләндем. Таштугай чиясенә болганган май белән чәй эчерделәр. Пилмәннән соң сусап торган кешегә килеште.

Маһруй авылда хезмәт итте. Башкорт хатыннары, агайлары аның хезмәтен онытмый, кучтәнәчләр – майлар, казылар-фәләннәр җибәрәләр. Күңелләр бик хөрмәт белдерәләр. Мин дә, чын көчне түгеп, авылда хезмәт иттем. Миңа да күңелсез булмас иде хезмәтемнең тиз онытылмавы. Ләкин не стоит язып торырга. Хезмәтләремнең файдасын күрүдән мәхрүм ителеп яратылган бер бәндәмен, ахры, инде мин.

« ***Үткәнне бәхет санап сагынам. Сабый чаклардагы уразалар, кышкы ураза, сәхәргә торулар, күңелле һәм матур тавышлар белән укылган аятьләр, дини карашлар белән чолганып үткән көннәрдәге хатирәләр күңелгә үз тоела. Моңлы мөнәҗәт һәм аһаңе белән намаз, тәмле хөрмәләре белән чәй, сәхәр, авыз ачу, бәйрәмнәре белән – уразалар мөкатдәс миңа.***

22сендә Нигъмәтуллиннарга барып, Гөлсем, Галия туташлар янында озак утырдым. Укырга китаплар алдым. Өйгә кайткач та өч томнан гыйбарәт булган «Габделхәмид Сани дәвер солтанаты, хәят хосусиядә сәясиясе» исемле төрекчә тарихны укырга тотындым.

Бүген иртә белән берәр төче күмәч, берәр чашка сөт һәм сөтле чәй; төштә – төйгән итле, бәрәңгеле аш; кич чөгендер кабып, сөтле чәйләр белән тукландык.

М.Фәйзи оештырган үзешчән түгәрәктә катнашучы Орск яшьләре

> «*Сагындым, сагынып киттем гармунны, халык музыкасын һәм халык моңнарын.*

23ендә көн буран: көне буе пич башында утырып, «Габделхәмид»не укыдым. Бүгенге көн тәртибе: иртә – чәй, бер чынаяк сөт, бер төче күмәч; төштә – помидор һәм бәрәңгеле шулпа, ит, тутырма; кич – монпасье белән чәй.

Ай, базарда тәмле нәрсәләр күп. Тәмле исләр бөркетеп торган биек-биек ак күмәчләр, кондитерский нәрсәләр, кәнфитләр, майлар. Акча да күп булып, тыгынганчы ашасаң икән шуларны. Идеал йолдызы балкыр иде.

27сендә иртә белән каклы вә май сумсасы, май бавырсагы пешердек. Бик тәмле булды. Бер стакан каймак ашадым.

Бүген кыйраәтханәдә Казанда чыккан «Кызыл яшьләр» газетасын укыдым. «Кызыл яшьләр» тирәсендә чуалырга бик яратам. Шул юлда эшләргә ашкынам. Кайчанга кадәр Орскида изелермен? Кайчан гына рухым бәйрәм итәр? Кайчан, теләгемә ирешеп, күңелем күтәрелер? Бер уйланам да, ярый инде заманына күрә!

28ендә, төштән соң, Гөлсем туташларга бардым. Галия, Мәрьям, Шәрифҗаннар да булды. Галия мандолина уйнады, Гөлсем белән Шәриф «Сәгать чылбыры» көен бик матур җырладылар. Ай, шул көйне яратам. «Читен хәл», «Авыр, дускаем!» дигән җырлары йөрәкләрне дер селкетә.

31ендә Маһикамал җиңги бездә ята әле. Хатын-кыз туганнар эчендә иң өлкәнебез булып калган бу күңелле җиңги белән көннәр күңелле уза. Үткән дәверләрне сөйләп рәхәтләнәбез. Бар иде шул заманнар...

Кыйраәтханәгә барып, китаплар алып кайттым. Көне буе, төне буе укып, төрек мөәррихе (тарихчысы) Әхмәд Рәфикъның «Ләлә дәвере» исемле тарихи әсәрен бик яратып, ниһаяләп куйдым. Укырга күңелле нәрсә.

Бүген миңа ике төче күмәч, бер чүрәк, ит, шулпа, сөтләр ашау насыйп булды.

1922 ел, февраль

2сендә. Бер нәтиҗә дә юк. Аптырадым инде, һич эшем алга бармый. Бәхетем ялтырар микән бер? Көчем зәгыйфь булса да, дәртем белән өметем көчле.

Элек Ходайдан теләп җуаныладыр иде. Хәзер андый нәрсәләргә илтифатсызлык. Эш үзең булдыра алуыңа гына терәлде. Әмәлләп булмый җөдим бит әле. Уйлап торсам, исем китә: 300 ел элек сызылган бер сызык эчендә мәҗүс яшәп, бер бәндәнең бармак ишарәсенә карап тилереп маташ, имеш. Әллә кай заман халыклары өчен төзелгән бер партияне – мәсләкне хәзерге заманга кабул итеп җенлән, имеш*. Никадәр садә тилелек, никадәр аңгыралык. Минем гакылым ул нәрсәләр алдында сәҗдә итми инде. Көчләнеп ышаныр хәлем юк. Тик асаре гатика (борынгы һәйкәлләр. – *Ред.*) алдында тәэсирләнгән кебек, эти-әниләр тарафыннан сөелгән дини җолаларның бәхриясенә мәхәббәт асрыйм. Үткәнне бәхет санап сагынам. Сабый чаклардагы уразалар, кышкы ураза, сәхәргә торулар, күңелле һәм матур тавышлар белән укылган аятьләр, дини карашлар белән чолганып үткән көннәрдәге хатирәләр күңелгә үз тоела. Моңлы мөнәҗәт һәм аһәңе белән намаз, тәмле хөрмәләре белән чәй, сәхәр, авыз ачу, бәйрәмнәре белән уразалар мөкатдәс миңа.

7сендә Фәтхуллин «Галиябану»ның авторские 50 000 сумны яңа тапшырды. Вакы-

*Сүз большевиклар партиясе турында бара. – Ред.

Мирхәйдәр Фәйзинең апасы Фатыйма

тында биш кадак онлык иде, хәзер бер кадак онлык акча. Театр уйнарга димли. Үзем дә катышам, ди. Тагы алдаргамы?

8ендә иртәнге чәйдә берәр стакан куе каймак ашадык. Чынлап та спектакль кую уена төшеп, оештыру чарасына керешеп карадым. Руфгатькә бардым. Гөлсемнәргә кердем. Буракановка юлыктым. Бар да риза. Бар да, зинһар, башында тор, вөҗүдкә чыгар, диләр. Гөлсемнәрдә Шәриф, Мәрьям, Маһруй, Чандыз, Җамаллар да бар иде. Күңелле утырыш булды.

Апайның бармагы шешү аркасында, йорт эше минем өскә төшеп тора. Пич тирәсендә, күнекмәгән эш белән арып, эт булып бетәм, кырык төрле вак эш маңгайдан тирләр агыза. Өлгерә алмый җөдәдем. Бит, башка кадәр корым белән буялам. Абау җаным, бик кыен икән бу эш.

9ында театр эшеннән бик тиз айныдым. Орски өчен көч түгү әрәм. Орски халкы каршында рух азыгына, аның каһарманнарына бәһа бармыни? Моңарчы кырык кат сыналмадымыни инде ул?

Төштә кабак бәлеше пешердек. Бик тәмле булды. «Һәмзад» исемле төрекчә 700 битле бер роман укый башладым.

> «*Юлык тәмам изелгән, ачлыкның тырнагы астына бөтен күңелле хосусиятьләрен җуеп, һәлакәт чокыры булып калган. Төрле сәбәпләр белән, мин киткәннән алып, 500 кеше үлгән. Ачлыктан көн дә биш-алты кеше үлеп тора. Махсус кешеләр һәммәсен бер чокырга ташлый тора.*

10ында Орскины җенем сөйми башлады. Йә Алла, бу чаклы рухани азыксыз җир булырмы? Китәргә урыным да була торып, китә алмый газапланам бит. Җанымның никадәр газаплануын сөйләп бетәр хәл юк. Очып кына китәр идем, кулларым канат түгел.

Өй – тар, ярым суык, язар урын юк. Дәфтәрләр майга буялып бетә. Уйлар әллә нинди ваклыклар арасында тарала. Их, ялгыз гына бер бүлмәдә торуны никадәр яратам мин. Их, Юлыкта рәхәт иде тормышым. Монда тән азыгы яхшы, анда – рух азыгы. Икесен бергә җыйганда, нинди шәп буласы. Ләкин ашарга күмәч белән ит булса, рух азыгы ягын теләр идем мин.

Бүген «Һәмзад»ны укып чыктым. Гаилә хәятенә гаид бу мөһим романны яраттым.

Йорт эчендәге эшләрне карарга туры килә. Шулай ук сыер карыйм, астын көрим, печән салам. Тик бер дә яратмыйм. Ихлассыз гына, мәҗбүри генә йөрим. Тормыш тарихымда бер чаклар бу эшләргә зур һәвәс белән керешеп карадым. Саусызлыгым манигъ булды *(мөмкинлек бирмәде)*. Шуннан бирле, ул эшләр белән бәхет таба алудан кулны селтәдем. Хәзерге мәҗбүри генә селкенүләрем җаныма бер дә зәвык бирми. Бәхетемне башка юллар белән көтәм. Ләкин язмыш йомычка кебек тугландыра үземне. Их, тормышмы бу?

13ендә, көпә-көндез, бикле сарайдан атыбызны алып чыгып киттеләр. Бөтен байлык бер ат белән бер сыер иде, аның да берсеннән колак кактык. Йортыбызны да алдылар. Менә безнең тормыш нинди хәлдә хәзер.

«Тарихи сималар»ны укып чыгып, «Фәләкәт сәнәләре»н укый башладым. Әхмәд Рәфикъ бәй җаныма азык бирә башлады. Җыйнак кына тарихи сәхифәләрен яратып укыйм.

17сендә тегермәнгә тартырга бер пот бодай илттек. Ашыйсым да килә, ай, әллә ни – әни пешерә торган хәлвәне...

Кыйраәтханәдән китаплар алып кайтып, «Арыклык» исемле берсен укый башладым. Төрек әдәбияты безнекеннән күпкә баерак. Табигъләры *(китаплары)* матур, нәфис. Төрле фәнгә гаид матур-матур нәрсәләр табып укырга була. Безнең кебек урысчасы сай кешеләргә ярап тора ул.

Бүген борынгы көйләрдән «Хәмдия» көенең тарихына гаид пьеса язуга керештем. Бәхетле тәмамлык насыйп булсын!

18ендә, көн җылытып, эретә башлады. Сагындым, сагынып киттем гармунны, халык музыкасын һәм халык моңнарын. Валлаһи, ике айдан бирле колагым гармун тавышы ишеткәне юк. Менә сиңа тормыш! Көн дә пианино тавышын ишетәм, ул үзебезнең өйдә генә. Ләкин ул, матур булса да, халыкныкы түгел шул. Аның белән татар моңнары игез түгел шул. Сагынам, дуслар, сагынам, авыл тормышын...

19ында Мәфтүхәләргә, Кәримәләргә, Маһруйларга бардым. Маһруйларда аш ашап, чәй эчтем. Ләкин Сәгыйдәгә ачуланып кайттым.

М.Фәйзинең «Урал буенда» исемле дүрт пәрдәлек пьесасының афишасы. Спектакль В.Г. Мортазин-Иманский идарәсендәге Башкорт-татар драма театры артистлары тарафыннан куелган

Үзем дә, апай да, Закирҗан да тиф йә башка авырулар белән авырып китә күрмик инде дип теләмәкче булам да, ләкин кем алдында чүгенеп теләргә белмим. Ходайга ышанмагач, уңайсыз икән ул! Һәрхәлдә, берәребез авырып китә күрмик инде. Мин дә китә алмый бүленеп кала күрмим. Авыру күп, эләктереп ала күрмәсен! Ходаймы, табигатьме, дим, дикъкать итә күрегез бу теләкне!

Кич бер стакан сөтне талкан белән, бер стакан сөтне арыш ипие белән ашадык.

М.Фәйзи,
Г.Исхаков,
Г.Мангутов.
Орск

20сендә Орскидан туйдым, Юлыкны, андагы дусларны сагынам. Гармуны белән Вәли, Гәрәйләрне; скрипкасы белән Габдрахманны; җырлары белән Мәүлетдин, Гали, Хәйдәр, Вәли, Гәрәйләрне; биюе белән Хөсәен, Гобәй, мулла Гомәрләрне; курае белән Заһид, Мусаларны сагынам. Ник язмыш минем теләгемә шулкадәр каршы килә?! Җимереп-җимереп бетәр идем киртәләрен, ай, көч юклыгы! Фәләк *(язмыш)*! Изә алмассың минем рухымны, боза алмассың минем дәртемне! Сау булсам, җитәрмен теләгемә!

23ендә «Хәмдия»мне язып беттем. Бер пәрдәле драма булды. Хәерле, мәнфәгатьле эш булсын!

Иртүк базарга чыктым. Бөтен көчемне сарыф итеп, китүче эзлим. Табылмый да табылмый. Һидаят озакламый ясачак «вечер»ы белән бәшарәт *(шатлыклы хәбәр)* бирде. Бирсен Ходай! Гыйбадулла исемле Акъярга баручы белән сөйләшеп карадым. Акъярга

кадәр 500 000 сорый. Мин 300 000нән артык бирерлек хәлдә түгел. Алай да әле Акъярдан арыга ничек буласын Ходай белә.

24ендә иртүк барып, Гыйбадулла белән 300 меңгә килештек. Әшәр-өшер хәзерләнеп, тын да ала алмый, апайның пешергән коймагы белән рәхәтләнеп чәй дә эчә алмый, нибарысы 450 мең сум акча белән өйдән чыгып киттем. Хуш, апай! Хуш, әнкәемнең яшәгән йорт-җире! Юлларым уң булып, бәхетемә аз гына булса да ирешеп, саулыкта күрешә алыйм!

Җылгалары агып яткан Орски урамнарын калдырып, юлны дәвам иттек. Борынгы Федор Егорыч утарында чәй эчәргә туктадык. Өйдән алып чыккан кабак пироглары ватылып беткәннәр, бөтенесен берьюлы ашарга туры килде. Өйдә үлчәп кенә ашап йөргән кешегә, бер рәхәтләнеп туйганчы ашарга сылтау булды. Шуның белән бәрабәр, каладан аерылу белән, гел ашауны гына уйлап тору бетеп китте. Әллә ничек җиңел булып, иркен сулап калган кебек булдым.

Күкшелдә Шакир абзыйга төштек. Ачлык булган илнең күңелсез картиналары авылларда да арттан куып йөри. Гел күңелсез хәбәрләр ишетелә.

25ендә иртә белән кәефсезрәк тордым. Таңнан чәй эчеп, юлны дәвам иттек. Турат суын чыкканда пимам белән бозга баттым. Акъярга кадәр 12 чакрымны сулы пима белән барырга мәҗбүр булдым.

Акъярга җитеп, Габдрахман кода Нураевка төштем. Өй һәйбәт, күңелле. Сыйлар мөкәммәл булачак. Әмма бернәрсә ашыйсы килми. Иртә белән бер төче күмәч кенә ашап чыккан хәлдә, төш узып та ашау дәрте кузгалган юк. Ни хикмәт, өйдәге сәгать саен ашап тору кайгысы кайда югалды бу? Тиф белән авырганда да хәтта аппетит бетмәгән иде, нинди гаҗәп хәл!

Юлыкларны очрату өчен, тиз генә базарга чыктым. Әхмәдулла Әдһәмовны күрдем. Юлыктан ике генә кеше бар иде. Өстәвенә, кәеф юк. Башым әйләнә. Тиф эләккәндер, кеше кулларында, хәтта юлда авырып калам, күрәсең, дип куркам. Кушти Әхмәт белән очраштым. Юлыкка алып барырга бер миллион сум сорый. Рухлар төште, аптыралды: нишләргә? Ахыр, ике ашъяулык, чалбар, толыпларымны заклад салып, утырып чыгып киттем. Менә тәвәкәлләп аз гына акча белән юлга чыгуның нәтиҗәсе! Юлыкта ничек табып бирәм соң инде аны?!

«Самарский»га кадәр итек белән бардым. Әлдә көн җылы. Укыган булыр идем «Әлхәм» сүрәсен! «Самарский»да, ак майлап, ике төче күмәч ашадым. Пиманы киптереп алдым. Төнләтеп «Матрай»га җитеп кундык.

26сында төнне тынычсыз үткәрдем. Эчем дә авырта. Иртә белән чәй генә эчәрлек тә аппетит булмады. Кызык һәм аптыратырлык бер хәл. Кайда китте бу өйдәге ашау юлында корбан булырга торган вакытлар?

«Матрай»дан соң, тагы кыш, кар томаны. Юлыкка кадәр ике кеше үләксәсенә очрадык. Дәһшәт! Юлыктагы ачлык дәһшәтләрен, угрыларны кыйнап үтерү кебек хәлләрне дә ишетеп кайтып барам. Сөекле Юлык фәләкәт оясы булып әверелгән, күрәсең.

Габделкәримдә туктап чәй эчтек. Көчләп кенә ашадым. Җитми калыр дип курыккан һәм юлда үз иркем белән рәхәтләнеп ашармын дип уйлаган азык шул көе килә. Гәрәй Шаһиәхмәдев бу авылда мөгаллим икән. Аттан төшкәч тә янына бардым. Күрешеп, сөйләшеп куандым. Зарифҗан Әдеһамов белән дә очрашып куандым. Бу якта мине үлгән дип ишетеп, догалар кылып, Коръәннәр укып беткәннәр икән!

Төштән соң Юлыкка җитеп, Хәлимуллиннарга төштем. Хуш кабул ителдем.

Мәгариф мөдире Бикбов иптәш тә шунда туры килде. Төбәп барган кешемә баштук юлыгып, сөйләшеп калдым. Минем килүемә чиксез куанып, зур хөрмәтләр һәм хөсне заннар күрсәтте, нык вәгъдәләр бирде.

Юлык мине ямьсез күренешләре белән каршылады. Юлык тәмам изелгән, ачлыкның тырнагы астына бөтен күңелле хосусиятьләрен җуеп, һәлакәт чокыры булып калган. Төрле сәбәпләр белән, мин киткәннән алып, 500 кеше үлгән. Ачлыктан көн дә бишалты кеше үлеп тора. Махсус кешеләр һәммәсен бер чокырга ташлый тора. Угрылык белән тотылганнарны авыл советы үзе кыйный да үтерә. Вә гайре, вә гайре... Ул гына җитмәсә, ваба авыруы кыра башлаган. Менә кирәк булса кыш вабасы!

Суфиларның суфие булган Нурислам хәлфә, Хәбиб хәлфә, Сәйфулла муллаларга кадәр угрылыкка керешеп, халык тарафыннан кыйналып үтерелгәннәр. Кыскасы, Юлыкта коточкыч хәлләр!

Кич коймак пешерделәр. Аппетит уянгандай булып тора. Рәхәтләнеп ашадым. Юлыкка җитү кәеф биреп җибәрде шунда да. Төшкән җирем – байлар, дуслар. Сөйләшеп, сорашып рәхәтләндек. Йокы да бик рәхәт булды.

27сендә иртә чәйгә кабартма пешерделәр. Габделхәй, Вафа күрешә килделәр. Вафа да яхшы ук бирешкән, күреп кайгырдым. Ач калган чаклар бездә була, ди. Тәэссеф *(кызганыч)*!

Хәсән белән мәктәпкә бардык. Әдһәм, Әхәт, Мәфтуха, мөәззин укыталар икән. Төшкә кадәр шунда утырдык. Кыйраәтханәмнең фатиры читательный пункт булган. Ач балаларны яхшы гына ашаталар икән. Служащийлар туклыкта, башка яклардан да бу тирәне – Башкортстанны Орскидан күп алда күреп торам.

Төштә токмачлы, симез итле аш ашау зур бәхет булды. Үлчәми генә ашау зур вакыйга булып, кызык тоелып тора миңа. Төштән соң кыйраәтханәгә бардым. Хәзер ул Гобәй мулла өендә һәм Әхәт назыйрлыгы *(идарәсе)* белән дәвам итә. Күреп, зиярәт итеп һәм мөтәэссир, һәм шат булдым. Минем язулар, ядкярләр исән тора икән. Газетада «Мирхәйдәр Фәйзинең яңа пьесалары» исемле бер язу күрдем. Бу якта мине, үлгән дип, газеталарга язып беткәннәр. Газетада үлү хәбәрем тәкзиб ителә *(ялган дип әйтелә)*. Кызык – тере көенчә үзеңнең үлгән хәбәреңне уку.

28ендә – ваба авыруы бар. Җанны шул тынычсызлый. Юлыктан тизрәк китәсе килә. Хәлимуллиннар: «Ашыкма!» – диләр. Авыру да булгач һәм юлда туктап яту да мәгънәсез булганга, бүген Бәхетгәрәй Габдрәшитов исемле егет белән китәргә булдым. Темәскә 500 меңгә алып барырга килеште.

Иртән чәйгә пәрәмәч пешерделәр.

Бүген түбәнге мәчетнең сандугачы Харис мөәззин ваба белән вафат булган. Тавышы шәп иде, авылга бер музыка бирәдер иде. Шуның шәфәгате белән рухы рәхәттә булуын телим.

Бәхетгәрәй белән Юлыктан чыгып киттек. Бәхетгәрәй – күңелем каршында хөрмәтле, сөекле егет, аның белән бару ямьле миңа. Буранбай авылында чәй эчеп чыгып, Әмин авылында кундык.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2020

ҺАВАЛАРДА ОЧА ИКЕ АККОШ...

Фәйзелхак Ислаев

Хәзерге көнгә кадәр республикабыз мәгариф системасын Мәгарифне үстерү институтыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Дөньялар үзгәрә, 20 елдан артыкка сузылган модернизация дигән исем астында югары казанышлары булган, дөньякүләм иң алдынгылардан саналган мәгариф системасын җимерү дәвам итә. 90 ел тарихы булган Мәгарифне үстерү институты икегә бүленде, татар укытучыларының квалификациясен үстерү үзәге икенче статус алды. Хәерлегә булсын.

90 ел эчендә күп мәртәбә исемен үзгәртсә дә, җисеменә тугры калган Мәгариф институты укытучыларга төрле яктан алыштыргысыз методик һәм теоретик ярдәм итү үзәге булып калды. Шушы вакыт аралыгында институт белән 25тән артык үзенчәлекле, киң колачлы шәхесләр җитәкчелек иткәнлеге билгеле. Алар арасында Гений Республиканец (Юныс Измайлович Абдрахманов) аерым урын алып тора. Ул институт директоры булып 1931 елның июненнән октябренә кадәр генә эшли. Институтта берничә ай гына эшләвенә карамастан, бу онытылган шәхес белән укучыны якынрак таныштырасы килә, чөнки аның биографиясендә халкыбызның, татар кешесенең фаҗигале язмышы яхшы чагылган. Өстәвенә, XX гасырның 30 нчы елларына караган татар мәгарифендә, мәдәни тарихында күренекле урын алып торган шәхес хакында әлегә язмалар бик сирәк, булганнарында да репрессия корбаны тамгасы бүгенге көнгә кадәр чагыла, аны күрмәмешкә салышу дәвам итә. Тагын шуны истә тотарга кирәк: үзенчәлекле талант иясе, татар халкының иң яраткан җырчыларыннан берсе булган Зифа Басыйрованың тормыш иптәше һәм улы Рафаилнең әтисе дә бит әле ул Гений. Бу ике кабатланмас шәхес турында язганда, дөреслеккә туры килмәгән фактлар китерелә, төрле мифлар уйлап чыгарыла. Шуларны искә алып, кайбер архив материалларын, бигрәк тә Флүр Баһаутдиновның «Зифа Басыйрова» дигән китап материалларын файдаланып әзерләнгән язмабызны укучыга тәкъдим итәбез.

Гений Республиканец 1906 елда Кронштадт шәһәрендә татар гаиләсендә туган. «Сәяси репрессия корбаннарының хәтер китабы»нда аның туган елы 1907 итеп бирелә. Республиканецның улы Рафаил Басыйров документларына караганда, Генийның татарча исеме – Юныс, фамилиясе Абдрахманов булган. Үткән гасырның 20-30 нчы елларында СССР күләмендә исем-фамилияләрне алмаштырып тарихи хәтерне юкка чыгару юнәлешендә чиксез мавыгу бу шәхескә дә кагыла. Ул заманда чын татарча исемнәр халкыбызга бөтенләй хас булмаган исем-фамилияләр белән алмаштырыла. Бу хакта репрессияләнгән язучы Ибраһим Салахов «Колыма хикәяләре»ндә мондый легенда язып калдырган:

«Аның ата-анасы бик иртә ачлыктан үлә. Өч яшьлек малай Казан урамында бер

кешесез ялгыз кала. Кемдер аны балалар йортына алып барып бирә. Исеме ничек? Атасы кем? Фамилиясе ничек? Беркем белми. Малай – хәл эчендә. Менә шунда, Казан балалар йортында, коллективның гомуми җыелышында, табылдык балага исем кушыла. Җыелыш күпчелек тавыш белән карар чыгара: «Малайның исеме – Гений, фамилиясе Республиканец булсын. Татар баласы булуы күренсен өчен, атасы исемен Измайлович дип куярга». Биредә чынбарлык әкият белән бергә уралып бара. Берничә ел бергә төрмәдә авыр гомер кичергән Ибраһим ага Генийның биографиясен яхшы белгән булырга тиеш, ул бит Кронштадта туган, анда үскән, шунда ук тормыш юлына баскан, ә Казанга Гражданнар сугышыннан соң гына килеп чыга.

Аның үз кулы белән тутырылган анкеталарга караганда, ул 10 яшьтән үк «Кронштадский вестник» газетасы редакциясендә таратучы (разносчик газет) булып эшләгән. Бик яшь, малай гына булуга карамастан, Гражданнар сугышы шаукымы 1918 елда аны да үз кочагына ала һәм ул, үзе теләп кызылармияче булып, ВЧК-ОГПУ органнарында хезмәт итә, Казан якларына килеп чыга. Кызыл армия сафларында 1922 елны укый-яза белмәүчеләр өчен махсус оештырылган мәктәпне тәмамлый, өстәмә курсларда укый. Укырга сәләтле егет шушы алган беренче белем нигезендә 1924-1926 елларда данлыклы Ленинград университетында рабфак студенты булып белем ала. Рабфакны тәмамлаганнан соң, Ленинградта татар клубын җитәкли, аннары шунда ук Технохимик заводында эшче булып эшләп ала. Эшче булып эшләүнең тагын бер сәбәбе булган, ахрысы, чөнки ул нәкъ менә шушы 1927 елның август аенда Коммунистлар партиясенә кабул ителә. Бу аңа партия сафларына керерегә генә түгел, Ленинградта урнашкан Н.К.Крупская исемендәге Коммунистик политпросвет институтына кереп укырга мөмкинлек тә ача һәм ул 1931 елны, институтны тәмамлагач, Казанга әйләнеп кайта, институт директоры итеп билгеләнә. Исегезгә төшерәбез, ул заманда да әле югары белемле татарлар бармак белән генә санарлык була.

Шәхси тормышына килгәндә, Гений рабфакта укыган вакытта өйләнә, туйны Ленинградта ясыйлар, ике балалары туа. Ул, укуын тәмамлагач, Казанга гаилә белән кайта, хатыны Наҗия Фәхретдинова Татар драма театрында актриса булып эшли башлый.

Институт 30 нчы еллар башында аерым, мөстәкыйль структура булып формалаша. Гений Республиканец җитәкче булган 1931 елда институт Татар мәгарифе кадрларының белемнәрен күтәрү институты дип атала башлый. Аның составында педагогика һәм педология, тел һәм әдәбият, физика һәм техника, җәмгыяви-икътисади, табигать белеме һәм химия кафедралары оештырыла. Хәзерге вакытта да институтның мондый структурасы булу сокландыра, әлеге өлкәдә тәҗрибә зур булмаса да, максатка кафедралар аша ирешүне ул вакытта яхшы аңлаганнар. Татарстан җитәкчеләре ярдәме белән Гений Республиканец «политпросвет» кафедрасын оештыра һәм аңа берничә ел җитәкчелек тә итә.

Институттан соң ул мәгариф һәм мәдәният өлкәләрендә тырышып хезмәт куя: Наркомпроста (Мәгариф министрлыгында) массакүләм бүлек мөдире (1931-1932), Сәнгать техникумы директоры (1932-1934), Театр-тамаша предприятиеләр идарәсенең (1934-1935) җитәкчесе булып эшли. Соңгы эш урыны – Казан шәһәре үзәк музее директоры. Төрле урыннарда эшләвенә карамастан, Гений Республиканец техникумда укытучы булып эшләвен дәвам иткән.

1937 елда Октябрь революциясенең 20 еллыгына әзерләнү уңаеннан, Казанда Владимир Ильич Ленинның мемориаль музеен оештыру мәсьәләсе күтәрелә. Заманасы өчен аеруча җаваплы һәм әһәмиятле эш Гений Республиканецка йөкләнә, чөнки ул инде – башка оешмаларда да үзен оештыру эшләренә сәләтле булуы белән таныткан шәхес. Гений Мәскәүдә В.И.Ленинның тормыш иптәше Надежда

Константиновна Крупская, Ленинның энесе белән очраша һәм музей оештыру хакында алардан ярдәм, мөһим киңәшләр ала.

Гений Республиканец шул ук 1935 елны популярлаша барган артист һәм кабатланмас талант иясе, җырчы Зифа Басыйровага өйләнә. Беренче танышулары кайда булганлыгы билгесез, тик Зифа сәнгать техникумына укырга кергән вакытта Гений инде аның директоры була. Әлбәттә, директор укырга килгән студент белән танышырга тиеш. Бу хакта Зифа апа болай дип язып калдырган: *«В 1935 году, еще студенткой техникума, я вышла замуж за гражданина Республиканец. Он был беспризорный, его воспитали чекисты, он не знал своих родителей, фамилию ему дали чекисты. Он был настоящим советским человеком».*

Биредә Зифа Басыйрова барысын да язып бетерми, чөнки ул да, техникумга укырга кергәнче үк, кияүдә булган. 26 яшьлек директор белән 22 яшьлек студентка арасында мәхәббәт уты кайчан кабынгандыр, анысы билгесез, тик алар, элекке гаиләләрен ташлап, 1935 елда яңа тормыш башлыйлар. Беренче иреннән аерылып, ни өчен Генийга кияүгә чыгуы турында Зифа Басыйрова болай аңлата: *«Мин, үземнең көнчелегем аркасында беренче ирем читкә киткәннән соң, ул азат хатлар язганнан соң, Республиканецка чыктым. Беренче иремне дә яхшы, туры кеше дип әйтә алмыйм».*

Ул елларны Зифада, студент булуга карамастан, үзенчәлекле тавышлы җырчы үсеп килгәнлеге төсмерләнгән вакыт. Гений аннан опера җырчысы ясамакчы булган, тик язмыш аны икенче юлдан алып китә.

Зифа Басыйрова театр техникумын 1936 елны уңышлы тәмамлагач та, Камал театрында эшли башлый, беренче рольләрне башкара. Студент чагында ук кайбер рольләрне театр сәхнәсендә башкарган артистка биредә ят кеше булмый. Сәләтле, тырыш, матур тавышлы Зифаны театр үзенә кабул итсә дә, аңа биредә шактый авырлыклар аша үтәргә туры килә. 1937 елның 15 мартында узган профсоюз җыелышында ул мондый сүзләр әйтә: *«Без, яшьләр, театрда май аеннан гына эшлибез (мин, Н.Гайнуллин, Р.Җиһаншина). Бөтенебез дә укуны отличнога тәмамладык. Нишләптер, мине кагалар, иң әз хезмәт хакы түлиләр, рольләрне бирмиләр, репитициядә дублировать итәргә дә ярамый. Гомумән, режиссерларга теләгем шул: бөтен артистларга карата тигез карашта булсагыз иде».* Гомер буе шулай турыдан ярып яшәгән мәшһүр артистка, ә турысын әйткән – туганына да ярамаган, диләр.

Башта аңарга ни өчендер малайлар, егетләр ролен башкарырга туры килә. Алга таба Зифаның драма артисткасы буларак таланты ачыла. Ул бик күп рольләр башкара. Бигрәк тә музыкаль спектакльләрдәге җырларны беренче башкаручы, аларны халыкка танытучы Зифа Басыйрова була: Х.Фәтхуллинның «Күзләр» драмасындагы «Хуш авылым», Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләге»ннән «Өмә җыры», «Чын мәхәббәт»тәге «Әдрән диңгез» һәм башка бик күп әсәрләр.

1930 нчы елларда җырлый башлаган З.Басыйрова 1940 нчы елларда инде авыл көйләрен сәхнәгә алып чыккан үзенчәлекле җырчы булып таныла. Баянчы Оркыя Ибраһимова белән Зифа, кабатланмас төркем булып, концерт эстрадасына халык көйләрен баян белән башкаруның иң гүзәл үрнәкләрен бирәләр. Алар «Су буйлап», «Өй артында шомыртым», «Дөм-дөм», «Шөгер», «Таң атканда», «Фазыл чишмәсе» кебек көйләрнең беренче башкаручысы булалар.

Болар әле – алда булачак иҗади уңышлар, ә киләчәккә өмет белән караган яшь гаиләне көтелмәгән зур сынау көтә. 30 нчы еллардагы репрессияләр шаукымы Октябрь революциясенең 20 еллык юбилее алдыннан тагын да кискенләшә. 1937 елның август аенда Мәскәүдән Татарстан җитәкчеләренә репрессияләрне көчәйтү турында яңа «план» җибәрелә. Моны үтәү өчен, республикада 500 кешене атарга,

Зифа Басыйрова
улы Рафаил белән

1500 кешене 10 елдан ким булмаган срокка төрмәгә хөкем итәргә кирәк була. Болар арасына безнең героебыз да эләгә.

1937 елның 14 сентябрендә Мәскәүгә Н.К.Крупская белән очрашырга бару өчен Казан вокзалында Мәскәү поездын көткәндә, Зифа һәм башка озатучылар ресторанда ял итеп утыралар. Шул вакытта Генийны кулга алып, ике көн сорау алалар да өенә кайтаралар, тик икенче көнне төнлә белән яңадан кулга алалар. Хатыны Зифага ул: «Минем бер гаебем дә юк, бер 5-6 көннән җибәрерләр, борчылма», – дип, чыгып китә һәм шул китүдән мәңгегә югала. Ул Советларга каршы булуда һәм милләтчелектә гаепләнә. Тикшерү вакытында кыйнау, төрле җәберләүләр, көчле басым ясауга карамастан, Гений Республиканец гаебен танымый, сүзендә нык тора. 1938 елның 12 маенда СССР Югары Мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе үзенең ябык утырышында, «җинаять эшен» карап, аны 58-2, 58-7, 58-8, 58-11 статьялар буенча, «участник правотроцкисткой националистической организции, по заданию которой вел преступно-подрывную работу против советской власти» дигән стандарт тамга салып, 10 елга төрмәгә утырту, милкен конфискацияләү, төрмә срогын тутырганнан соң 5 елга хокуклардан мәхрүм итү хакында карар кабул итә.

Зифа Басыйрова

Шул арада, 1938 елның 1 гыйнварында, Зифаның улы туа, аңарга Рафаил исеме кушыла, тик фамилиясе әтисенеке түгел, ә Басыйров итеп куела. Шулай итеп, ана үз баласын әтисе белән бәйләгән җепне өзәргә мәҗбүр була. Әтисенә бала туу турындагы куанычлы хәбәр вакытында барып җиткәнме-юкмы – билгесез. Ялгыз яшәвенә карамастан, Зифа улына тиешле тәрбия бирә: ул яхшы укый, спорт белән шөгыльләнә, бокс буенча разряды да була, Авиация институтын уңышлы тәмамлап, радиоинженер һөнәрен ала, радио-телевизорларны бик оста төзәтүче була. Шәхси тормышына килгән вакытта, Рафаил Хәсән Туфанның кызы Гөлгенәгә (Гуляга) өйләнә, алар ике бала тәрбияләп үстерәләр. Зифа үз баласы турында болай әйтеп калдырган: *«Балама ышанам. Кайбер аналарның балаларыннан зарланганлыгын тыңлаганнан соң, балаларга, киленнәргә ышанычым бетеп тә куя. Минем балам бик яхшы. Мин аларга [акчаны] бирәм. Мин картайсам, нишләрләр»*.

Гений Измайлович белән төрле төрмәләрдә, лагерьларда газап чигеп, шактый елларын бергә үткәргән язучы Ибраһим Салахов «Колыма хикәяләре»ндә аның турында кызык һәм гыйбрәтле истәлекләр язып калдыра. Алар, Колымага барып җиткәнче, Казаннан соң Бөгелмә, Уфа, Тубыл төрмәләре аша үтәләр. Татар бистәсенең өстендә урнашкан таудагы Кремль белән рәттән, патша заманында XIX гасыр уртасында каторжаннар өчен махсус төзелгән Тубыл төрмәсендә алар 1939 елның ноябреннән 1940 елның май аена кадәр булалар. Бу язмаларда берничә урында Гений Измайловичның портреты менә болай сүрәтләнә: *«Тәбәнәк, юан, әмма гаҗәеп матур сынлы», «буйга кечкенә, гәүдәгә тулы, борынгы грек скульптураларына охшаш, матур сынлы, йөзе нурлы», «гәүдәгә тәбәнәк, юантык булса да, йөзгә чибәр. Киң маңгай. Тирән утырган зур, соргылт күзләр. Туры борын. Юка иреннәр. Түгәрәк матур ияк»*.

Алар Казан халкын сокландырган пар буласы иде дә, тик язмыш тату гаиләне аера, әмма бер-берсенә булган мәхәббәтне җуймыйлар. Гений еш кына хатынын Минзифа, Гөлзифа дип искә ала, Рамай җырын аның башкаруында радиодан ишеткәч, төрмәдәге иптәшләренә үзенең җырга, башкаручыга соклануын белдерә, елап та ала. Үз чиратында, Зифа да ирен гел сөйли иде, аны сагынуын, яратуын җырга салып җырлый иде, дип, истәлекләргә язып калдырган.

Ире Республиканецны халык дошманы дип кулга алу һәм төрмәгә утырту Зифа Басыйрованың иҗатын катлауландыра, аңарга төрле каршылыклар белән көрәшергә, кечкенә улы Рафаилне иң авыр сугыш елларында ялгызы тәрбияләргә туры килә. Камал театры артисты, халык дошманы хатыны буларак, төрлечә эзәрлекләү һәм кимсетүләргә дучар була. Биредә татарга, бигрәк тә артистларга хас көнләшүнең дә роле зур булгандыр дип уйларга урын бар.

Автобиографиясендә ирен кулга алу турында Зифа болай дип язган: *«В 1937 году он был арестован как враг народа, в феврале 1938 года после его ареста я родила. В связи с его арестом, везде резко изменилось отношение ко мне. Меня исключили из рядов ВЛКСМ. Ужасная обстановка была и в театре, выселили из квартиры. Я, как жена врага народа, должна была быть арестована. Видимо сжалились, и я была оставлена у чужих людей. В 1942 году моего мужа освободили по болезни, перевели в Республиканскую неврологическую больницу, и там он скончался в 35 лет»*.

Зифа Басыйрова Ибраһим Салаховка язган хатында: *«Берничә тапкыр иптәш Табеевка керергә туры килде. Ул ярдәмгә килде. 1965 елны юбилеемны үткәрергә рөхсәт бирде. Ләкин кайбер халык җырларын яратмаучылар булдырмаска тырыштылар...»* – ди.

Ибраһим Салахов 1957 елны, реабилитациядән соң, Казанда Зифа Басыйрова белән очраша. Зифа ханым Гений Измайловичның соңгы көннәре турында мондый

хатирәләрен җиткерә: *«1942 елның көзендә мине Эчке эшләр халык комиссариатына чакырдылар. Котым очты. Нишлисең, бардым. Җаным уч төбендә. Мине чакырган кеше, ишектән керүгә исәнләшеп нитеп тормады, бик коры гына: «Сез Гений Измайлович Республиканецны беләсезме?» – диде. «Ничек белмәскә, ул минем ирем. Ул кайда, биш ел аның турында бернәрсә дә белмим», – дидем. «Ярый, хәзер күрешерсез», – диде. Өнемме, төшемме? Аптырап калдым. Мине, машинага утыртып, Арча кырындагы психбольницага алып киткеләр. Бер палатаның ишеген ачып, эчкә керергә куштылар. Янымдагы кешеләр белән бергә кердем. Бер генә караватт. Анда баштанаяк одеалга уранган бер кеше ята. Врач килеп одеалны ачты да:*

– Гений, торыгыз, хатыныгыз килде, – диде. Караваттагы кеше, тартып алып, тагын уранды.

– Торыгыз!

– Комачауламагыз, зинһар, мин Владимир Ильич белән сөйләшәм.

Тавыш таныш, Гений тавышы... Йөгереп барып, одеалны тартып алып, кочакламакчы идем, ул мине этеп җибәрде. Егылдым. Мин аягүрә басканда, алдымда коточкыч бер кеше басып тора иде. Бөтен йөзен кара сакал баскан. Күзләре, акаеп, әле бер, әле икенче якка ташланалар.

– Кем сез? Нигә рөхсәтсез кердегез! Әйттем бит, мин Ильич белән сөйләшәм. Китегез! Китегез!

Ул безне куып чыгарды. Мин аннан соң бу палатага берничә тапкыр килдем. Ләкин ул: «Ильич белән сөйләшәм, вакытым юк», – дип, палатага керттермәде. Берничә елдан соң мин аның үлүе турында хәбәр ишеттем».

Әйтергә кирәк, Зифа Басыйрованың Ибраһим Салахов язып калдырган хатирәләре архивта сакланган документларга туры килеп бетми. Архив чыганакларына караганда, Гений Измайловичның үтенече буенча өстәмә тикшерүләр үткәргәннән соң, Генераль прокуратура 1942 елның 25 ноябрендә Республиканецны гаепсез дип таба. Тик ул, бу куанычлы хәбәрне алганчы, шул ук 1942 елның 23 июлендә туберкулез авыруыннан 35 яшьтә вафат була.

Тик архив документлары да Генийның соңгы көннәре турында тулы ачыклык кертми. Аны, чыннан да, төрмәдән азат иткәннәр, ахрысы, һәм ул Казанга кайткан, тик нишләптер Зифага түгел, беренче хатынына килгән булса кирәк. Бәлки, Зифа ул вакытта Казанда булмагандыр. Авыргач, аны хастаханәгә салалар һәм ул анда үлә. Генийның хатыны Наҗия, апасы һәм ике баласы аны соңгы юлга озаталар, Вахитов станциясе кырындагы татар зиратында җирлиләр.

Кызганыч, үткән гасырның утызынчы елларында Гений Республиканец исеменә халык дошманы дип салынган тамга хәзергә кадәр нык сиздерә. Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты һәм заманында ул җитәкләгән башка оешмаларда да аңарга игътибар бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Ә бит бу шәхеснең республика мәдәниятенә һәм мәгарифенә керткән өлеше санап бетергесез. Татар халкының бөек җырчысы Зифа Басыйровага багышланган хатирәләрдә, мәкалә һәм китапларда, Флүр Баһаутдинов китабыннан башка, аның ире, улының әтисенә багышланган сюжетлар юк дәрәҗәсендә.

Ә бит халкыбызның мондый асыл затларына урын түрдән булырга тиеш! ■

Татарстан китап нәшриятына – 100 ел!

БУЫННАРДАН КҮЧКӘН ЯКТЫ МИРАС

Балачак... Эти-әни назына төренеп, уйнап-көлеп, тәгәрәшеп үскән бер борчусыз күңелле чор... Ә янәшәдә әби-бабайларның да булуы, аларның җылы кочагында иркәләнеп үтелгән еллар – гомернең иң татлысы, иң баллысыдыр ул, мөгаен. Ул яктан без дә, апам белән, бик бәхетлеләр, чөнки ике әбиле, ике бабайлы балачак кичердек. Көнозын эш белән мәшгуль эти-әниебезгә безне тәрбияләшергә ярдәм иткән, һәрчак янәшәбездә булган әби-бабай янында бик рәхәт булса да, әниебез ягыннан булган әби-бабайларыбызны да бик сагына, аларга барырга ашкынып тора идек. Бездән шактый ерак яшәгәнгәме, аларны Ерак әби, Ерак бабай, дип атап йөрттек.

Һәркем өчен күркәмлек, тугрылык өлгесе булган әлеге изге җаннар – безнең Ерак әби һәм бабабызны Арча районының Субаш-Аты авылы халкы бүгенге көндә дә Ак әби, Ак бабай буларак хәтерли. Гаҗәеп йомшак күңелле, үтә дә тыйнак, чиста-пөхтәлеге белән күпләрне сокландырган әбиебез белән сугышларны кичеп кайткан җор телле, кулында ут уйната торган уңган-булган балта остасы, гаять җитез бабабыз, гомерләре буена соклангыч пар булып, бер-берсен тулыландырып яшәделәр.

Бабай мал-туар арасында кайнаша, каралты-кураны гөл итеп тота, ә әбиебез өй тирәсендә йорт мәшәкатьләре белән мәшгуль була иде. Без – ике кызчык әбиебез тирәсендә бөтереләбез, булдыра алган кадәр ярдәм итәргә омтылабыз. Һичкайчан тавышын күтәрмәс, сабыр, тыныч холыклы әбиебез үз-үзен тотышы белән дә безгә үрнәк. Әнә ул җайлап кына эш тәртибен аңлата, тырышлыгыбызны күреп, чын күңеленнән куана, аркабыздан сөя. Эшләребезне тәмамлап, тәмле чәй эчкәннән соң, йомшак диванда ял итәргә яратабыз. Гадәттәгечә, канәгать елмаеп, әбиебез дә янибызга килеп утыра. Без исә, түземсезләнеп, аның сүз башлавын көтәбез. Бераз тын алгач, йомшак тавыш белән, әби сүз башлый: «Рәхмәт, балакайлар, тырышасыз, гел шулай игелекле булыгыз. Бер бик гыйлем кеше

болай дип язып калдырган: *«Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата-ана өчен тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык, ахирәттә йөзгә аклык китерер»*.

Ахирәт сүзен аңламасак та, әбине бүлдерүдән куркып, тын да алмый тыңлыйбыз. Ләкин аның безгә карап, сез – бик тәрбияле балалар, әти-әниегез өчен аклык кына булып яшәсәгез иде, дип, башыбыздан сыйпап куюыннан ул сүзнең яхшы мәгънәдә булганлыгына шигебез калмый. Әбиебез дәвам итә: *«Тәрбияле баланы һәркем яратыр, мактап кына телгә алып сөйләр. Тәрбиясез баланы бер кеше дә ратмас»*. Күңелдән генә шул ике баланы чагыштырып утырам: тәрбиялесе бик матур, гел елмаеп кына сөйләшә, ә теге, тәрбиясез дигәне, нинди ямьсез, киемнәре пычрак, сөйләшүе дә дорфа. Юк, икенчесе бер дә ошамый миңа. Аның кебек булырга ярамый. Әби сөйләгәннәрне сабый акылым аша уздырып, анализлап, үземчә нәтиҗә ясап утырганым әле дә исемдә... Соңрак әбидән ишеткән «бик гыйлем кеше язып калдырганнарны» әниебез авызыннан да ишетү безнең өчен куаныч булды. Ул гыйлем кешенең Ризаэддин Фәхреддин исемле икәнен, ә китапның «Тәрбияле бала» дип аталуын белдек.

Әби белән бабай бик акыллы, төпле, тәрбияле кешеләр иде. Алар безгә тәрбияви әкиятләр, хикәяләр сөйлиләр, тормыштан күп мисаллар китерәләр, аларны безнең аңга – балалар аңына барып җитәрлек гади итеп аңлата беләләр иде. Әниебезнең дә алар тәрбиясендә үсүе, үзе әни булгач, аларны безгә – балаларына җиткерүе, безне дә шул үрнәктә тәрбияләргә омтылуы белән горурланам.

Әти-әниебез, авылыбызның мөхтәрәм укытучылары буларак, безне тәртипле, итагатьле итеп үстерүгә зур игътибар бирделәр. Җайлап кына әдәп-әхлак нормаларын, туганлык, дуслык, өлкәннәргә хөрмәт, аралашу әдәбен төшендерделәр. Мәктәпкә беренче адымнарыбызны атлаганчы, без тәрбияле баланың мәктәпкә ничек баруы, анда үзен ничек тотуы, дәресләрен ничек әзерләве турында әти-әниебез сөйләгәннәрдән белдек. Яшүсмер чорыбызда өстәлебездә һәрчак Ризаэддин Фәхреддиннең «Балаларга үгет-нәсыйхәт» китабы булды. Мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт педагогия университетының тарих-филология факультетына укырга кергәч, үзем өчен әлеге гыйлем иясен бөтен гомерен татар халкының тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә, ислам динен саклап калуга багышлаган халкыбызның күренекле мәгърифәтчесе, галим, язучы һәм педагог Ризаэддин Фәхреддин буларак ачтым. Киңәшләрен тыңлап үскән бала буларак, аеруча якын иде ул миңа.

Әбиебезнең күңел сандыгында сакланып балаларына күчкән, китап булып безгә – оныкларына тапшырылган олы мирас – Ризаэддин Фәхреддиннең «Тәрбияле бала», соңыннан аңа килеп өстәлгән «Балаларга үгет-нәсыйхәт» хезмәтләре – нәселебезнең һәр буынын тәрбияләүгә зур өлеш керткән өстәл китаплары. Бүгенге көндә әлеге әхлак мәсьәләләренә багышланган, халык тәҗрибәсенә нигезләнгән хезмәтләрне безнең балаларыбыз тыңлап үсә. Олуг галимнең шундый канатлы сүзләре бар: *«Балачакта алган тәрбияне соңрак бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас»*. Димәк, кеше тормышындагы бик мөһим булган иң гүзәл сыйфатларны – әхлак нигезен – без балаларга гаиләдә кечкенәдән үк сала башларга тиеш. Бу – һәр әти-әнинең изге бурычы. Мин исә, нәселебездә өстәл китабыбыз булып буыннан-буынга күчеп килгән әлеге искиткеч мәгънәле хезмәтләр авторы – мәшһүр педагог Ризаэддин Фәхреддин алдында баш иям.

Гөлнара Гатауллина,
Казан шәһәре ■

МУЗЫКА БЕЛӘН ЯЗЫЛГАН ЯЗМЫШЛАР

Мәгъсум Гәрәев

Миңа калса, Ростропович шаяртмыйча, нәрсәдән дә булса кызык табып мәзәк ясамыйча сөйләшә алмый иде шикелле. Ирониясе һәм үзирониясе дә бетмәс-төкәнмәс аның. 2005 елның көзендә Зур театрда Сергей Прокофьевның «Война и мир» операсын куярга әзерләнгәндә, Мстислав Леопольдович (спектакль аның дирижерлыгында уйнала) журналистларны хәйран калдыра. «Мин Прокофьевтан йөз мең мәртәбә акылсызрак. Әмма кайчак андый кешедән дә файдалы фикерләр чыга», – ди ул.

Ростроповичның шук-шаян чагында да гади, һәркемгә игътибарлы, кече күңелле, көлемсәр була белүенә гаҗәпләр калам. Виолончельченең яшәү рәвеше – музыка. Ансыз аңа тормыш юк. Тугач та кулына виолончель тотырганнармы әллә моның дип уйлап куйган чакларым да була. Атаклы музыкантны ашкынулы уй-фикерләре һаман сәхнәгә күтәрә. 80 яшь туласы көнгә кадәр (2007 елның 27 марты) гомеренең һәр сәгате тасвирланган иде.

Легендар җырчы Леонид Утесовның: «Сезнең алга 13 елдан 100 яшен тутырачак кеше чыгып басты», – дип, бөтен залны дәррәү куптарган сүзләре истә. Аннары джаз музыкасының атасы, композитор һәм дирижер Олег Лундстрем: «11 елдан», – дия иде. Мин алар кебек мактана алмыйм әле. Миңа 15 елдан гына 100 тула...

Мстислав Ростропович хатыны – опера җырчысы Галина Вишневская белән СССРдан куылганчы да һәм Франциядән кайтып йөри башлагач та, без бер генә тапкыр очрашмадык. 2004 елның июнь уртасында Казанда ике көн булган иде алар. Элек тә киләләр иде. Шул чакларны искә төшердек.

– Чит дәүләтләр бүләкләгән орденнарымның барысын да таксам, Брежневны да көнләштереп уздыра алам, – ди иде ул чорда Ростропович. – Әмма СССРда һәм Россиядә алган бүләк-исемнәрем һәммәсеннән дә кадерлерәк. Мин туган илемдә, Сталин премиясен алудан башлап, Россия Мәгариф академиясенең Мактаулы академигы булуга ирештем. Ләкин лауреатлыкны түгел, музыканы үлеп яратам. Лавр яфрагыннан үрелгән венокны музыка белән чагыштырып буламы соң?!

Мстислав Ростропович – безнең чорның гаҗәеп затлы легендасы. Бөек музыкант – кешеләргә матди ярдәм күрсәтү ягыннан да дөньякүләм танылган шәхес. Берлин стенасы җимерелгәч, дивар ташларына утырып виоланчельдә уйнау дисеңме, Санкт-Петербургтагы гади халык дәвалана торган хастаханәне финанслаумы, Россия шәһәрләре залларында бушлай концертлар бирүме – боларны Ростропович күз буяу, яхшы атлы булып күренү өчен эшләми, намусы, йөрәге шулай куша. Ростропович һәм Вишневская Россия педиатриясенә ярдәм фонды оештырды. Икесенең дә талантлы балаларны бушлай укыту өчен аерым, махсус фондлары бар. Ростропович акчасына – музыкантлар, Вишневскаянықына опера җырчылары укыды һәм бүген дә укый!

Мстислав Леопольдовичның татарларны яратуын, аларга ярдәм итәргә ашкынып торуын әйтергә кирәк. Маэстро моның сәбәбен Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында болай дип аңлатты:

– Сугыш башлангач, Ленинград балаларының бер өлешен Оренбургка эвакуацияләделәр. Мин анда Мәрьям апа һәм Тәүфыйк абый гаиләсендә яшәдем. Алар миңа яхшы тәрбия бирделәр, авызларыннан өзеп ашаттылар. Шушы игелекле җаннар

Хөкүмәт үткәргән банкеттан соң, Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында.
Рәсемдә: (сулдан уңга): ТР Премьер-министры Р.Миңнеханов, СССРның халык артистлары – опера җырчысы Г.Вишневская, виолончелист М.Ростропович, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе М.Гәрәев һәм ТАССРның, РСФСРның халык артисты И.Шакиров. 14.06.2004 ел

булмаса, мин, бәлки, исән дә калмас идем. Татар халкына шул бурычымны түләргә тырышам. Әмма булдыра алырмынмы?!.

Казанда музыкант Фонды стипендианты, скрипкачы Сәйфи Арслан да бар икән. Малай белән озак сөйләшеп утырды Ростропович. Оренбургта ул 15 яшендә музыка училищесында укыта башлый. Бу – дөнья күләмендә феноменаль күренеш. Шушы көнгә кадәр бер генә илдә дә музыка училищесында 18 яшьлек укытучы булмаган. Мстислав Ростропович 1943 елда, 16 яшендә, Мәскәү консерваториясенә кабул ителә.

Ростропович Сәйфи Арсланны әнисе белән Мәскәүгә алып китте, аларга фатир алып бирде. Малай башта Мәскәү консерваториясенең махсус мәктәбендә укый һәм Россия Президенты стипендианты була, аннары музыка югары уку йортын тәмамлый. 2006 елда скрипкачыларның Европа күләмендәге ярышларыннан Гран-при алып кайта. Хәзер консерваториядә укыта.

«Яшәвемнең төп мәгънәсе – балаларга ярдәм итү, алардан чын музыкант әзерләү», – ди Ростропович.

Баянчы Айдар Гайнуллин да маэстроның өметен тулысынчааклады. Ул 13 яшендә үк Россиянең мәдәният фонды лауреаты булды. Айдар Россия Президенты исемендәге Алтын китапка кертелгән.

Менә шуннан соң Ростропович стипендиантын үз концертларына чакыра башлый. Башта Лондонга, аннары Парижга алып китә. Парижда атаклы музыкант Айдарга үз өендә мастер-класс дәресләре бирә. Соңыннан серне ача: «Аң бул, мин боларны сиңа киләчәк 50 елны алда тотып сөйләдем!» – ди.

Айдар миңа беренче күрешүемдә үк, нигәдер, туганым кебек якын тоелды. Кемгәдер охшатам үзен, әмма кистереп әйтә алмыйм. Сөйләшеп утыра торгач, хәтерем яңарып китте ләбаса! Чү, мин әйтәм, Ренат Ибраһимов студент елларында шундый ук каратут какча йөзле, чем-кара чәчле иде. Сүзләренең кайберләре, әйтерсең, бер авыздан чыга: йомшак телле, мишәрләрчә.

Айдар Гайнуллин һәм Мәгъсум Гәрәев. 19.05.2009 ел

Озак түзеп тормадым:

– Ренат Ибраһимовлар белән туганлык юктыр бит, – дип сорап куйдым.

Болай да көләч йөзе тагын да ачылыбрак китте Айдарның. Соравыма каршы сорау:

– Кайсысы белән икән?

– Мин, әлбәттә, җырчы Ренат Ибраһимовны күздә тотам. Музыкант Ренат Ибраһимовны күргәнем юк, ишетеп кенә беләм: Мәскәү татары, башкалада консерватория һәм аспирантура тәмамлаган. Хәзер Лондонда яши, филармониянең симфоник оркестрында контрабаста уйный. Хатыны Люция Саратов кызы, инглиз балаларына музыка укыта...

– Җырчы Ренатны яшьтән белгән кешеләрнең мине аның белән бутаган вакытлары да булды, – ди баянчы.

– Айдар, синең даһи виолончельче Мстислав Ростропович шәкерте икәнеңне беләм. Үзең кай тарафлардан син, әти-әниең кем?

– Безнең Гайнуллиннар нәселе Чуашстанның Батыр районыннан, Татарстанга терәлеп торабыз. Әнием Равия – авылдагы гап-гади хатын, әтием Әкъръәметдин – электр монтажчысы. Бала чакта күз матур нәрсәгә төшә, уенга да бирелеп китәсең. Абыем Адис – музыка мәктәбен тәмамлаган баянчы. Кызыктыра бит. Уйнарга өйрәтә иде. Шулай баянчы булып киттем. Абыем хәзер Мәскәүдә яши, музыка мәктәбендә укыта, зур гына ансамбльдә – концертмейстер...

Айдар Гайнуллин, Мәскәүдә торса да, елның яртысын Германиядә үткәрә. Ике илдә берьюлы ике аспирантурада укыды: Гнесиннар исемендәге Россия музыка академиясендә һәм Германиядәге Милли музыка югары мәктәбендә.

Айдар – үтә талантлы музыкант. 2001 елның көзендә Лондонда баянчыларның «Дөнья кубогы» дип аталган бөтендөнья конкурсы үткәрелә һәм, Гайнуллинга әлеге бүләкне бирү белән генә чикләнмичә, аңа «Баян короле» дигән диплом да тапшыралар. Татар музыканты 23 яшендә (ул 1981 елның 12 гыйнварында туган) җир йөзендә баянчылар өчен булдырылган барлык бүләкләрне дә алуга ирешә. Мин татарның атаклы гармунчы-баянчылары Фәйзулла Туишев, Гали Җәмлиханов, Мохтар Әхмәдиев, авылдашым Рокыя Ибраһимова һәм Фәйзи Биккинин концертларын тыңлап, алар белән аралашып үстем. Әмма шушы яшемә җитеп, Айдардай оста баянчыны очрата алмадым. Аның уенын җентекләп күзәтсәң, таң калдыра торган сыйфатлары бик күп: баянның үзеннән генә түгел, Гайнуллинның кулларыннан, күзләреннән, кашларыннан, хәтта чәчләреннән дә, гомумән, бөтен сыныннан моң агыла. Ул, баянын тотып, дөньяны әйләнеп йөри, һәрбер илнең зиннәтле залларында уйный. Мстислав Леопольдович талантлы шәкертен Парижга алтын туена – Галина Вишневская белән бергә торуларына 50 ел тулуга багышланган бәйрәмнәренә чакыра. Мәҗлестә Англия королевасы Елизавета һәм Франция Президенты Жак Ширак мактаулы кунаклар төсендә катнаша. Безнең егет шундый дәрәҗәле шәхесләр алдында сайрата баянын.

Айдарның Һиндстан, Малайзия, Таиланд, Кувәйт, Кытай кебек илләрдә узган концертларында баян музыкасын, гади тамашачылар белән бергә, корольләр, шәехләр, президентлар, премьер-министрлар, министрлар гаиләләре белән тыңлыйлар.

Гомергә онытылмаслык тәэсирләр калдырган якты гастрольләрен санап бетерә алмассың Айдарның. Төньяк Кореяда «Апрель язы» дигән традицион фестиваль үтә. Гайнуллин бу бәйрәмнең кунагы була. Анда Алтын премия һәм Алтын кубок тапшыралар үзенә. Баянчы Төньяк Кореяда булуы турында аерым бер хис белән сөйли. Бу илнең юлбашчысы Ким Чен Ир баянда уйнаганны аеруча ярата икән. Ул, ничектер, Россия баянчысы концертлары булуын белми кала. Юлбашчы күрсәтмәсе буенча, Россиягә очачак самолетның рейсын ике көнгә кичектерәләр. Татар баянчысы Ким Чен Ир өчен махсус концерт бирә. Аның уены тәэсирләндерә җитәкчене. Ул безнең егетне Төньяк Кореяга ешрак килеп йөрергә өнди, аңа баян музыкасы турында хикәятләр сөйли.

– Айдар, мин баянны Европада гына яраталар дип уйлый идем. Фикерем дөрес булмаган. Димәк, син һөнәр сайлауда ялгышмагансың.

– Баян дөньяның барлык илләрендә дә елдан-ел популярлаша бара. Аккордеон да шулай ук тамашачы күңелен яулый. Бүгенге көндә баян сәнгате Кытайда аеуча киң җәелгән. Бу илдә хәзер бер миллионнан артык профессиональ баянчы бар. Франция телевидениесендә баян музыкасын тәүлек буе тапшыра торган махсус канал эшли. Италия, Испания, Германия, Англия кебек илләрдә дә баян музыкасы концертлары иң зур һәм зиннәтле залларда үтә. Минем фикеремчә, баянның киләчәге зур. Аның мөмкинлекләре чикләнмәгән. Баянда төрле музыканы уйнап була: классика, джаз, хәтта рок. Мәҗлесләрдә һәрчак баян өстенлек ала. Күз алдына китерегез: баян төрле тавышлар чыгара, барлык жанрдагы музыканы уйный алуы белән тулы бер оркестрны алыштыра. Фортепианода халык көйләрен тиешле дәрәҗәдә уйнап булмый, скрипкада аккордлар белән сыздыра алмыйсың. Ә баян барысын да сибә. Аның бердәнбер кимчелеге шул – күтәреп йөртергә авыр: үзе – 15, футляры белән 17 килограмм.

– Айдар, синең бу баяның кайда эшләнгән?

– «Юпитер» баянын нигез итеп алып, Россия осталары ясады. Тавыш сыйфатлары буенча ул итальяннарныкын уздыра. Россия баяннары кыйммәт, әмма Италиянекенә караганда арзанрак.

– Синең Германиядә яшәп иҗат итүче татар композиторы Суфия Гобәйдуллина белән элемтәң бармы? Мәгълүм булганча, ул баян белән оркестр өчен күп яза. Яңа әсәрләрен башта синең Мәскәү консерваториясендәге җитәкчең – баянчы-профессор Фридрих Липска һәм виолончельче, Россия музыка акдемиясе профессоры Владимир Тонхка уйната. Суфия апаның татар фольклоры мотивлары буенча язган популяр әсәрләре байтак. Атаклы композиторның шул әсәрләрен уйнасаң иде. Остазың Ростропович дөньяның концерт сезонын Суфия Гобәйдуллина музыкасы белән ача бит.

– Мин композиторларны әлегә музыкасы буенча гына беләм. Аның әсәрләрен камера оркестрына кушылып башкара башладым. Кинорежиссер Иван Вырыпаевның «Эйфория» дигән фильмы чыкты. Ул музыкага багышланган. Баянда мин дә уйнадым. Фильм Венеция кинофестивалендә кече алтын медальгә лаек булды.

Айдар Гайнуллин баянчыларның үзе катнашкан барлык халыкара конкурсларда беренче урынны алды һәм шуның белән «Гиннесның рекордлар китабы»на кертелде. Һәм ул анда татарлардан беренче кеше.

Журналыбызның авторы, танылган журналист, ТР Язучылар берлеге әгъзасы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Мәгъсум Гәрәй улы Гәрәевкә*** *февраль аенда* ***85 яшь*** *тула. Матбугатыбыз ветеранын юбилее белән ихлас котлап, аңа саулык-сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!* ■

Безнең мирас №2 февраль 2020

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

Токио күренеше. 1910 ел

ЯПОНИЯДӘ КОНТЛАР, ЯГЪНИ МОРЗАЛАР

– Мондый чәйне Япониядә беренче күрүем, моңа кадәр һич эчкәнем дә, күргәнем дә булмады.

Тәрҗемәчем Накайама болай диде:

– Бу чәй сые Сезнең хөрмәткә булды. Без бу чәй турында ишетеп беләбез, тик мин дә менә гомеремдә беренче тапкыр, Сезнең белән бергә булганга гына, эчә алдым, Сезгә рәхмәтлемен.

Ярты сәгать вакыт үткәндерме, юктырмы, Конт Маҗораның улы килеп, безгә: «Рәхим итеп килсәгез, атам кунак бүлмәсендә сезне көтә», – диде. Без шунда ук кабат кунак бүлмәсенә юнәлдек. Конт Маҗора безне аякта каршы алды, аннары, башта үзе утырды да безгә дә урын күрсәтте. «Хуш килдегез» йоласын үтәгәннән соң, сүз башлады:

– Без Сезне үзебезгә якын күргәнгә, үз гореф-гадәтләребез буенча кабул итәбез. Югыйсә, Аврупа гадәтләрен дә беләм, Англиядә һәм Америкада булдым. Безнең япон милләтендә кунак алдында киерелеп басып тору ихтирам билгесе түгел. Киресенчә, «Хөрмәтле кунагым, килгән минутыгыздан башлап, Сезнең алдыгыз-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

да аяк-кулым бәйле, урынымнан хәрәкәт итәргә хакым юк, әмерегезгә буйсынам» мәгънәсенә туры килгән хәл-торышыбыз белән кунагыбызга булган ихтирамыбызны күрсәтәбез.

Шунысы да бар: һәр милләтнең үз гореф-гадәте үзенә кадерле, мөкатдәс. Без японнарның гадәтләре менә шундый һәм без һичбервакыт үз милли гадәтләребезне үзгәртү фикерендә булмадык, булмаячакбыз. Сезнең бүгенге бу күрешә килүегезгә мин бик шатмын. Татар-төрек кавемнәре – безнең кардәшләребез, бу гасырда безне бер-беребезгә якынайтачак уртак шәркыйлыгыбыз да киләчәктә бөек берләштерүче көч булып торачак.

Шуңа күрә хәтта: «Минем өчен бу бәйрәм көне булды», – дисәм дә, бер дә арттыру булмас. Моннан тыш, мин Бөек Чыңгызга карата соклану һәм ярату хисе тоям, татар кавемнәре тарихы белгечлегем дә бар. Сезгә – олы яшьтәге һәм ерак җирләрдән килгән мөхтәрәм әфәндегә – күрешергә килүегез өчен бик рәхмәтлемен.

Мин генә дә түгел, бөтен япон милләте Сезне ихтирам итә, һәркөн газеталарыбызда басылып барган мәкаләләр Сезне япон милләтенә яраттырды. Сезнең бу сәяхәтегез, бер Аврупа сәяхәтчесенеке кебек, бүген сөйләнеп, иртәгә онытылачак вакыйга гына булып калмас; безнең йөрәкләрдә гомер буе яшәрлек эз калдырып, ике милләт арасында дустанә мөнәсәбәтләр урнашуга да сәбәп булыр һәм исемегез, лаеклы рәвештә, Япония тарихына керер, мәктәпләрдә балаларыбызга да өйрәтелер дип ышанам. Нәкъ шулай булачак һәм мин бу сөенечле хәбәрне Сезгә бүген үк белдердем.

Конт Маҗораның бу дәрәҗәдәге илтифатыннан бик нык уңайсызландым, бер яктан, боларны ишетүемә шат булуымны белдерсәм дә, икенче яктан, ул мәлдә телемә килә алган сүзләр белән үземнең урынымны, дәрәҗәмне аңлавымны белдереп, болай дидем:

– Минем кебек чит ил кешесен хозурыгызга кабул итеп, бу дәрәҗәдә илтифат күрсәтүегез – Сезнең бөек кеше булуыгыздан. Шушы бер ай эчендә япон милләтенең миңа күрсәткән зур ихтирамы өчен, даими рәхмәт әйтеп, шөкер кылам. Бик нык ышанып әйтә алам: бу илтифатлар миңа күрсәтелсә дә, ахыр исәптә, ул – минем милләтемә күрсәтелгән хөрмәт. Шул ук вакытта, япон милләтенең мин вәкиле булган, чылбыр әсирлегендә гасырларча изелгән, хәзер дә изелүендә дәвам иткән милләткә – кан кардәшләренә бу дәрәҗәдә ихтирам күрсәтүе аның бөеклегенә дәлил булып тора.

– Юк! Моңа кадәр без үзебезне алга киткән һәм мәдәни халык дип саный идек... Әлбәттә, чынлап та, алдынгылыкта һәм мәдәнилектә күзгә күренеп торырлык урыныбыз бар. Әйе, кабатлап әйтәм: бу – ачык билгеле. Мәдәният һәм мәгариф эзләп, бөтен Аврупаны гиздек, тик, ни кызганыч, яныбызда диярлек урнашкан кан кардәшләребездән һич хәбәребез юк иде. Ул җирләрдә ырудашларыбыз бардыр дигән уй башыбызга да килмәде. Әгәр татарлар үзләре безне эзләп килмәгән булсалар, Сез олы зат рәхим итеп бирегә килмәгән булсагыз, кем белә, әле тагын күпме вакытларга кадәр татарлар турында хәбәребез дә булмас иде. Без Сезне эзләп барырга тиеш идек, Сез безне эзләп килдегез. Вазыйфабыз булган бу эшне башкара алмаганлыгыбыздан уңайсызланам. Бу рәхимлелектә Сез алга чыктыгыз. Аврупа халыкларына Шәрыкны танытуда да татарлар алда иде, Шәрык илләрен бер-берсе белән таныштыруда да Сез алга чыктыгыз. Без Сезгә рәхмәтле булып, моннан соң һәрвакыт бәйләнештә торып, Шәрыкның мәнфәгатьләре һәм аның якты киләчәге өчен бергәләшеп хезмәт итик.

Мин бу сүзләргә аерым рәхмәт әйттем, аннан соң кабат чәйләр, җиләк-җимешләр килде. Әңгәмә бер сәгатькә якын дәвам итте. Сүз барышында Конт

Император Муцухито (Мэйдзи, 1852-1912)) гаиләсе. Муцухито 1867 елның 3 февралендә тәхеткә килә һәм вафатына чаклы ил белән идарә итә.

Маҗора Русиядәге мөселманнарның хәлләре, саннары – җан исәпләре хакында сорау бирде. Аннары Дини идарә рәислегенә бәйлелекләренең дәрәҗәсе белән кызыксынды. Мин болай дидем:

– Бу соңгы соравыгызга җавапта бераз икеләнәм, чөнки шәригать кушуы буенча кирәкле булган дәрәҗә бар, чынбарлыкта булган дәрәҗә бар, боларның кайсын күз алдында тотуыгызны аңлап бетермәдем.

– Минем максатым – файдалы мәгълүмат алу, рәхим итеп икесе хакында да сөйләсәгез, бигрәк тә файдалы булыр.

– Бик яхшы. Безнең Ислам динендә хилафәт, ягъни дини идарә мәсьәләсе бар, аны сөйләп аңлату өчен башта дини идарәнең үзенең ни икәнен аңлатып китәргә кирәк. Хилафәт – руханилыктан бигрәк, дини рәислек дигән сүз. Яхшыны – яманнан, дөресне ялгыштан яхшы аеручы Ислам дине, сәясәтне дә үз эченә алган дин булганга, бу рәислек эчендә сәясәт тә берләшкән. Шул рәвешле, халифә булган шәхес үз мәмләкәтендә дини һәм сәяси рәис сыйфатына ия булган кебек, дин карашынча, чит мәмләкәтләрдәге мөселманнарга да рәис булып тора.

Бөтен мөселманнарның да имамны (ягъни халифәне) тانулары һәм аңа итагать итеп буйсынулары – дин таләбе. Һәр мөселман имамын белергә һәм танырга тиеш. Имамын танырга-белергә кирәк күрмичә яшәп вафат булган мөселманнарның бу дөньяны хата-ялгышлыкларга баткан хәлдә калдырып китүләре турында пәйгамбәр хәдисләре бар. Шуңа күрә һәр мөселман кешесе, кайда гына булса да, ачыктан-ачык билгеле итмәсә дә, кальбе белән имамын таный һәм аңа кальбе белән баглана. Динебез таләпләре һәм вөҗдан кушуы буенча инанулар арасында урын алганга, моңа бернинди көч тә каршы тора алмый. Шул дәрәҗәдә ки, мәсәлән, бүген аврупалыларның Ислам дөньясына ташланулары арткан саен, мөселманнарның дини һәм милли хокукларына һөҗүмнәре дә шул ук нисбәттә арта бара. Таптап изгәннәр, дини рәислек идарәсенә булган баглылык матди яктан зәгыйфьләнгән, бигрәк тә Русия хөкүмәте идарәсендәгеләр хо-

кукларыннан барыннан да артык мәхрүм ителгәннәр. Ләкин шулай булса да, рухи баглылыгыбыз һичбервакыт какшамаячак, һичбервакыт юкка чыкмаячак. Мөселманнар бу көч белән чынлап горурлана алалар. Бу җәһәттән җир шарының барлык мөселманнары бер бөтен тәшкил итәләр. Килер вакыт, Аллаһының кодрәте белән бу рухи көч җисми-матди көчкә дә әверелер.

Моннан соң, бу юлда хезмәт итү бөтен мөселманнарның да вазыйфасы булып тора.

– Сөйләгәннәрегездән бик канәгать калдым. Моннан соң да күрешү насыйп булыр, файдалы мәгълүматларга байый алырмын дип өмет итәм. Ишегебез Сезнең өчен һәрвакыт ачык. Рәхим итеп килсәгез, шатланачакмын, моны ышандырып әйтә алам.

Конт Маҗора яныннан саубуллашып чykканнан соң, туп-туры тәрҗемәчем һәм дустым Накайаманың өенә киттек.

МИЛЛӘТ ВӘКИЛЛӘРЕ МӘҖЛЕСЕ

Билгеле булганча, Япония – конституция юлы белән идарә ителә торган ил. Япониядә конституция идарәсе урнаштырылганнан соң инде 22 ел үткән. Илнең идарә эшләре тулысынча милләт вәкилләре тарафыннан чыгарылган кануннар буенча алып барыла. Сенат Мәҗлесе дә бар, үзләре аны Кизоки Эн дип атыйлар.

Ил кануннарына халык ни дәрәҗәдә итагать итеп буйсынса, император Микадо да шулкадәр үк итагать итә һәм буйсына, бервакытта да канунга каршы булган эшләр эшләми. Шул ук вакытта, японнар карашынча, бу кеше олы, изге шәхес булып санала, хәтта берничә ел элек аңа илаһи зат итеп тә карый башлаган булганнар. Бераздан Микадо үзе бу илаһилык дәрәҗәсеннән баш тарткан, ләкин шулай булса да, японнар бервакытта да бу бөек затның хакимиятен изгеләштерүне һәм тоткан урынын олылап яклауны, хуплауны бер мыскал да киметмәгәннәр. Микадо ни генә дисә дә, халык арасында аны тәнкыйть итәчәк бер генә кеше дә булмаячагы көн кебек ачык. Шулай була торып та, Микадо дәүләт эшләренә вазыйфасы тышында һичбервакыт тыкшынмый. Мин японнарның Милләт вәкилләре Мәҗлесендә (үзләренчә «Җийоги Эн»нәрендә) дә, Сенат Мәҗлесендә дә булдым.

Милләт вәкилләре Мәҗлесе әгъзалары арасыннан күп кенә кеше минем дусларым иде, ә «кайберләре минем шәкертләрем иде» дия дә алам. Шуңа күрә Җийоги Эн ишеге миңа һәрвакыт ачык иде.

МИЛЛӘТ ВӘКИЛЛӘРЕ МӘҖЛЕСЕ БИНАСЫ

Милләт вәкилләре Мәҗлесе белән Сенат Мәҗлесе икесе дә Хибйә бакчасына якын бер җирдә вакытлыча гына салынган агач бинада урнашкан иде. Инде шактый вакыт бу бина эчендә ил эшләре хәл ителә килгән. Милләт вәкилләренең күпчелеге милли кием кия, аякларында да һәрвакыт ак оекбаш белән арты-алды ачык башмаклар була.

Милләт вәкилләренең гомуми саны – 372. Бу – җан исәбе 51 миллион булган халыктан сайланган вәкил саны. Милләт вәкилләре Мәҗлесенең рәисе – Хисибә исемле, ә баш сәркатибе – Хийашитә исемле кешеләр иде.

Мәҗлес утырышларына мин берничә тапкыр катнаштым, беренче тапкыр 18 нче февраль утырышында булдым. Ул вакыт милләт вәкиле Томиджи җәнапларыннан Мәҗлеснең оешуына, ачылуына кагылышлы мәгълүмат сораган идем. Профессор Томиджи шул рәвешле җавап бирде: «Мин Сезгә Милләт вәкилләре Мәҗлесенең ачылуы турында мәгълүмат бирә алам, ләкин ул ишетеп белгән хәбәрләр булачак. Әгәр Сез бу мәгълүматны принц Итодан алсагыз, бу Сезнең өчен тагын да әһәмиятлерәк булачак, чөнки Мәҗлесне ачуга төп хезмәт күрсәткән кеше – ул. Бу

Император Муцухито

шәхес гомеренең ун елын шул хезмәткә багышлаган, берөзлексез эшләп, бары тик төп канунны төзер өчен генә гомеренең ун елын сарыф иткән. Моны башкарып чыгу өчен, Аврупадагы бөек дәүләтләрнең төп канунннарын җентекләп өйрәнгән, шуннан соң, безнең япон халкының милли гореф-гадәтләренә, йолаларына туры китереп, бүгенге төп канунны барлыкка китергән. Шуңа күрә, бер уңайлы вакытын туры китерә алсагыз, принц Итодан гаять киң мәгълүмат ала алыр идегез. Һәм, гомумән, принц Ито бирәчәк мәгълүмат Сезнең үзегез өчен генә түгел, ә бөтен дөнья тарихы өчен дә әһәмиятле мәгълүмат, ә безнең өчен шәрәф, ягъни бөек дәрәҗә булачак».

Бу сөйләшүдән соң, мин Мәҗлеснең оешуы хакындагы мәгълүматны принц Ито җәнапларыннан алырга дигән карарга килдем. Биредә хәзер бары тик үзем катнашкан беренче утырышта Мәҗлеснең көн тәртибендә булган мәсьәлә белән Милләт вәкилләре Мәҗлесенең бүген җәмгыятьтә тоткан урынына карата профессор Томидҗи җәнаплары биргән мәгълүматны гына китерәчәкмен.

18 нче февраль көнне сәгать көндезге беренче яртыда Милләт вәкилләре Мәҗлесенә килдем, утырыш башланмаган иде әле. Токио милләт вәкиле, дустым Сасаки белән сөйләшеп, бераз вакыт үткәрдем, мәҗлестә каралачак мәсьәләләр турында сорадым. «Башта финанс мөдирлегенең чыгышы бар. Аннары карарбыз, Америкадагы япон мөһаҗирләре турында сүз башлар кеше булмаса, малия (финанс) буенча фикер алышу дәвам итәр», – диде. Нәкъ сәгать бердә мин чит ил кешеләре өчен махсус билгеләнгән урынга барып утырдым.

Утырыш залына инде милләт вәкилләре җыелган, Хисибә Сан рәислек бүлемендә иде. Министрлардан баш министр Кавҗара һәм чит ил эшләре министры Камора җәнаплары, кайбер дәүләт эшлеклеләре һәм Дәүләт Советы әгъзалары да утырышка килгән. Тик кайбер милләт вәкилләренең урыны буш иде.

Башта малия түрәләреннән бер кеше кыска гына итеп сөйләп алды. Моңа каршы сөйләүче булмады.

Бераздан беренче чыгыш ясаучы Корахара җәнаплары мөнбәргә чыкты. Аны алкышлап каршы алдылар. «Әфәнделәр! Америка Кушма Җөмһүриятләренең япон мөһаҗирләренә карата үткәргән сәясәте ул илгә күчеп киткән кешеләребез өчен золым булган кебек, милләтебез өчен дә хурлык, түбәнлек. Мин бу хакта, Калифорниядән дә, башка өлкәләрдән дә килгән ышанычлы хәбәрләргә нигезләнеп, иптәшләргә мөрәҗәгать итәм, – дип башлап, бер сәгатьләп чыгыш ясаганнан соң: – Бу ачы хакыйкатьләрне мин ышанып кабул иттем. Хөкүмәтебезнең бу хосуста сүзсез калып торуы һич дөрес түгел, японнар дөньяның кай җирендә генә булсалар да, хәтта бер генә кеше булса да, ул – япон кешесе, аның шәхси хокукы – безнең милли хокукыбыз дигән сүз. Мин бу хакта хөкүмәтнең эндәшми торуына бернинди мәгънә дә бирә алмыйм. Хөкүмәт сүзсез торса да, милләт эндәшми тора алмаячак. Безнең коралҗиһазларыбыз милләтебезнең намусын яклар өчен ләбаса, гаскәребез дә япон

Токио урамы. 1910

милләтенең конституция буенча каралган хокукларын саклау өчен...» – кебек сүзләр сөйләде.

Корахара җәнаплары, көчле алкышлар астында, үз урынына китте. Моннан соң, рәис утырышка тәнәфес игълан итте.

Тәнәфес вакытында минем яныма профессор Томидҗу килде. Бераз сөйләшеп тордык, сүз конституция идарәсенә кагылгач, Томидҗу болай диде: «Ил конституция ысулы белән идарә ителүдә тулы иреккә ия була алмый, күрәсең. Бары тик парламент кына мәмләкәтнең алга баруына һәм югарыга күтәрелүенә хезмәт итә дигән фикер бик үк дөрес түгел. Җийоги Эн һәм хөкүмәт – болар мәмләкәтне тотучы ике бөек көч. Боларның бәрелешүеннән мәмләкәт кайчак яра алырга да мөмкин. Бүгенге көндә Япониядә хөкүмәт идарә тезгенен тулысынча үз кулына алган, кайчакларда хәтта Милләт вәкилләре Мәҗлесенең карарлары да берни эшли алмый, чөнки Кизоки Эн Җийоги Эн карарын юкка чыгара ала. Кизоки Эн, ягъни Сенат Мәҗлесе хөкүмәт кулында. Күп кенә мәсьәләләрдә безнең кебек милләт тарафыннан сайлап куелган, милләт мәнфәгатенә хезмәт итүче кешеләрнең тоткан урыннары зур җаваплылык таләп итә.

Бездә бүгенге көндә иң зур мәсьәлә – икътисад мәсьәләсе. Дөресрәге, яшәү мәсьәләсе: җир аз, мәмләкәтебез фәкыйрь, эш аз, читтән мал китертелми, чик хезмәте авырлык белән бара, читкә мал чыгармыйбыз, милләтнең акчага булган ихтыяҗы зур һәм хөкүмәт боларны онытып җибәргән кебек. Хөкүмәт үзе дә акчага мохтаҗ. Менә шундый уйлар белән, мәмләкәтебездә, һич югы елда ике ай, ат ярышларында комар уенын ирекле итәргә уйлаган идек. Җийоги Эн карар да чыгарган иде. Тик Кизоки Эн карарыбызны юкка чыгарды, чөнки ул һәрвакыт хөкүмәт кулында». «Бик гаҗәп, ат ярышларындагы комар уеныннан нинди файда өмет итә идегез?» – дип сорадым. Шулвакыт кыңгырау чыңлады, утырыш залына керә башладылар һәм минем соравыма җавап алу өчен вакыт калмады. Икенче утырыш бик шау-шулы узды, тик мин, телне яхшы белмәвем сәбәпле, күп нәрсәне аңлый алмадым. Болай дип әйтергә мөмкин: хәлләр, хәбәрләр дәрьясыннан тамчылап белем туплыйм.

Төрекчәдән
***Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ *татар китабы*

Хатыйп Миңнегулов,
КФУ профессоры

«МИН – БӘХЕТСЕЗ ТАТАР УЛЫ...»
(Шиһаб Нигъмәти. – 1913-1995)

XX гасырның беренче яртысы үзенең коточкыч сугышлары, канкойгыч, афәтле вакыйга-хәлләре белән, мөгаен, тарихта тиңсездер. Йөз миллионлап кеше кырыла, исәпсез-хисапсыз шәһәр-авыллар җимерелә, Идел суыдай кан-яшь түгелә, ятим балаларның, тол аналарның аһ-зары күкне кара болыт кебек каплый. Элек-электән сугышып яшәгән Россия империясендәге, аның дәвамчысы булган Советлар Берлегендәге сугышлар, инкыйлаби хәрәкәтләр адәм балаларының тормыш-яшәешен кырмыска оясыдай туздыра. Бу бәла-афәтләрнең авырлыгы аеруча берничә гасыр буе дәүләтсезлектән, хокуксызлыктан, колониаль изелүдән җәфа чиккән татар халкына төште. Аның миллионлаган угыл-кызлары корбан булды, гомер кичергән җирләреннән күчеп, качып китәргә мәҗбүр ителде. Шактый өлеше чит мәмләкәтләргә дә барып эләкте. Шундый катлаулы язмыш ияләренең берсе – Шиһаб Нигъмәти (Шиһабеддин Нигъмәтуллин). Ул чордашларына, өлешчә, хәзерге буынга да мөгаллим, шагыйрь, публицист, журналист буларак теге яки бу дәрәҗәдә билгеле. Кызганыч ки, аның тормыш юлы, әдәби-публицистик эшчәнлеге юньләп өйрәнелмәгән. Бу билгеле бер дәрәҗәдә аңлашыла да. Ш.Нигъмәти – сугышта әсирлеккә эләгеп, концлагерь газапларын күреп, ахырда Алманиядә яшәп калган зат. Ә андый кешеләргә исә Советлар Берлегендә, гомумән, тискәре мөнәсәбәт яшәде, алар еш кына «дошман», «хыянәтче» дип бәяләнде. СССР таркалганнан соң мондый караш (аеруча урыс дөньясында) уңай якка шактый үзгәрде: әмма әле ул элеккеге тенденциозлыктан һаман да тәмам арынып җитә алмый. Бу уңай белән гасырлар буена сыналган бер инсани хакыйкатьне истә тоту зарури. Кеше ул, кем генә, нинди генә булмасын – адәм баласының улы-кызы, Аллаһы Тәгаләнең колы, табигатьнең җан иясе; шуңа күрә һәр инсан үзенә игътибарга, үз язмышын гадел аңлауга-аңлатуга мохтаҗ.

Мөһаҗир татарлар, аларның тарихы, бигрәк тә язма мирасын өйрәнү белән инде без фәкыйрегез чирек гасырдан артык азмы-күпме (булдыра алган кадәр) шөгыльләнеп килә. Бу юнәлештә язылган йөзәрләгән мәкалә-хезмәтләрем, хәтта берничә китабым да бар [1; 27; 3]. Аларда, башка мәсьәләләргә, бүтән авторларга мөнәсәбәттә, Ш. Нигъмәти исеме дә атала, аның хакында да кайбер мәгълүматлар, фикер-күзәтүләр бирелә [3: 19, 218, 224, 232-233...], хәтта бу затның аерым шигырьләре дә («Бул каһарман», «Туган илемә», «Байкал»...) укучыларга тәкъдим ителә.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2020) санында.

Шиһаб Нигъмәти



Ş.Niğməti

Şiğъrlarъ

MUNXEN — 1953

Çinovъ həm redaktorъ Ajaz Hakimoglu



Kötə mikən?

Jəş jegetkəj kötte cit ilərgə,
Tuъp yekan ilen qaldъrъp.
Jat millətkə xezmət itte,
Sağъş belən jörək jandъrъp.
Könbatъştan kilde tep tavъşъ,
Qanlъ suğъş anda başlandъ.
Jəş jeget tə qurqmadъ,
Suğъş utlarъna taşlandъ.
Östəl artъnda utъra jəş qъz bala,
Tin-tin jöri anъŋ qələme.
Tön joqlamъj utъrъp xat jaza da,
Çitməs inde anъŋ sələme.
Kyptən inde jeget suğъş qъrlarъnda,
Məŋge ujanmasqa joqlağan.
Qan ağъzъp anъŋ jəş jörəge,
Xərəkətsez kyptən tuqtağan.
Ol, juldan çabъp par at kilə,
Qъŋğъravlъ pocta atlarъ.
Ələ də bulsa jəş qъz kötə mikən,
Kilməsme, — dip uјlam xatlarъ.

Vustrav, 1942, Köz.

[illegible]

Qan ockəler tuğan urman aşa
Ytte minem barъr jullarъm.
Julğa sъa anda adəm qanъ.
Qaraŋğъ tön torğan jullarъm.
Qara urman, qaraŋğъ tön,
Suqmaqlarъ batav, salim majaqlar.

3

Ш.Нигъмәтинең 1953 елда Алманиянең Мюнхен каласында «Шигырьләр» исемле җыентыгы дөнья күрә [4]. Бу язмада без төп игътибарыбызны әнә шул мәҗмугага юнәлтәчәкбез. Әмма турыдан-туры аңа керешкәнче, авторның тәрҗемәи хәленә, гомуми эшчәнлегенә мөнәсәбәтле кайбер фикерләрне кыскача гына бәян итик.

Интернет мәгълүматлары күрсәтүенчә [5], Ш.Нигъмәти – Көнбатыш Себердән. Ул 1913 елда хәзерге Төмән өлкәсендәге Вагай районының Рәнчек авылында туган. Иртеш елгасы буендагы бу кария Себернең электән үк мәшһүр административ, мәгърифәти үзәге булган Тубыл шәһәреннән 60-70 чакрым ераклыкта гына. Шунысын да искә төшерик: туган төбәге Ш.Нигъмәтинең иҗатында да еш телгә алына. Мәсәлән, аның 1943 елның җәендә «хәрби әсирләр лагеренда» иҗат ителгән «Иртеш» шигыре [4: 46-47] мондый юллар белән башланып китә:

Бүгенгедәй әле күз алдымда
Анам, авылым, Иртеш буйлары...

Алга таба автор туган ягының матур табигатен, анда үткән сабый, үсмер, егет чакларын искә төшерә. Автор өчен әнисе, туган авылы, Иртеш – аерылмас бербөтен төшенчәләр. Шигырьнең ахыргы юллары авыр хәлдәге лирик геройның туган ягына җылы мөнәсәбәтен аеруча калку чагылдыра:

...Элеккедәй тагын йөзәрменме,
Ак көмештәй Иртеш суында.
Ят илләрдә, Иртеш, синең кебек
Гүзәл елга һич тә күрмәдем.
Сагынам сине, сөекле Иртеш,
Илдә чакта кадерең белмәдем.
Күз алдымнан синең күренеш,
Кая барсам да, һич югалмас.
Кулларымны юган ят елгалар
Кайгыларым минем юа алмас.

Гомумән, Ш.Нигъмәти әсәрләрендә Себергә хас табигать, аның кыр һәм урманнары, елга-сулары, кош-кортлары, бу төбәкнең яшәешенә хас сыйфатлар еш телгә алына. Алга таба бу традиция Булат Сөләйманов, Шәүкәт Гаделша (Сибгатуллин) кебек соңгы чор себер татар шагыйрьләре иҗатында да уңышлы дәвам иттерелә.

Ш.Нигъмәти әүвәл үзенең туган авылындагы мәктәптә укый. Аннан педагогик уку йортында махсус белем ала. Мондый татар педтехникумнарының ул вакытта Свердловск, Төмән, Тубыл калаларында эшләве мәгълүм.

2008 елда Төмән шәһәрендә ветеран мөгаллимә Люция Бәдретдин кызы Хәбибуллинаның «Себердә татар мәгарифе (XX гасыр)» исемле гаҗәеп бай эчтәлекле, иллюстрацияләргә бай булган (44 басма табаклык) китабы нәшер ителде [6]. Көнбатыш Себердә гомер кичерүче милләттәшләребезнең мәгарифен, мәдәниятен, әдәбиятын, күренекле кешеләрен чагылдырган энциклопедик характердагы бу хезмәттә Ш.Нигъмәти хакында да кайбер мәгълүматлар бирелә [6: 267]. Баксаң, бу зат 30 нчы елларда берара Тубыл төбәгендәге Карагай мәктәбендә директор урынбасары булып эшләгән икән. Аның хакында хезмәттәшләренең мондый истәлеге китерелә: *«Житез-өлгер, эшне зур җаваплылык тоеп башкара, һәрнәрсәдән хәбәрдар, беренче көннән үк укытучылар белән уртак тел табып эшләп китте. Мәктәптә әдәбият түгәрәге оештырып, балаларны шигырь язарга өйрәтте, үзе дә шигырьләр яза иде».* Әмма Ш.Нигъмәтигә бай тарихлы, электән үк мәдрәсәле, мәчетле Карагай авылында озак эшләргә туры килми. СССР җитәкчелегенең 1939 ел 1 сентябрь әмере нигезендә, укытучыларны хәрби

хезмәттән азат итү турындагы элеккеге карар юкка чыгарыла. Шуның нәтиҗәсендә, 1939 елның октябрендә Ш.Нигъмәтуллин дә хәрби хезмәткә чакырыла.

Ул сугышның беренче көннәреннән үк фронтка җибәрелә. 1941 елның 4 ноябрендә Волхов фронтында әсирлеккә эләгә. Шактый вакытын алман концлагерьларында, зинданнарында (Vustrav, Berlin, Pozen, Mittenwald...) уздыра.

Төрмә караңгы, төрмә салкын,
Төрмә пычрак, үзе тар.
Төрмә – михнәт, төрмә – мәктәп:
Тар төрмәдә бар да бар [4:19].

«Төрмә» дип исемләнгән парчадагы бу юллар – һич тә хыял җимеше түгел, ә авторның берничә еллык тоткынлык, газап-михнәтләренең бер резюме-нәтиҗәсе, сабагы да ул.

Сугыш һәм әсирлек, – мөгаен, аерылмас төшенчәләрдер. Моны тарих үзе раслап тора. Әсирләр – хокуксыз, хуҗаларының коллары кебек. Аларны кыйнарга һәм үтерергә дә, эшләтергә һәм азат итәргә дә, үз максатында төрлечә файдаланырга да мөмкин. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында күп меңләгән немецларның һәм алман яклыларның Советлар Берлегендә әсирлектә булулары, аларның катлаулы язмышы күпләргә билгеле. Алмания ягына әсирлеккә эләккән урыслар һәм Советлар Берлегендәге кайбер башка кавем кешеләре аеруча күп була: мөгаен, аларның саны миллионнан артып китәдер. Алман хакимияте бу төр әсирләрнең шактыен төрле юллар белән юк итә. Әмма зур өлешен үз максатларында да файдалана. Генерал Власовның «Урыс азатлык армиясе» – шуның гыйбрәтле бер мисалы. «Азатлык» дигәндә, монда, иң беренче чиратта, илне большевиклар хакимиятеннән азат итү күздә тотыла. Нигездә, 1942 елда әсирләрдән Кавказ, Төркестан легионнарын төзү башлана. Бераз гына соңрак «Идел-Урал легионы» оештырыла. Анда катнашучыларга «большевизмнан» азат үз мөстәкыйль дәүләтләрен төзү дә вәгъдә ителә. Бу төр легионнарга әсирләрне тарту, аларны оештыру, тәрбияләү өчен бик күп төрле чаралар үткәрелә. Хәтта 1944 елның 4-5 мартында Алманиянең Грайсфальд шәһәрендә шактый тантаналы шартларда Идел-Урал легионының махсус корылтае да уздырыла. Татар-төрки әсирләре белән беррәттән, бу чарада алман хакимияте вәкилләре, галимнәр, сәясәтчеләр дә катнаша. Анда легионның гына түгел, ә, гомумән, татарларның, Идел-Урал буе халыкларының киләчәгенә кагылышлы мәсьәләләр дә карала, резолюцияләр дә кабул ителә.

«Идел-Урал легионы»ның язмышы төрле хезмәтләрдә [(бигрәк тә И.Гыйләҗевнең «Легион Идел-Урал» монографиясендә (К., 2006)], «Моабит дәфтәрләре» авторына һәм, гомумән, җәлилчеләргә мөнәсәбәтле хезмәтләрдә шактый тулы яктыртылыш тапкан.

Әсирлек, лагерь газапларыннан иза чиккән, үз милләтенең язмышы хакында һәрчак уйланган Шиһабеддин Нигъмәтуллин да, мөгаен, озак баш ватканнан соң, «Идел-Урал легионы» сафларына тартылгандыр. Биредә аның шактый эшчәнлек алып баруы билгеле. Аерым язмаларда Ш.Нигъмәтинең 1944 елның көзендә легионда катнашучыларга татар тарихын укытуы, шулай ук «Идел-Урал» гәҗитенең мөхәррире итеп билгеләнүе телгә алына [Александр Петрушин. Остаться учителем//«Тюменский курьер». – 28 апреля, 3 мая 2007 г.] [3]. Хәтта ул 1944 елгы корылтайда легионерлар арасында аңлату, тәрбия мәсьәләләре буенча доклад та сөйли. Кайбер хезмәтләрдә аның җәлилчеләр белән аралашуы, татар басмаларында чыгышлар ясавы да телгә алына [5; 6: 267].

Ш.Нигъмәти сугышның тәмамлануын Алманиянең Америка гаскәрләре оккупацияләгән өлешендә каршы ала. Мәгълүм ки, ул үзенең күп кенә әсәрләрендә үзе өчен бик тә газиз булган туган илен яратуы, аңа тартылуы хакында яза:

...Син дә ярат мине, туган илем,
Мин бит синең үз улың.
Минем өчен иң кыйммәтле,
Син генә бит минем күз нурым [4: 46].

«Мөһаҗир уйлары» парчасы мондый юллар белән башланып китә:

Мин илемдә көтүче булсам икән,
Күп сарыкка үзем баш булып.
Яшел чирәмдә аунап ятсам икән,
Тал тамырларына баш куеп [4: 41].

«Сугыш беткәч» шигырендә [4:12] авторның теләк-омтылышлары тагын да тулылана төшә:

...Ятлар йорты туйдырды инде,
Күптән вакыт илгә китәргә.
Үз йортыма кайтып, халкым белән
Эшләп, җырлап гомер итәргә.

Ш.Нигъмәти, гәрчә туган Иртеш-Иделләрен бик сагынса, газиз ватанына бик тартылса да, әсирлектә булган кешеләрне илдә нинди язмыш көтүен белеп, шактый гына илдәшләре, милләттәшләре кебек, мөһаҗирлектә кала. Хәтта аның, куркынычсызлык, сәяси максатларны күздә тотып, «Аксам Йосыф углы (Aksam Josefoglu) исеме белән Төркия ватандашлыгын алуы» да искәртелә [5; 6: 267]. Әмма 1946 елда язылган «Мин – төрек» парчасындагы түбәндәге юллар бу фактның рәсми ягын бераз шик астына да ала:

Булмаса да кесәмдә төрек пасы (паспорты. – Х. М.),
Йөрәгемдә төрек каны ага [4: 17].

Шунысы кызык: «төреклек» мотивы Ш.Нигъмәтинең бары тик ике шигырендә генә күзгә ташлана (берсе – «Төрек дөньясына» дип атала. Ул да 1946 елда язылa). 1953 елгы җыентыктагы әсәрләрдә автор үзенең татарлыгына һәрчак басым ясый:

...Әй, татарым, әй, син, җаным!
Сөекле милләтем минем!
Юктыр иркен, әй, ватаным,
Юктыр бәхтең синең [4: 17]. (1948 ел)

Ш.Нигъмәти сугыштан соңгы елларда Көнбатыш Аурупадагы татар милли хәрәкәте үзәгендә кайный, төрле иҗтимагый-мәдәни чаралар оештыруда актив катнаша, әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә, гәҗит-журналларда языша. Мәсәлән, 1952-1953 елларда Мюнхендә нәшер ителгән «Азат Ватан» журналында аның дистәләгән шигыре, мәкаләләре басылган [Болар һәм, гомумән, бу мәҗмуга хакында: 3: 216-241; 7]. Мәсәлән, «Диния нәзарәте (төзелүенә – 164 ел)» исемле язмасында (№ 7. – 15-17 б.) Ш.Нигъмәти татар-башкорт тарихын ислам диненә мөнәсәбәттә яктырта. Автор карашынча, Рәчәйдә XVI йөздән башлап татарга каршы кыру, юк итү сәясәте уздырыла. «Татар башкорт халкына рухи көч бирүче ислам дине икәнлеген аңлаган басып алучылар,– ди ул,– беренче нәүбәттә аларның дин башлыкларын – руханиларны һәм укымышлыларны кырдылар, мәчет һәм мәктәпләрне яндырдылар...»

Ш.Нигъмәтинең сугыштан соңгы төп эшчәнлеге, әлбәттә, Мюнхендә урнашкан «Азатлык» радиосы белән бәйле. Ул биредә әүвәл татарча тапшыруларның хәбәрчесе, ә 1954-1979 елларда мөхәррире булып эшли. Бераз вакыт бу радионың «мөхәррирләр советы директоры» да булып тора. Аңа 1989 елда туган иленә кайтырга рөхсәт ителә.

Әмма, күрәсең, ниндидер җитди сәбәпләр аркасында, ул күптәннән омтылган теләгенә ирешә алмый, 1995 елда мөһаҗәрәттә вафат та була.

Миңа, Ш.Нигъмәти кебек сугыш, әсирлек газапларын кичергән, ярты гасырлап гомерен мөһаҗирлектә – Алманиядә уздырган шагыйрь Минһаҗ ага Исмәгыйли белән (1910-1995) берничә мәртәбә очрашып сөйләшергә туры килде. Аның хакында язмаларым да бар [3: 243-285]. 80-90 нчы елларда ул Алманиядән асыл Ватанына кайтып-китеп тә йөрде. Кабере дә туган авылы Шыгырданда. Минһаҗ ага чордашы Шиһабеддин Нигъмәти белән аралашуларын, аның туган җирен өзелеп сагынуын, Иртеш буйларын күрәсе килүен, моңаеп җырлавын, вакыты-вакыты белән елап та алуларын кат-кат искә төшерә иде... Шулай ук аның укымышлы булуы, берничә телне белүе хакында әйтүе дә хәтердә калган.

Ш.Нигъмәти яшьтән үк әдәбиятны, үз халкының моң-җырын ярата. Әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Әмма аның бу чорда язганнары шәхсән миңа хәзергәчә билгеле түгел.

Еш кына гадәттән тыш шартларда кешенең иҗади сәләте ачылып китә яисә элеккеге шөгыленә тартылуы көчәя. Безнең дистәләгән әдип-шагыйрьләребезнең (Г.Исхакый, Х.Туфан, Ф.Кәрим...) шактый гына әсәрләре төрмә-зинданнарда, сугыш кырларында иҗат ителгән. Шунысы гыйбрәтле: бу күренеш аеруча иленнән аерылып, әсирлек газапларын кичергән иҗат әһелләренә хас. М.Җәлил, А.Алиш, Х.Мөҗәй һ.б. – моның ачык мисаллары. Аерылу, сагыну, коточкыч авырлыклар, күрәсең, адәм балаларының күңелләрен айкый, уй-кичерешләрен көчәйтә, рухи халәтләрен тагын да ныграк кузгата.

Ш.Нигъмәти дә әсирлектә, мөһаҗәрәттә әдәби иҗатын дәвам иттерә. Әмма, ни кызганыч, аларның шактые юкка чыккан, югалган. Әмма шулай да аның 1953 елда дөнья күргән җыентыгының төп өлешен алман төрмә-лагерьларында язылган шигырьләр тәшкил итә. Мюнхенда латин хәрефләре белән нәшер ителгән бу китап аның төзүче-редакторы **Аяз Хәкимоглы** дигән кешенең бер битлек кенә «Кереш сүзе» белән ачыла. Анда мондый юллар да бар: *«Ирек сөюче татар улы – Нигъмәти әфәнденең шигырьләрендә җир йөзендәге гаделсезлекләрне чагылдыруы, татар халкының үткәндәге тарихы белән горурлануы, бүгенге көндәге тоткынлыгы белән хурлануы һәм халкыбызны милли азатлык өчен көрәшкә чакыруы күренә»* [4: 1] .

1953 елгы китап хакында сүз барганда, шунысын да махсус искәртү гөнаһ булмастыр. Ул бик тә мөһим, гыйбрәтле уй-кичерешләргә, образ-сурәтләргә, шигъри чараларга шактый бай. Әмма анда бәхәсле фикерләр, әдәби яктан эшләнеп бетмәгән, прозага тартым юллар да, ритмик төгәлсезлекләр, рифма тиешенчә сакланмаган урыннар да күзгә ташлана. Бу төр җитешсезлекләрнең зур өлеше, әлбәттә, авторның әсирлектәге тереклеге, мөһаҗәрәттә яшәве белән аңлатыла. Шигырьләрнең хәзерлекле, таләпчән мөхәррир кулыннан үтмәве дә үзен нык сиздереп тора. Ничек кенә булмасын, без ул текстларны оригиналдагыча калдырырга тырыштык – каләм тыкмадык.

49 битлек бу җыентыкта авторның 69 шигыре урнаштырылган. Алар төрле зурлыкта. Арада хәтта робагый-дүртъюллыклар да бар. Шигырьләр, нигездә, лирик характерда. Бары берничә әсәрдә генә эпиклык элементлары күзгә ташлана («Бүре белән сарык» мәсәле, «Җәллад»...). Китапта бер тәрҗемә үрнәге дә бар: ул да булса – Лермонтовның «Җилкән» шигыре [4: 32-33]. Ул мондый юллар белән башлана: *«Зәңгәр диңгез өстендә ап-ак җилкән Күренә ялгыз томан эчендә...»*

Мәгълүм булганча, узган гасырның 30-50 елларында Алманиядә татар телендә аерым китаплар нәшер ителә, гәҗит-журналлар чыгарыла («Яңа милли юл», «Идел-Урал», «Очар яфраклар», «Милли Байрак» һ.б.). Боларның кайберләрендә, бигрәк тә «Азат Ватан» журналында Ш.Нигъмәтинең дә аерым шигырьләре нәшер ителә. 1953 елгы җыентыкта да аларның бер өлеше урын алган.

Инде моңа кадәрге сүз сөрешеннән Ш.Нигъмәти китабының, шулай ук аның иҗатының аерым сыйфатлары күрсәтелде, атап кителде. Шуларга өстәп, янә кайбер фикер-күзәтүләребезне бәян итәбез.

Шагыйрьнең 1953 елгы җыентыгы милли рух белән сугарылган. Ул андагы әсәрләрнең эчтәлегендә, идея-тематикасында, образ-сурәтләрендә, тел-стилендә ачык күренә. Автор үзен чын мәгънәсендә үз милләтенең – татарының улы дип хисаплый. *«Минем күңлем халкым өчен, Кайгыра һәм шатлана»*, – ди ул. Һәм, аларга өстәп, мондый юлларны да язып куя: *«Яшә, милләт! Яшә, татар! Яшә, халкымның моңы!»* [4: 37-38]. Шагыйрь өчен «моң», «җыр» – татар яшәешенең, милләт асылының бер символы, авыр-кыен вакытларда күңел таянычы, иптәше, юлдашы:

...Беркемем юк бу ят илдә,
Моңланам тик ялгызым.
Кара болыт каплап алды
Минем бәхет йолдызын.
Калды хәзер бу дөньяда
Бер генә юанычым:
Ул да булса – милли тойгым, –
Ул гына – куанычым.
Мин – бәхетсез татар улы
Авырлыкка түзәмен.
Моңнарымны җырлый-җырлый,
Кайгыларым басамын...
(«Иптәшем») [4: 37].

Гомумән, Ш.Нигъмәти шигырьләрендә «җыр», «моң» төшенчәләре шактый еш очрый. Минһаҗ ага Исмәгыйли сөйләвенчә, ул матур итеп җырлаган, «көйләгән» дә.

Ш.Нигъмәтинең милли уй-кичерешләре хакыйкый чынбарлык, халкыбызның данлы да, фаҗигале дә озын-озак тарихы белән тыгыз бәйләнешле. «Татар хатыны» (1948) шигырендә ул татарның үткәнен, Чыңгыз дәверләрен, Болгар-Алтын Урдаларын, Сөембикәләрне, Казанның канга батырылуларын искә төшерә. Шушы тарихи яссылыкта шагыйрь ир-атлар белән тигез сафта басып килүче «татар хатыны»на дан җырлый, мактау-сәналар укый, аның батырлыгына, түземлелегенә, тугрылыгына соклануын белдерә. Публицистик рухлы бу шигырь шушындый юллар белән төгәлләнә:

...Һәм бүген дә горур татар хатыны,
Әйдә, безнең белән зур эшкә!
Утка ташлап шәхси тормышыңны
Милләт ирке өчен көрәшкә! [4: 31].

Ш.Нигъмәти, туган төбәген, Себернең урман-суларын, киң сахраларын, Иртешләрен мактаса да, татар дөньясын киң планда карый. Аның өчен Идел буйлары да якын-үз:

Әнә анда биек ярдан төшеп,
Татар кызы салкын су ала.
Чиләккәен батырып су алганда,
Елга сукайлары комлана.
Комланганда елга суына карап,
Татар кызы анда моңлана.
Әй син, Идел, – гүзәл елага (? – Х.М.).
Ничә гасыр инде коясың?

Ничә еллар инде татарларның
Кан, күз яшькәйләрен юасың?.. [4: 44].

Аурупада Альп тауларыннан башланып, Мюнхен тирәләреннән үтеп, Дунайга коючы Изар исемле елга бар. Алман сүз сәнгатендә, җырларында ул еш кына бездәге Агыйдел кебек мактала. Ш.Нигъмәти дә үзенең бер шигырендә бу елганың матурлыгын тасвирлый. Әмма әлеге парчаның соңгы юллары бик тә гыйбрәтле тәгәлләнә:

...Гүзәл Изар, ләкин аны
Тиңли алмыйм Идел буена [4: 39].

Ш.Нигъмәти үз халкының, «иленең» үткәнен генә түгел, хәзерге хәлен, аның хокукусызлыгын, дини, милли, мәгърифәти яктан кысынкылыкта яшәвен яхшы белә, аны шушы хәлдән чыгарырга, хөр, бәхетле итәргә омтыла:

...Син каксаң да мине, каргасаң да,
Авырсынмам синең сүзеңне;
Көрәшәмен, илем, көрәшәмен,
Азат итәр өчен үзеңне.
(«Туган илемә») [4: 46].

Бу юлда ул үз укучыларын «Мин – ирексез милләт улы» дип «зарланмаска», үз-үзеңне «түбәнсетмәскә», «курыкмыйча, «каһарманнардай» көрәшеп, «коллык богауларын өзәргә» чакыра [4: 7]. Ирексезлек, гомумән, – адәм баласы өчен зур газап. Әмма чит-ят илләрдәге, әсирлектәге тоткынлык, мөгаен, – газапларның да газабыдыр. Әсирлектә иҗат ителгән күп кенә әсәрләр моны ачык күрсәтә. Тоткынлыктагы башка каләм әһелләре кебек, Ш.Нигъмәти шигырьләрендә дә төрмә-лагерьларда михнәт чигүчеләрнең рухи халәтләре калку гәүдәләнеш тапкан. Кара язмышка тарыган лирик герой бәргәләнә, үзен карурманда, караңгы төндә адашкан кеше кебек тә тоя, очар кошлар (кәккүк, сандугачлар), исәр җилләр аркылы иленә, туган якларына сәламнәр юллый, анасыннан, якыннарыннан хәбәрләр көтә, узган гомере, яшьлеге, мәхәббәте хакында уйлана. Җирсү-сагыну мотивы шагыйрьнең бөтен әсәрләре күзәнәкләренә сеңгән. Автор бу төр шигырьләрендә, сурәтләү предметына, тематикасына нисбәттән, капма-каршы (антитеза, контраст), янәшә кую алымнарыннан иркен файдалана: тоткынлык – ирек, туган ил – чит-ят җир, тарих – хәзерге заман, караңгы төн – нурлы кояш һ.б.

Әдәбият

1. Хатыйп Миңнегулов. Исхакый мөһаҗирлектә: Монография. – Казан: Таң-Заря, 1999. – 84 б.
2. Хатыйп Миңнегулов. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектән иҗаты: Монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 367 б.
3. Хатыйп Миңнегулов. Чит илләрдәге татар әдәбияты: Монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.
4. Ш.Нигъмәти. Шигырьләр / Җыйнаучы һәм редакторы Айас Хәкимоглы. – Мюнхен, 1953. – 49 б. (Латин язуында).
5. https: //tt. Wikipedia org/Wiki/Шиһап Нигъмәти. Бу материалны һәм А. Петрушин язмасын безгә интернеттан табып җибәргәне өчен, Татарстан Милли китапханәсе директорының урынбасары Ирек Һадиевка зур рәхмәт.
6. Л.Б.Хәбибуллина. Себердә татар мәгарифе (XX гасыр). (Из истории народного образования Тюменской области в XX веке). – Тюмень: ОАО «Тюменский дом печати», 2008. – 528 б.
7. Хатип Миннегулов. «Азат Ватан»: скорбь и надежда (Татарский журнал в Германии) // Журнал «Татарстан». – 2003. – № 3. – С. 58-62.

Дәвамы киләсе санда ■

Балдаклы хыянәт*

Хәйдәр

Хәйдәр (Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов) (1952-2000) – шагыйрь, язучы, тәрҗемәче.

Узган кыш авылдан Айбулатның бабасы Сафиулла карт кунакка килгән иде.

Бабасының күчтәнәчләр төяп килеп төшүе Айбулат өчен бер бәйрәмгә әверелде. Анысы, Айбулат күчтәнәчләргә кызыкмый, тәмле әйберләргә аның мохтаҗлыгы юк, аңа бабасы кадерлерәк, аңа Казан урамында бабасы белән йөрү тансык. Кичке табын янында авыл күчтәнәчләреннән авыз итеп, хәл-әхвәл сорашып утыргач, йокларга әзерләнделәр: бабасы шулай соңга калып килеп төшкән иде. Айбулатның әбисе белән бабасы еракта яши – башта тимер юл станциясенә кадәр машинада килергә кирәк, аннары поездга күчеп утырасы. Авылдан иртүк чыгып китсәң дә, Казанга төнлә генә килеп җитәсең...

Рита аларның өчесенә дә – Айбулатка да, Мансурга да, Сафиулла картка да урынны залга җәйде. Болай итүе бик әйбәт булды: Сафиулла карт, арып килдем, дисә дә, ярты төн узганчы улы Мансур белән гапләшеп ята, әллә нинди кызыклы тарихлар сөйли. Айбулатка рәхәт – юрганга төренеп, бабасы сөйләгән кыйссаларны тыңлый...

Бу килүендә дә Айбулат өчен шактый кызыклы әңгәмә башланып китте. Утны сүндергәннәр иде инде, Мансур мендәрдән башын калкытты да:

– Хәтерлисеңме, әти, мин бала чакта авылга сукыр скрипкачы килгән иде?.. – дип сорады.

– Беләм, минем таныш иде ул... – диде Сафиулла карт. – Оста скрипкачы иде, шәп уйный иде.

– Менә шул турыда синнән сорарга теләгән дә идем инде, – диде Мансур. – Шуның язмышы кызыксындыра мине...

– Озын тарих ул, сөйләсәң, әллә кайларга кереп китәргә туры килер...

– Җәйнең бик матур көне икәне хәтеремдә калган.

– Мин үз гомеремдә сукыр скрипкачыларны аз күрмәдем. Безнең авылга да бик еш килә торганнар иде. Кайберләре, акча җыю нияте белән, юри дә сукырга салынып йөрделәр инде. Син әйткәне шул булса...

– Менә болай, – дип, аны бүлдерде Мансур. – Безнең авылга мин бала чакта ике сукыр скрипкачы килгәнен беләм. Кайсы еллар икәнен хәтерләмим. Икесе ике кеше булдымы алар, әллә икесе дә бер кешеме?.. Тик менә берсенең бездә кунып чыкканлыгын беләм. Сез аның белән келәттә икәү бергә йокладыгыз... Ни сөйләшкәнсездер – анысы миңа караңгы.

*Шул исемдәге әсәрдән өзек.

– Әйе, әйе, – дип, җанланып китте Сафиулла карт, хәтта торып ук утырды. – Алайса, син минем танышны әйтәсең инде... Таныш кынамы соң, минем җан дустым иде ул! Әй, гомерләр!.. Кара, мин аны картлыгым белән оныта да язганмын инде. Ярый әле хәтергә төшердең.

– Каян танышлар идегез соң сез, эти?

– Без бит Алабуга культура-агарту училищесында бергә укып алган идек. Озак түгел инде. Шул ярты ел, бер ел чамасыдыр. Тумышы белән Минзәлә якларыннан иде ул. Авылының исемен хәтерләмим инде, исемнән чыккан. Бордыбаш, дип әйтимме, Зичәбашмы әллә? Ходай белсен инде... Менә шул. Бездә кунып чыккан булса, әнә шул скрипкачы инде ул.

Мансур торып утырды, утны кабызды, китап шкафыннан нидер караштырды, янә утны сүндерде.

– Тумыштан сукыр булмагандыр ич ул, эти? Училищеда да укырлык булгач, дип әйтүем?

– Юк инде, нишләп сукыр булсын?! Сау-сәламәт егет иде. Харап иттеләр шул...

– Ничек харап иттеләр?

– Сталинның культ чоры башлангач... Укып беләсеңдер, ул чакта кешене төрмәгә тыгу берни дә тормый иде. Ике-өч кеше берләшеп, бер кеше өстеннән шикаять язып бирсәләр – беттең исәплә.

– Шулай да сәбәпсез эшләнмәгәндер ләбаса? Шикаять язып бирүчесе дә тиктомалга андый юлга басмас...

– Тиктомалдан түгел. Бер дә тиктомалдан түгел. Көнчелек хәрәкәткә китерә андый шикаятьчеләрне, көнчелек! Бу егеттән дә берничә малай бик каты көнләшкән.

Бабасы белән этисенең әңгәмәсе бигүк аңлашылып бетмәсә дә, Айбулатка куркыныч була башлады. Юрганына ныграк төренде. Тәрәзәдән балкыган айны алып китәрләр кебек тоелды... Хәзер, менә шушы төн уртасында, фатир ишеген каерып ачарлар да, өйгә таныш түгел кешеләр килеп керер кебек иде. Сталин чоры турында өлкәннәрдән ишетеп белә: куркыныч булган ул чакларда...

– Алар бер үк авылдан бер егет, бер кыз – икәүләшеп укырга килеп кергәннәр иде, – дип сүзен дәвам итте Сафиулла карт. – Авылда күршеләр генә булып яшәгәннәр. Сабый чакта бергә уйнап үскәннәр, бер мәктәптә бергә укыганнар. Инде үсеп җиткәч, безнең халыктагы гореф-гадәт буенча, егет белән кызга аралашырга ярамый. Егет кызны нык яраткандыр, ахрысы, авыл кешеләре арасында яманатлары чыгудан да курыкмыйча, кызый белән күрешкәләгән... Моны ул соңыннан, теге чакны келәттә йоклаганда, сөйләп ятты. Күрешү – күрешү, аны нихәтле генә яшерергә тырышсаң да, йомып калып булмый, каһәр. Монда да шулай була: кызның этисе белән әнисе сизенеп ала, егетне кисәтәләр. Шуннан нишләргә кала инде: тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлагач, егет белән кыз авылдан китәргә, берәр шәһәргә барып, укуларын дәвам итәргә сүз куешалар. Егет скрипкада бик оста уйнаса, кыз матур итеп җырлый белә икән. Райкомолда боларга Алабуга шәһәрендәге культура-агарту училищесына барып карарга киңәш итәләр. Әнә шул киңәш белән алар училищега килеп керделәр.

***

Менә бу кыз да, мескенкәй, эти-әнисенең сүзен тыңлап кияүгә чыккан булса, бәлки, исән дә калыр иде әле...

– Нишләде? – дип шомланып сорады Мансур. – Үлдеме? Үтерделәрме?

– Үлде дисәң дә, дөреслеккә туры килми инде, – дип, тамагын кырып алды Сафиулла карт. – Үтерүен үтермәделәр, үз-үзенә кул салырга мәҗбүр иттеләр. Болай булган. Безнең

анда сталинчы бер төркем малай бар иде. Шул малайларның берсе әлеге кызга кызыккан, үзенеке итәсе килгән. Шәхес культы чорында кешенең котын алып каршыңа тезләндерү җиңел эш иде. Бу малай да, иптәшләре белән сүз берләшеп, теге кызны комсомол комитетына чакыртып керткәннәр. «Менә шулай-шулай, этиеңнең халык дошманы булуы ачыкланды, – дигәннәр. – Өлкәдән кәгазь килеп төште, – дигәннәр. – Сине эзлиләр», – дигәннәр.

– Ах, кабахәтләр, – диде Мансур, тешләрен шыгырдатып. – Кара нинди җиңел юл тапканнар, ә?!

– Берсе әйткән: «Син этиеңне дә, үзеңне дә бәладән коткара аласың. Мин сиңа юлын өйрәтәм, – дигән. – Безнең сүзне тыңласаң, барысы да ал да гөл булачак», – дигән. Кызыйның андый гөнаһка барасы килмәгән... Тулай торагындагы ятагында язу калдырган да юкка чыккан.

– Анда нәрсә дип язды икән? – дип, кызыксынып сорады Мансур.

– Анда ул болайрак дип язган: «Минем этиемнең халык дошманы булуын ачыклаганнар. Әтием халык дошманы булгач, Совет җәмгыятендә үземне яшәргә лаек дип саный алмыйм, суга батып үләм. Хушыгыз!» – дигән. Язуның табылуын барыбыз да белеп алдык, кызыйны эзләргә чыгып киттек. Декабрь ае, чатнама суык. Камада боз каткан чак... Күз алдыма китерсәм, хәзер дә тәннәрем чымырдап китә.

Төркем белән елга өстеннән карга бата-чума бер шәүләнең йөгергәнен шәйләп алдык. Андый чакта була бит ул: качкан кеше, куркытылган кеше сине коткарырга киләләр дип белми, киресенчә, артыннан эзәрлекле чыкканнар дип белә. Без кычкырабыз тегеңә, ул аның саен йөгерә. Тавыш юньләп ишетелерлек ара түгел инде, шактый еракта...

– Теге малайлар котын алганнар инде... – дип куйды Мансур.

– Алмыймы соң инде!.. – Сафиулла карт суны аз-азлап кына кабып эчеп куйды. – Кыз балага җитә кала инде. Җитмәсә, авыл баласы бит әле ул, кем нәрсә әйтсә, шуңа ышана. Теге малайлар әйткәннең дөреслеген тикшереп тору кая ул?! Аннары, тәкъдимнәренә дә күнә алмый инде: безнең халыкта кызлык намусын саклау бик көчле бит... Намусын пычраттымы – ул инде кеше арасында яшәргә яраксыз исәпләнә. Белмим, хәзер ничектер, элек шулай иде. Мин хәзерге яшьләрне белмим. Аннары, безнең заманда шәригать кануннары да халыкны бик нык тәрбияли торган иде шул. Калганын иртәгә сөйләшеп бетерербез, яме, бүгенгә җитеп торыр.

– Иртәгә ял көне әле, беребезнең дә эшкә барасы юк, – диде әңгәмәне өзәргә теләмәгән Мансур. – Карале, эти, бу картина мин уйлаганнан да шәбрәк булачак бит болай булса! Ярый сөйләттердем әле, – дип, этисенең күңелен күрергә тырышты.

– Кама уртасындарак балыкчылар ачкан бәке булган икән. Кызыбызны инде куып җиттек дигәндә генә, бәкегә төште дә китте... – дип, кыйссасын ялгап җибәрде Сафиулла карт. – Барыбыз да «аһ» иттек!.. Кем уйлаган аны шулай кыланыр дип?! Кем уйлаган анда бәке бардыр дип?! Кирәк бит инде, әй... Инде куып җиттек, инде тоттык дигәндә генә бит... Төште дә китте... Шундук таш кебек аска китте, иелеп карадык – киемнәре белән акрын гына су төбенә төшеп бара. Әй, кызганыч та соң, әй, шул кызны кызгануыбыз! Теге скрипкачы дустыбыз, тартып чыгарам мин аны дип, бишмәтен үк сала башлады. «Нишлисең, тиле?!» – дибез. «Әллә синең дә су төбенә ычкынасың киләме?!» – дибез. «Миңа ансыз яшәү юк! Мин аны коткарырга тиеш!» – дип кычкыра. Бер малайның кесәсендә бавы булган икән, шуның бер очын биленә урап, бозлы суга төшереп җибәрдек инде. Кая ул тартып чыгару?! Менә шулай итеп, миңа коточкыч хәлнең шаһиты булырга туры килде.

– Ай-яй, – дип уфылдап куйды Мансур. – Моны тыңласаң гына да чәчләр үрә тора...

– Үлгән артыннан үлеп булмый, дигәндәй, егетне дә харап итәсебез килмәде, боз өстенә тартып чыгардык, җылы киемнәргә төрдек, тулай торакка алып кайтып, тәнен спирт белән уып карадык – тик файдасыз иде – салкын тиеп өлгергән... Шактый вакыт

авырып ятты. Савыккач, кызы өчен үч алырга теләп, теге малайларга бәйләнә башлаган. Аңамы соң иблис токымнарына каршы тора алу... «Комсомол безгә кирәкми, ул оешманы таркатырга кирәк!» – дип сөйләнеп йөри дигән ялган яла яктылар да төрмәгә озаттылар.

– Кайда сукырайган соң ул? – дип сорады Мансур.

– Себердә концлагерьда булган, шунда тагын салкын тигергән... Илле алтынчы елда гына аңа туган якларына кайтып егылырга насыйп булган... Менә шундый заманнар бар иде, улым.

– Бик гыйбрәтле тарих бу, әти, – диде Мансур. – Мин язучы булсам, һичшиксез, моны утырып язар идем. Кызганыч, язучы булмаганмын.

– Минем дустым гомере буе сөйгән кызына турылыклы булып калды. Скрипкада ул үзенең кызының гүзәллеген, сафлыгын уйный иде, үзләренең фаҗигале мәхәббәтен скрипка моңнары аша сөйләп бирә торган иде...

Мансур сикереп торды да өстәл лампасын кабызды.

– Әти! Шәп әйттең! – дип, шатланып кычкырып җибәрде ул. – Таптым, таптым!

– Нәрсәне таптың, улым? – дип, Сафиулла карт та торып утырды. Айбулат та, күзләрен угалый-угалый, әтисе янына барып басты.

– Карале, әти, кыз калдырган язуда теге егетләрнең таләпләре әйтелгән идеме икән? – дип кызыксынды Мансур.

– Әйтелгән иде, – диде Сафиулла карт.

– Мин моны картина итеп ясаячакмын! – дип дәртләнде Мансур.

– Шул картнымы?

– Картны гына түгел, әти! Рәсем сәнгатенең мөмкинлекләре чиксез бит. Барсын да сыйдырам, барсын да...

– Ай-һай... – дип, шик белдерде Сафиулла карт. – Белмим инде, булдыра алсаң, кара шунда.

– Булдырабыз аны, әти!

***

Шифаханәдән чыгып, троллейбус тукталышына барып басканнар иде инде, яннарына такси килеп туктады.

– Айбулат, кил, утыр! – дип кычкырды Рафаэль ишектән башын тыгып. – Әниеңне дә чакыр.

Рафаэльне күреп, Айбулат эсселе-суыклы булды, әнисенә күтәрелеп карады.Ританың да йөзе үзгәргән иде – ниндидер караңгылык иңгән... Болытлы көн кебек.

– Барма, – диде ул Айбулатка шым гына. – Утырма...

Димәк, Рафаэль беренче көнне килгәндә әнисе белән нидер булган... Димәк, алар нәрсәдәдер килешә алмаганнар, күрәсең, ачуланышканнар... Айбулат шулай уйлап алды. Югыйсә, әнисе болай дорфа кыланыр идеме?!

– Классташ... – диде Рита, теш арасыннан ысылдатып. – Йә, ярар, юлыңда бул.

– Мин сезне болай җиңел генә ташлап китә алмыйм ич инде, – дип, Рафаэль бер урында таптанырга кереште. – Нигә шул хәтле үпкәләдең соң әле син? Мин нинди зыян эшләдем соң?

– Суфи! – Рита Рафаэльгә арты белән басты.

– Аңладым, – диде Рафаэль. – Аңлашыла башлады... Йә, Айбулат алдында болай кирле-мырлы сөйләшеп тормыйк инде...

—Мин, гомумән, сөйләшергә теләмим синең белән!

– Хет теләсәң нишләт, мин үз-үземә хыянәт итә алмый идем. Башкаларга хыянәт итүне әйткән дә юк инде... Гафу ит!

Рафаэль шулай диде дә таксига таба атлады, кереп утырды, ишеген шапылдатып япты да таксины каты жуылдатып китеп барды.

***

Тирә-ягында куаклар үсеп утырган асфальт сукмак буйлап шифаханә капкасы янына килеп җиттеләр. Капка төбендә басып торган Рафаэльне беренче булып Айбулат күреп алды, әнисенә таба борылды: кем чакырган аны? Тагын нигә килгән ул?

– Савыгып чыгуың белән котлыйм! – дип,ерактан ук кычкырды Рафаэль. – Сәлам, Мансур дус!

Мансурның да йөзе яктырып китте, Рафаэльгә карап елмайды, кул болгады.

– Сәлам, Рафаэль! Их, йөгереп барып күрешер идем, хәзергә аяклар тыңламый,— дип акланды ул. – Ята-ята камашып беткәннәр, бераз гына ашыгып атлый башласаң, чалынып егылуың ихтимал...

Алар кочаклашып диярлек күрештеләр.

– Әйдәгез, утырыгыз, – диде Рафаэль, таксига ишарәләп. – Илтеп куям, арба әзер.

– Рәхмәт, дустым, – диде Мансур. – Менә, таныш бул. Минем хатын – Рита... Монысы минем улым — Айбулат...

– Без танышлар инде, – диде Рафаэль. – Теге көнне мин аларны өегезгә кадәр илтеп куйган идем.

– Алайса, нигә исәнләшмисез соң? – Мансур Ритага карады. – Рафаэль – бик әйбәт егет.

– Без Рита белән бер класста бергә укыдык ич, – диде Рафаэль. – Әйдәгез, утырыгыз.

Рита, нәрсәдер күзәткән булып, арты белән борылды: никах балдагын сул кулыннан уң кулына күчерергә оныткан иде ул... Мансур искәреп алмадымы икән инде? Хәрәкәтен сиздермәскә тырышып, Рита кулындагы капрон перчатканы салды, тиз генә сул кулыннан балдакны уң кулына күчереп куйды...

Мансур да, Рафаэль дә моны искәрмәделәр...

Таксига кереп урнаштылар.

– Мин әле бүген генә сезнең яңа күргәзмәне карап чыктым, – диде Рафаэль. – Рәхәтләнеп тамаша кылдым... Минем бер сорау бар иде сиңа, Мансур.

– Сора, булдыра алганча җавап бирермен.

– Син минем әтиемне күреп белә идеңме?

– Гафу ит, – диде Мансур. – Юктыр, мин синең әтиеңне белмимдер. Әле үзең белән дә очраклы гына таныштык лабаса?! Шулай түгелме?

– Шуңа аптырап соравым да инде, – диде Рафаэль, таксины кабызды, юлга алып чыга башлады. – Туры юлдан гына кайтарып куйыйм әле сезне...

Әтисенең шулай канәгать елмаеп кайтуыннан Айбулат уңайсызланды: берни дә белми, берни күрми, белергә дә теләми... Нигә, ни өчен? Малай үзен ике ут арасында итеп сизде, таксины туктатып, төшеп каласы, күзе кая карый – шунда китәсе килде... Аяклары талчыгып беткәнче, аяклары канап-суелып беткәнче, аяктан егылганчы!.. Шулай барасы да барасы иде, урман-чытырманлыклар аша, салкын елгаларны ерып чыга-чыга, сазлыкларга бата-чума барасы иде. Юлның ахырында аны әтисе генә каршы алсын иде. Бары тик әтисе генә, бары тик ул гына... Башка беркем дә кирәкми! Әтисе белән кабат монда әйләнеп кайтмасыннар иде, шунда икесе генә яшәсеннәр иде. Айбулат барсын да әтисенә сөйләп бирер иде. Ни өчен әтисен машина бәрдергәнен дә, әтисе өйдә юкта менә бу абыйның килүен дә, үз теләге белән килмәвен, әнисе чакырып китерүен дә түкми-чәчми сөйләр иде Айбулат.

Юк шул, кеше үзенең бик күп теләкләренә ирешә алмый, моңа кадәр ничек яшәгән

булса, шулай яшәргә мәҗбүр була. Айбулат әлегә бу хакыйкатьне белми. Аның бары тик теләкләре генә бар...

...Рафаэль таксины подъезд ишеге төбенә үк китереп туктатты. Рәхмәт әйтеп машинадан чыктылар.

– Саубуллашыр алдыннан шулай да беләсем килә, – дип туктатты Рафаэль Мансурны. – Син кайчандыр минем әтине күргәнсең... Югыйсә, яңа картинаңдагы скрипкачы карт минем әтигә ул кадәр үк охшамас иде... Мин шулай дип уйлыйм...

– Синең әтиең скрипкачы булмагандыр ич?! – дип, кулларын җәйде Мансур. – Скрипкачы идеме?

– Әйе, – дип раслады Рафаэль.

Мансур гаҗәпкә калды.

– Чынлапмы? Тормышта андый гына охшашлык булгалый торгандыр инде, – дип, сүзне икенчегә борырга теләде.

– Минем әти дә сукыр иде.

– Соңыннан ачыклый алмыйсызмы сез моны? – дип кыбырсый башлады Рита.

– Сабыр ит инде,—дип туктатты аны Мансур. – Хәер, керә торыгыз. Мин хәзер керермен, – диде ул Рита белән Айбулатка.

Рита подъезд ишегеннән кереп китте – Рафаэль белән янәшә басып тора алмый башлаган иде инде ул. Айбулат кымшанмады, этисе белән басып калды.

– Менә бу минем өчен яңалык, – диде Мансур, аның кашлары югары күтәрелде.— Чынлап та шулай идемени? Синең әтиең Алабугада укымаганмы?

– Әйе, укыган. Ниндидер училищеда...

– Алайса, шул бит инде ул! – дип, Мансур Рафаэльне кочаклап ук алды. – Беләсеңме, Рафаэль, безнең әтиләр дус булган.

– Без дә дус булырбыз, – дип, Рафаэль Мансурның кулын кысты.

– Әтиең исәнме әле?

– Юк... – дип авыр сулады Рафаэль. – Миңа сигез яшь тулгач вафат булды...

– Кызганыч...

– Унсигез ел концлагерьда утыру... Аңа нинди адәм баласы түзсен соң?!

– Беләм, этиеңнең язмышын беләм... – Ихтыярсыз Мансурның башы түбән иелде. – Үкенечле язмыш... – Әйтерсең, Мансур этисе тәрбиясендә үскәненнән уңайсызлана иде. — Мондый язмышны дошманыңа да теләрлек түгел.

– Син картинада сурәтләгән кыз хакында миңа сөйләп калдырган иде ул, – диде Рафаэль. – Әти ул кызны гомере буе эзләде, гомере буе юксынды... Ул аңа гомере буе тугрылыклы булып калды...

– Тугрылык... – дип, авыз эченнән генә пышылдады Мансур. – Мин ул әсәремне башкача атарга уйлап йөри идем. Синең рөхсәт белән, Рафаэль, «Тугрылык» дип куШыйммы исемен?

– Анысы синең эш инде...

– Миңа гына түгел, ул кызны яратуын әнигә дә сөйли торган иде. Әни ул кызны кызганып елый иде...

– Без тагын күрешик әле, – дип тәкъдим итте Мансур. – Мин ул картинамны төгәлләнмәгән килеш калдырган идем... Менә бу фаҗига килеп чыкты да... Кайбер детальләр өстисем килә... Бәлки, син миңа булышыр идең?

– Белмим шул, – дип икеләнде Рафаэль. – Үзең беләсең, мин сезнең дөньядан ерактарак торам... Әнә минем арба... – Ул таксига төртеп күрсәтте. – Бар булган һөнәрем шул...

– Хикмәт синең һөнәрдә түгел, – дип, аны тынычландырырга тырышты Мансур. – Хикмәт — язмышта... ■

Мәшһүрләребез: *Бакый Урманче һәм Нури Арслан*

БАКЫЙ УРМАНЧЕ (1897-1990)

Бик зур кайгыбыз бар. 6 августта 94 нче яшендә Бакый абзый вафат булды. Аның үпкәсе шешкән иде, шул авыру дәвамында үпкәсендә су хасил булган. Шул аның әҗәленә сәбәп булды.

Мин аның янында күптән түгел булып, бик һәйбәт сөйләшеп утырган идек. Менә хәзер ул юк инде.

Аксакаллардан иң өлкәне, иң дәрәҗәлесе китте. Бакый абзый революциягә кадәрге зыялылар, аларның гореф-гадәтләре, традицияләре белән хәзерге заманны тоташтыручы бер күпер иде. Хәзер татар мәдәниятендә андый кеше калмады инде, элекке зыялылар белән хәзергеләре арасында җанлы элемтә өзелде.

Иннә иләйһи раҗигун.

1990, 8 август

Бакый Урманче. Алматы шәһәре. 1942 ел

НУРИ АРСЛАН (1912-1991)

Бүген шулай ук зур кайгылы көн дә. Зур талант иясе булган шагыйребез Нури Арслан бүген гүр иясе булды.

Ни сәбәпле Нуриның вафатын мин аеруча авыр кичерәм? Без аның белән шифаханәдә өч атна чамасы вакыт эчендә бер этажда, күрше палаталарда дәваланган идек. Электән үк бер тирәдә яшәү һәм җыелышлардан бер транспортта кайту сәбәпле, соңгы дүрт-биш ел эчендә без Нури белән яхшы ук якынлашкан, бәйрәмнәрдә берберебезне тәбрик итмичә калмый идек.

Шифаханәдә дәвалана башлап, бераз аякка баса башлагач ук, мин аның хәлен белешергә кердем. Ул миңа бик авыру кебек күренде. Шулай да мин аяк очына барып баскач, елмаерга тырышты, холкы белән егет кеше буларак, авыруга бирешмәскә тырышуын сиздерде.

Нури Арсланов. 1930-1940 нчы еллар

– Ә, Гомәр ага, кергәнсез дип ишеткән идем, үзем бармакчы булган идем әле, тик менә бу каһәр җибәрми бит әле... – диде.

Берничә көннән аны хирургия бүлегенә күчерделәр. Аның янына улы да килгән иде, мин аңа әтисенең хәлен белергә килүе өчен рәхмәт әйтеп, операция көннәрендә атасы янында булырга киңәш бирдем.

Ләкин Нурига, ни сәбәпледер, операция ясамаска булганнар. Ихтимал, карт йөрәк операцияне күтәрә алмас дигән фикергә килгәннәрдер. Аны интенсив терапия палатасына салдылар.

– Шеше кайтты инде, ләкин бәвелдән әле һаман да кан килә, тәүлегенә җиде-сигез тапкыр йомышка чыгарга туры килә, – дип зарланды ул.

Ул караватында утырып тора иде. Хәзерге яшьләрнең иҗаты, аларның иске әдәби телне белмәүләре сәбәпле гарәп, фарсы сүзләрен ялгыш кулланулары хакында мисаллар китереп, зарланып та утырды.

Нури белән безнең сер килешә, бер-беребезне яхшы аңлый идек. Чөнки ул да, мин дә, элекке мәдрәсәдә укып калган кешеләр буларак, элекке әдәбиятны гарәп язуында укып белә идек.

Шуның өстенә, аның шигырь стиле дә миңа бик ошый, ул үз иҗаты аша безнең шигърияттнең элекке үзенчәлекләрен хәзерге әдәбиятка бик теләп күчерә бара, әдәбиятыбызны талантлы яңа шигырьләр белән баета иде.

Мин шифаханәдән чыкканда, ул мине коридорга озата чыкты.

– Дүрт-биш көннән мин дә чыгармын инде, бик туйдырды, – дип зарланып калды.

Ә менә 14 апрельдә («Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек»тә «12 апрельдә» диелгән. – *Ред.*) китеп тә барган. Каты туфрагың йомшак булсын, Нури дус. Мин сине озатырга бара алмадым, чөнки минем үз хәлем дә шәпләрдән түгел, ун-унбиш адым барган саен, тын буылудан туктарга туры килә. Синең артыңнан китәргә миңа да күп калмады инде.

1991, 16 апрель

Истәлекләр Гомәр Бәширов көндәлегеннән алынды.

Әдәбият:

1. Бәширов Г.Б. Күңел дәфтәре: көндәлек язмалар [төзүчесе, кулъязмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчесе Зөфәр Бәширов]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011. – 464 б. ■

1920 нче еллар азагында күренекле язучы Гадел Кутуй татар сәнгатенә багышланган бер мәкаләсендә: «Яңа татар әдәбиятының иң бөек шагыйре Габдулла Тукай булса, татар профессиональ музыкасының бөек композиторы Салих Сәйдәшев», – дип язган. Тора-бара әдәбиятыбыз һәм сәнгатебездәге бу эзлеклелеккә халкыбыз сәнгатенең төрле өлкәләрендә иҗат итүче бөек шәхесләребез кушыла бара. Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким узган гасырның 70 нче елларында дөнья күргән «Тукай башыннан сыйпар иде» дигән мәкаләсендә Мәскәүдә караган бер концерттан алган тәэсирләре белән уртаклаша һәм: «Эчемнән халкыма рәхмәт әйтеп утырдым. Шулай, башка халыклар каршында безнең дәрәҗә бетмәсен, дипме, ул йә Тукаен, йә Сәйдәшен биреп куйган... Илһам Шакиров – чын талант, халык улы. Тукай исән булса, башыннан сыйпар иде аның», – дип яза.

ХАЛКЫБЫЗ **ИЛҺАМЫ**

Гәрәй Рәхим

1973 елны Илһам Шакиров, бер төркем татар зыялылары белән Финляндиягә барып, шунда яшәүче татарлар белән очрашулар үткәрде. Аннан ул «Туган ил» дигән халык җырын алып кайтты.

Шул чорда күренекле язучы, фольклорчы һәм тел галиме **Нәкый Исәнбәт** Илһам Шакиров иҗатына багышланган мәкаләсен бастырып чыгарды. Ул да анда: *«Татар музыкасында Сәйдәш ничек үзенә хас урын тотса, җырчылыкта Илһам да шундый урын тота»*, – дип, Гадел Кутуй һәм Сибгат Хәким башлаган чылбырны, ягъни шигърияттә – Тукай, музыкада – Сәйдәш, җыр сәнгатендә – Илһам чылбырын ныгытып куйды.

Озак та үтмәде, бу чылбырга тагын бер «боҗра» өстәлде. Бөек иҗаты турында озак еллар ләм-мим сүз әйтмәгән сәнгать белгечләре, журналистлар, әдәбият-сәнгать әһелләре, дәррәү кубып, бөек рәссамыбыз Бакый Урманче иҗатына зур игътибар бирә башлады. Ул елларда, ягъни Бакый ага шактый гомерен уздырган тоткынлыктан азат ителеп, бөек рәссамыбыз реабилитацияләнгәннән соң, безнең алда аның иксез-чиксез сынлы сәнгать дөньясы ачылып китте. Урманче иҗаты турында сүз алып баручылар аны, беравыздан, татар сынлы сәнгатендә иң бөек шәхес дип раслады.

Шулай итеп, теге «бөекләр чылбыры» тәмам тулыланды: шигърияттә – Тукай, музыкада – Сәйдәш, сынлы сәнгатьтә – Бакый, җырда – Илһам. Татар әдәбияты һәм сәнгатенең Тукайдан безнең көннәргә кадәр тезелеп килгән бу «чылбыр»ын без, яшь иҗатчылар, дәррәү күтәреп алдык. Хәзер инде Татарстанның халык язучысы булган Рабит Батулла әле ябь-яшь чагында ук шушы чылбыр турында сәхнәләрдән сөйләде, мәкаләләрендә язып чыкты. Илһам Шакировка багышланган «Юлаучы» дигән шигыремдә бу «чылбыр» турында мин дә болай дигән идем:

Алар безнең, яңа бу заманның
Иң алдынгы сәнгать батыры:
Шигърияттә – Тукай,
Музыкада – Сәйдәш,
Сәхнәләрдә – Илһам Шакиров.

Еллар үтә, гомер алга чаба...

Бүген инде татар халкы үзенең бөек җырчысын еш кына «халкыбыз Илһамы» дип йөртә. Әйе, исеме җисеменә туры килә шул, аны лаеклы рәвештә «халкыбыз Илһамы» дип атап була. Татарлар гына түгел, ә тугандаш төрек, башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән, азәрбайҗан һәм башка бик күп төрки халыклар, шулай ук музыкаларының нигезе пентатоникага корылган Кытай, Корея, Япон һәм Азиядәге башка төрки булмаган халыклар да аны «халкыбыз Илһамы» дип әйтә алырлар иде. Якын күршеләребез – славян, фин-угыр, ерак күршеләребез булган Европа, Америка, Азия, Африка, Австралия кыйтгаларында да Илһам Шакиров җырын яратып тыңлаучылар күп. Әйтик, узган гасырның илленче елларында Илһам Шакировның Чехословакия башкаласы Прагада үткәрелгән халыкара музыка бәйрәмендә татар халкының бөек җыры «Кара урман»ны акапеллада җырлавын тыңлаучылар бу җырны һәм аның башкарылуын бөтендөнья күләмендәге музыкаль казаныш дип бәяләделәр.

Атаклы дирижер, озак еллар Татарстан Дәүләт симфоник оркестрын җитәкләгән Натан Рахлин да Илһам Шакировка, хөрмәт йөзеннән, автографлы фотосын бүләк итә. Анда: *«Любимому Ильгаму – от Натана»*, – дип язылган. Бу талантлы музыкантның талантлы җырчыга мөнәсәбәтен ачык күрсәтә.

1968 елда Татарстан артистлары һәм композиторлары Финляндиянең татар җәмгыяте чакыруы буенча Хельсинкига баралар, анда берничә концерт куялар. Моңа кадәр Илһам Шакировның җырлавын радио һәм патефон тәлинкәләре аша гына ишетеп белгән фин татарлары җырчының үзен күреп чиксез шатланалар, хәтта анда Илһамның мәхәббәт романы да булып ала.

Казакъстанның атаклы композиторы, Казакъстан Республикасы Дәүләт гимнының авторы, татар егете **Латыйф Хәмиди** 1970 елның 29 мартында Илһам Шакировка бүләк иткән фотосының артына, татарчалап, болай дип яза: *«Зур талант иясе, бик матур тавышлы һәм минем иң яратып тыңлый торган сөекле җырчым – Татарстанның халык артисты Илһам Шакировка, зур ихтирам һәм изге теләкләр белән, Латыйф Хәмиди»*.

Илһам Шакиров иҗатына уңай мөнәсәбәт белдерүчеләр арасында күренекле дәүләт эшлеклеләре, музыкантлар, җырчылар, галимнәр, язучылар, гади музыка сөючеләр күп. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, күренекле язучыларыбыздан – Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Салих Баттал, Сибгат Хәким, Башкортостанның күренекле язучылары Мостай Кәрим һәм Наҗар Нәҗми, татар нәселеннән булган рус язучысы Михаил Львов, күренекле татар режиссеры Марсель Сәлимҗанов, галимнәр Мансур Хәсәнов һәм Миркасыйм Госманов, драматург Туфан Миңнуллин, атаклы җырчыларыбыз Әлфия Афзалова, Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов һәм дистәләгән шагыйрьләребез Илһам Шакиров иҗаты турында матбугатта язып чыкты.

Сүз дә юк, Илһам Шакировның татар музыка тормышындагы феномены – безнең профессиональ сәнгатебезнең югары бәягә лаек икәнен раслаучы бер күренеш ул.

Үзенең бөтен иҗаты, табигать биргән гаять үзенчәлекле, моңлы, бик тә милли, үтемле, җанга якын тавышы белән бергә, Илһам Шакиров халкыбызның бөек һәм катлаулы тарихы, бу өлкәдәге фәнни эзләнүләр, сәнгатебезнең һәр тармагы – әдәбияты,

Финляндия Президенты Урхо Калева Кекконен Татарстан артистларын кабул итү вакытында. Сулдан уңга: күренекле татар артистлары Венера Шәрипова һәм Айрат Арсланов, Финляндиядәге татар галиме Гомәр Таһир, Илһам Шакиров, атаклы татар композиторы Рөстәм Яхин, музыкант Марс Макаров, Урхо Калева Кекконен, скрипкачы Марат Әхмәтов.

Хельсинки, 18 август, 1968 ел

театры, сынлы сәнгате, архитектурасы, классик музыкасы белән һәрдаим кызыксынган, ул гына да түгел, шушы өлкәләрне һәм гамәли, һәм фәнни яктан яхшы белгән олуг шәхес иде. Ә бит җыр сәнгатендә сәхнә әһеле булу ягыннан бик талантлы, ләкин халкыбыз тарихы белән аз кызыксынучы артистларыбыз да юк түгел. Алардан аермалы буларак, Илһам Шакиров халкыбыз тормышының, рухының борынгыдан килгән чын милли үзенчәлекләрен тирәнтен белгән, алар турында теләсә нинди әңгәмәгә, бәхәскә фәнни төгәллек белән катнаша ала торган сәнгать эшлеклебез иде. Аның бу үзенчәлеген инде узган гасырның җитмешенче елларында, ягъни моннан ярты гасырлар элек үк тотып алган, ул чактагы яшь археолог, тарихчы, соңыннан Татарстанның күренекле тарих галиме Равил Фәхретдинов 1973 елда «Җырчы» дигән китап бастырып чыгарды. Бу Илһам Шакировның иҗаты һәм тәрҗемәи хәле турында беренче китап иде. Шул ук вакытта ул – күренекле галимебез Равил Фәхретдиновның да дөнья күргән беренче китабы. Бу китапта әйтелгән фикерләр бүген дә актуальлекләрен югалтмаганнар. Әлбәттә, яшь галимнең яшьләрчә дәртле китабы 30 яшьлек җырчы исеменең дөньяга тагын да киңрәк таралуына шактый зур этәргеч бирде.

Илһам Шакиров... Без, җыр һәм музыка сөючеләр, бөек җырчы Илһам Шакиров исемен, аның җыр-моңнарын никадәр генә яхшы белсәк тә, аңа чиксез соклансак та, күбебез әле аның нәсел-нәсәбе, тарихи әби-бабалары турында аз белә идек. Моңа, беренчедән, Совет чорында аерым шәхесләрнең революциягә кадәрге булган нәселнәсәпләре, туган-тумачалары, аларның тормышлары белән кызыксынуга игътибарсызлык, ул гына да түгел, аны өнәмәү тәэсир итсә, икенчедән, үзебезнең шәхси тарихыбызны оныта баруыбыз да сәбәпче булды. Ә бит безнең тирән тарихка нигезләнгән



Азәрбайҗан Республикасының Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе, Азәрбайҗанның халык артисты Полад Бюль-Бюль оглы Мәскәүдән Казандагы иҗатташ дустына котлау һәм, култамгасын куеп, үзенең фотосын бүләк итеп җибәрә. Аерым алганда, ул, бөек татар җырчысы турында болай ди: *«Илһам дигән илһамлы исем белән, ул, үзе дә белеп бетермәстән, яшьли дәртләнеп, моңланып, саф күңелдән җырлаган да җырлаган. «Илһам» дигән изге сүз бит, татар телендә генә түгел, ә күпчелек төрки халыкларда да бөек илһамлыкны аңлата торган илаһи сүз!*

Җырчы бөек Илаһыбыз бик сирәкләргә генә бүләк итә торган җылы, аңлаешлы һәм күңел төрләренең иң тирән төпкелләренә барып ирешә торган табигый тавышка ия. Илһам шушы бүләк-тавышны үз иҗатының төп коралы итте».

Мәскәү, 2 декабрь, 2010 ел

иҗтимагый гореф-гадәтебез, тарихи традициябез – һәр кешенең җиде буын бабасына кадәр нәсел-нәсәбен белергә тиеш булуы. Большевиклар хакимияткә килгәнче, татар халкы арасында шәҗәрәләр төзү – нәсел агачын булдыру һәр кешенең изге бурычы саналган. Аллага шөкер, соңгы елларда күп кенә зыялы гаиләләрдә шәҗәрәчелек, ерак нәсел-нәсәпләр тормышын өйрәнү хәрәкәте яңадан яңарып килә. Әйтик, Татарстан хакимиятендә эшләүчеләрнең шактые инде үз шәҗәрәләрен, нәсел агачларын булдырды.

2005 елда, Илһам Шакировка 70 яшь тулган елны Татарстан Республикасының «Җыен» Татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды тарафыннан җырчыга багышлап чыгарылган китапта Илһам Шакировның шәҗәрәсен һәм нәсел агачын төзеп нәшер итү максат итеп куелган иде. Бу эш күренекле шәхесләребезнең борынгы нәсел-нәсәпләрен архивлардан эзләп табып тәртипкә салучы галим һәм каләмдәшебез Дамир Гарифуллинга йөкләнде.

Хәзер инде без бөек җырчыбызның нәсел-нәсәбе турында билгеле бер күләмдә мәгълүматка ия. Дамир Гарифуллин Илһам Шакировның атасы ягыннан сигез буын бабаларын ачыклады: Илһамның әтисе Гыйльметдиннең әтисе Габделнасыйр, аның әтисе Габделхалыйк... Д.Гарифуллин тарафыннан Теләнче Тамак авылында табылган ике китап эченнән чыккан кәгазьләрдә Илһам Шакировның бу бабаларының балалары, оныклары һәм онықларының балалары турындагы мәгълүмат бар. Алар барлыгы 80 кешегә җыела. Әмма әлегә Илһам Шакировның дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче буын бабаларының (Габделгазиз бине Габдулла бине Ишкилде бине Үтәгән бине Алпар) бала-чагалары турында мәгълүмат билгеле түгел.

Шулай итеп, Илһам Шакировның бүгенгә билгеле булган иң ерак сигезенче бабасы Алпар була. Татар тарихында, аның топографиясендә һәм кеше исемнәре арасында

Дөньяның мәшһүр музыканты Мстислав Ростропович, алдан искәртмичә генә, Мәскәүдә Илһам Шакиров концертына килә. «Кара урман»ны тыңлагач, Илһамга: «Ты убил меня этой песней», – дип, соклануын белдерә дә җырчыны өенә кунакка чакыра. Җырчыны иң гаҗәпләндергәне шул була: Ростроповичлар аны үзе яраткан татар ризыклары – пәрәмәч, чәк-чәк, өрекле чәй белән сыйлый.

Мәскәү, Тимерьюлчылар мәдәният сарае. 1974 ел

киң билгеле булган бу исемнең килеп чыгышы турында тарихи белешмә табылса, бик кызык булыр иде.

Инде Илһам Шакировның һәм әти-әнисенең тормышына, тәрҗемәи хәленә күз салсак, монда да бик гыйбрәтле хәлләр күрербез.

Илһам үзе Сарман районының Яңа Бүләк авылында туып-үскән (хәзер бу авыл Тукай районына керә). Аның әтисе Совет чорында гына төзелгән әлеге авылга гаиләсе

белән күрше Таулык авылыннан (Илһам Шакировның бабасы һәм бабасының ата-бабалары шушы авыл зиратына күмелгән) күченеп килә һәм шунда төпләнеп кала. Аңлашыла ки, бу вакытта әле Илһам тумаган була.

Оста тимерче буларак, Гыйльметдин абзый Яңа Бүләк һәм күрше авыллардан килеп тимер чүкетүче авыл кешеләре белән якыннан аралаша, алар белән тормыш хәлләре турында гәп кора. Авыл кешеләре арасында да төрлеләре бар бит: утызынчы елларда, шәхес культы котырган чакларда, кемдер, тимерче Гыйльметдиннең теле озын, дип, НКВДга шикаять яза. 1937 елның 8 октябрендә аны кулга алалар. Бу вакытта әле Илһамга ике яшь ярым чамасы гына була һәм ул, әлбәттә, этисен хәтерләп бетерми.

Гыйльметдин агай 1940 елның 4 мартында 5 нче хезмәт белән төзәтү колониясендә ачлыктан һәм авырудан җәфаланып җан бирә.

Гаиләдәге алты баланы тәрбияләп үстерү Илһамның әнисе Нуриәсма апа өстенә төшә. Ул чактагы газапларны Илһам еш искә ала иде. Булачак җырчы абыйсы белән бергә үргән чабаталарны сатып та аз-маз тамак туйдыра.

Шушы авырлыкларны кичерә-кичерә, Бөек Ватан сугышы да үтеп китә. Тумыштан баш-аягы белән җырга гашыйк Илһам Шакиров күрше Теләнче Тамак мәктәбендә урта белем ала. Укыганда ул, туганнарын, туган йортын сагынып, көн саен булмаса да, атнага берничә мәртәбә Яңа Бүләккә кайтып йөри. Юлда һәрвакыт япа-ялгызы бар тавышына җырлый. Яңа Бүләк һәм Теләнче Тамак урманнары, чәчәкле болыннары, иген кырлары әле бүген дә яшүсмер Илһамның моңлы тавышын саклыйлардыр, сагыналардыр!

Теләнче Тамакта урта белем алган һәм педагогия училищесына кереп тә анда җан азыгы тапмаган, бөтен күңеле белән җыр дөньясына кереп чумган Илһам Шакиров 1954 елны Казанга – музыка училищесына юл ала. Әмма ул бу турыда беркемгә дә әйтми. Илһам моңа кадәр инде Теләнче Тамак мәктәбе үзешчән түгәрәгендә катнашып, тирә-як авыл сәхнәләрендә, туйларда беренче чирканчык ала, җыры белән авыл кешеләрен шаккатыра.

Училищеның беренче курсында ук, Илһам Шакировны Татарстан радиосына чакырып җырлата башлыйлар. Озак та үтми, радиокомитетка радиотыңлаучыларның йөзәрләгән хатлары ява башлый. Аларның барысы да радиодан тагын-тагын-тагын Илһам Шакировны җырлатуларын сорыйлар.

Әмма җыр сөючеләрнең мәхәббәте яшь егетнең күңелен күтәрсә дә, ул чорда көндәлек тормыш алып бару, кием-салым бөтәйтү, тамак туйдыру бик җиңел булмый. Музыка училищесында укыган еллар турында Илһамның шәриге, соңыннан күренекле татар композиторы булган **Фасил Әхмәтов** «Без өчәү идек» дигән мәкаләсендә болай дип яза: *«Аның торыр җире дә юк иде, без аны шул училищеның подвалында яшәүче ятимә апаның бер бүлмәле фатирына урнаштырдык.*

Ел буена аның аягыннан кирза итек төшмәде. Менә шундый иде яшь Илһам Шакиров. Мирсәет Яруллин, мин, ул – өчәү бергә Кекин йорты ашханәсенә йөрибез, беребезнең акчасы бетсә, икенчебездә кырып-себереп табыла...

Шәп, көчле, табигый тавышлы Илһам белемен арттыру өчен көне-төне эшләде, кулында һәрчак китап, үзе бик еш пианино янында иде».

Илһам Шакиров, җырчы буларак, халык арасында нәкъ менә радио аша таныла. Әмма ул чын профессиональ җырчы булу өчен күпләгән радиотыңлаучыларның йөзләгән, меңләгән мактау хатлары гына җитмәячәген яхшы аңлый һәм, музыка училищесының беренче курсын тәмамлауга ук, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә. Инде училищеда укыганда ук халыкка танылган җырчы буларак, аны консерваториягә ике куллап кабул итәләр.

Консерваториядә Илһам чит ил, рус һәм татар композиторларының классик

әсәрләре белән таныша, рояльдә башка студентлардан яхшырак, профессиональ дәрәҗәдә уйный, музыка теориясен һәм тарихын тирәнтен өйрәнә. Консерваториядә ул тәҗрибәле музыка укытучысы Елена Абросимовадан дәресләр ала, аның иң яраткан укучысы була. Биредә укыганда аны танылган татар композиторы Мансур Мозаффаров аеруча якын итә. Ул Илһам Шакиров өчен махсус җырлар яза.

Инде иҗади яктан шактый өлгергән һәм халык арасында танылуга ирешкән җырчы консерваториядә укыган һәм аны тәмамлап Г.Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясендә эшләгән чакларында ел буенча диярлек гастрольләрдән кайтып керми. Бу чорда ул Татарстан һәм Башкортостанның бөтен татар авылларында диярлек концертлар куя, СССРның төп шәһәрләрендә һәм татарлар тупланып яши торган төбәкләрендә чыгышлар ясый, чит илләргә турнега чыга. Дөнья картасының ул гастрольләрдә булган урыннарын карасаң, гаҗәпкә калырлык: Хельсинки, Истанбул, Киев, Баку, Ашхабад, Ташкент, Фрунзе, Алма-Ата, Мәскәү, Ленинград, Саратов, Әстерхан, Уфа, Куйбышев, Омск, Новосибирск, Томск, Красноярск, Иркутск, Владивосток һәм башка йөзләгән кечерәк шәһәрләр, меңләгән авыллар...

Шушы бетмәс-төкәнмәс гастрольләрдә, радио һәм телевидениедә башкарган, патефон тәлинкәләренә язылган йөзләрчә исемдәге җырлары белән Илһам Шакиров бөтенхалык мәхәббәтен казана.

Илһам Шакиров һәр җырында, туган халкының бәгыреннән ташып чыккан илаһи моң, үзенә генә хас булган кабатланмас тавыш, көчле рух белән тамашачы күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтә, шуның белән чын халык җырчысы биеклегенә күтәрелә. Бер генә дәүләт бүләге алмаган булса да, ул барыбер «халык җырчысы» дигән бөек исемне йөртер иде. Ләкин Татарстан хакимияте Илһам Шакиров иҗатын һәрвакыт югары бәяләп килде. Республикабыз хөкүмәте тәкъдиме белән, ул «Россиянең халык артисты» дигән мактаулы исемне алды, аңа Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. 2000 елның 28 апрелендә Россиянең Мәдәният министрлыгы һәм музыка сәнгатен үстерү буенча Чайковский исемендәге фонд Илһам Шакировка Россиядәге иң дәрәҗәле бүләкләрнең берсе булган «Алтын Апполон» премиясен тапшырды. Ә бит бу премиягә Россиянең мәшһүр җырчылары һәм музыкантларыннан Ирина Архипова, Андрей Эшпай, Татьяна Устинова, Михаил Шишкин кебек атаклы сәнгать әһелләре генә лаек булган иде.

«Алтын Апполон» премиясен алганда инде Илһам Шакировка 65 яшь иде. Профессиональ җырчы өчен бу шактый зур яшь. Гадәттә җырчылар иҗаты 40-45 яшьтә табигый рәвештә сүрелә башлый, күп җырчылар инде ул яшьтә сәхнәгә бик сирәк чыгалар, чыксалар да, җырларын фонограмма ярдәмендә генә тыңлаучыга тәкъдим итәләр. Ә табигать Илһам Шакировка тавышны шулкадәр мул итеп биргән ки, ул 80 яше узганчыга кадәр сәхнәдә фонограмма (артистлар аны «фанера» дип йөртәләр) кулланмады. Сиксәннән узган артистның сәхнәдә һаман табигать биргән үз тавышы белән җырлавы күпләрне гаҗәпкә калдыра, чиксез сокландыра иде.

Дөрес, бу вакытта инде җырчыбыз сәхнәгә бик еш чыкмады, чыкса да, бер-ике җыр башкару белән чикләнә иде. Тамашачы зәвыгының нәзбереклеген, нечкәлеген тирән тойган җырчы үз бәһасен, димәк, профессиональ артист бәһасен төшермәү өчен шулай эшләде. Илһам Шакиров җырын тыңларга теләүчеләр өчен әллә күпме аудио һәм видеоязмалар, ягъни дисклар чыгарылды.

Сәхнәгә еш чыкмаса да, Илһам Шакиров, картайдым, дип, мич башына менеп ятмады, татар әдәбият-сәнгать әһелләре – музыкантлар, композиторлар, театр артистлары, язучылар, галимнәр белән якыннан аралашып яшәде. Җәйнең матур бер көнендә ул Казан янындагы атаклы Аккош күле ярында «Илһам сәйраны» дигән күңел ачу җыены

оештырды. Анда, ким дигәндә, 30-40 күренекле сәнгать әһелен, дусларын чакыра, үз куллары белән бик оста һәм тәмле итеп шашлык, пылау пешерә иде. Илһам бу осталыкка да ярты гасыр буе гастрольләрдә йөреп өйрәнгән.

«Илһам сәйраны»нда күренекле сәнгать әһелләре тәмле ризык белән сыйланалар һәм бүгенге сәнгатьнең торышы, аның уңышлы һәм кимчелекле яклары, сәнгатебезнең һаман үсә баруы өченниләр эшләргә кирәклеге турында сөйләшәләр иде. Әлбәттә, әдәбият-сәнгать кешеләренең һәрберсе сәйранда әйтелгән фикерләрне үзләренең киләчәк иҗатларында файдалана.

Бөек Болгар җирендә борынгы ата-бабаларыбыз, бүгенге милләттәшләребез һәм кунаклар, бала-чагалар һәм киләчәк буыннар хөрмәтенә архитектура һәм сәнгать ягыннан гүзәл итеп төзелгән Ак мәчет ачылгач, республикабызның «Яңарыш» фонды рәисе, Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев чакыруы буенча, Илһам Шакиров, бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләре белән, бирегә сәяхәт кылган иде. Республикабызның күренекле сәнгать әһелләре илаһи Ак мәчеткә һәм изге Болгар җиренә башларын иделәр. Әлеге сәяхәт, әлеге очрашу күпләрнең күңеленә тирән уелып калды. Илһам Шакиров изге җирдә озаклап дога кылды. Бу аның халкыбызның изге туфрагына, изге мәчеткә соңгы сәяхәте булды.

Узган елның 18 гыйнварында бөтендөнья татар җәмәгатьчелеге, бөек җырчысы Илһам Шакиров белән бәхилләшеп, аны мәңгелек дөньяга озатты. Халкыбызның сөекле улының җәсәде Казан каласының иң затлы милли бинасына – Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрына куелган иде. Монда, казанлылар белән бергә, республикабызның байтак районнарыннан, күрше милли республикалардан, Россия төбәкләреннән, Татарстанга йомыш белән яки турист булып килгән чит ил татарларыннан вәкилләр җыелган иде. Бәхилләшү мәрәсимендә катнашкан Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов җырчының туганнары һәм якыннарының, бөтен татар халкының авыр кайгысын уртаклашты һәм Казандагы иң зур халыкара төзелеш булган «Казан ЭКСПО» билгеләмәсендәге берничә мең тамашачы сыешлы концерт залына Илһам Шакиров исеме бирелү турындагы карарга кул куячагы турында хәбәр итте.

Бәхилләшү мәрәсименә җыелган халык бөек җырчыны үзе көй язган «Мәңгелеккә китеп барам» дигән җыр язмасы белән Казанның Яңа татар бистәсе зиратына озатты (җыр сүзләренең авторы – тугандаш башкорт халкының күренекле шагыйре Габделхак Игебаев).

Быел халкыбыз үзенең дәүләтчелеге 368 ел өзелеп торганнан соң (1552 елдан 1920 елга кадәр) Россия Федерациясе эчендә яңадан торгызылуының, ягъни 1920 елда ТАССР оештырылуның 100 еллыгын зурлап билгеләп үтәргә җыена. Бу бәйрәмнең республика күләмендәге рәсми ачылышы 2019 елның 20 декабрендә булды. Шунсы куанычлы, әлеге олы бәйрәмгә нәкъ менә Президентыбызның бөек җырчыбыз исемен бирергә дигән вәгъдәсе гамәлгә ашырылган «Казан ЭКСПО»дагы Илһам Шакиров исемендәге гаять зур тамаша залында старт бирелде. Әлбәттә, бу олуг бәйрәмебезнең ачылышы ук бөек җырчыбыз исеме белән дә тәңгәл килүе – үзе үк бер тарихи чынбарлык, тарихи гамәл! Димәк, бөек Илһамыбызның исеме мәңге онытылмаячак, татар халкы да аның сүнмәс иҗаты белән ерак киләчәккә атлый.

Шулай була күрсен. Амин!

Фотолар Илһам Шакировның шәхси архивыннан алынды. ■

Безнең мирас №2 февраль 2020

Беренче укытучыларым

Индус Таһиров

Мин укытучыларымнан уңдым һәм аларга һәрвакыт рәхмәтле булып яшим. Дөньяда иркен сулыш алып, анда үз урынымны табып гомер кичерә алуым белән мин аларга бурычлы.

Ләкин бу язмамда сүз күбрәк беренче укытучыбыз – әниебез Әминә Каюм кызы Каюмова турында барачак.

Ул – изге ил аналарының безнең өчен иң якыны. Телебезне дә әниебез ачты, туган халкыбызга карата мәхәббәт хисләрен дә әниебез уятты. Мәктәпкәчә үк укырга-язарга да ул өйрәтте, яшәү тәртипләрен дә аның аша белдек. Яхшылыкның яманлыктан өстен булырга тиешлеген дә безгә әниебез сеңдерде.

Аның тормыш юлы җиңелләрдән булмаса да, язмышы бәхетле. Чөнки башына төшкән авырлыкларны, кайгы-хәсрәтләрне, берсеннән-берсе зуррак югалтуларны батырларча җиңә белгән зат иде ул. Ата-анасынннан васыятъ итеп алган «сабырлыкның төбе сары алтын» дигән сүзләр әниебезнең яшәү кагыйдәсе булды. Ул аны безгә дә васыять итеп калдырды.

Әниебез чын мәгънәсендә кешелекле зат иде. Гомере буе берәүдән дә көнләшмичә, кеше шатлыгына шатланып яшәде. Ул беркайчан да беркем турында да начар сүз әйтмәде, берәүгә дә рәнҗемәде, берәүне дә рәнҗетмәде, берәүне дә каргамады, берәүгә дә ачу сакламады, начарлык та теләмәде. Ул безнең өчен һәрвакыт эчкерсезлек үрнәге булды.

Әниебез Әминә Каюм кызы Каюмова Урсал тау астында – Зәй буенда, тирә ягын урман һәм болыннар уратып алган Әлмәт авылында туып үскән. Атасы – бабабыз Каюм, хатыны үлгәч, 65 яшендә икенче мәртәбә күрше Түбән Мактама авылы кешесе Хәмидулла кызы Бибигайшәгә өйләнә. Алар бергә биш бала үстерә. Әниебез дөньяга килгәндә, атасына инде 83 яшь була. Ике елдан соң, әниебезнең сеңлесе Галимә апабыз дөньяга килгән. Бабай, балаларын аякка бастырып, аталык вазыйфаларын тулысы белән үтәгәннән соң, йөз яшен тутырып, дөнья куя.

Әниебез, Бөгелмәдә педагогия юнәлешендәге махсус уку йортын тәмамлап, яңа оештырылган Шөгер районына эшкә билгеләнә. Ул шушы җирлектә ныгый, педагог булып өлгерә. Шөгерне чын күңеленнән яратып кабул итә.

Яратмаслык та түгел шул Шөгеребез. Аның искиткеч табигате, һичкайда булмаган гүзәл таулары, урман һәм болыннары күпләрне таң калдыра. Шөгерне хәтта Татарстан Швейцариясе дип тә атыйлар. Аңа дан җырласаң да, мактасаң да, сагынып искә алсаң да, дөрес аңлашыладыр дип уйлыйм. Чөнки ул – туган җир, безне тудырган һәм дөньяга чыгарган төбәк. Аның моңнары, сагышлары, тирән кичерешләр булып, һәммәбезнең күңеленә сеңгәндер. Туган илгә, халкыбызга, телебезгә мәхәббәт тә шунда яралган. Без аны үзебезгә татарлык нигезе салганы өчен яратабыз.

Бөгелмәдә әниебезгә ныклы белем биргәннәр. Һади Атласи, Фазыл Туйкин шикелле мәртәбәле шәхесләр эшләгән ул уку йортында. Әниебез үзенең укытучыларын сагынып сөйли торган иде. Алар турында язып та чыкканы булды.

Һади Атласины укучылары: «Милләтебез балаларына аң-белем бирүгә чын күңелдән

Әниебез Әминә Каюм кызы Каюмова

бөтен көчен куйган, күп кырлы галим», – дип бәяләгәннәр. Ул шушы данлыклы уку йортында тарих, география, немец телен укыткан. Әниебез аның мөкаммәл рәвештә инглиз, немец, гарәп һәм фарсы телләрен белүен азсызыклый торган иде. Аның язмаларында яраткан укытучысы турында мондый сүзләр бар: *«Мәһабәт гәүдәле, ачык чырайлы укытучыбыз Һади абый класска килеп керүгә, аягүрә басып каршы ала идек. Мин аның тарих, география дәресләрен бигрәк тә яратып укыдым. Ул вакытта дәреслекләр, китаплар булмаганлыктан, лекцияләрне тыңлап язып бара идек. Хәзер дә исемдә әле: Герцен урамындагы фатирыма кайткач, кара буяуга аз гына шикәр комы салып (янәсе, ялтырап торсын!), кара ясыйм да, дәфтәрем кырыеннан кыр калдырып, класста язып кайткан караламаны матур итеп күчереп яза идем».*

Һади Атласи үзенең укучыларына: *«Бабаларыбыз: белем алу – энә белән кое казу,» – дип тикмәгә генә әйтмәгән. Белемне җиләк җыйган кебек бераммтекләп җыйсаң гына алып була»*, – дип әйтә торган булган. (Һади Атласи. Тарихи-документаль җыентык. – Казан: «Җыен» нәшрияты, 2007, 370-371 б.)

Әниебез Шөгергә, Һади Атласиның педагогик мәктәбен үтеп, укытучылык хезмәтенә зур мәхәббәт сеңдереп килгән. Һәм гомере буе аңа турылыклы булып яшәде.

Алар әтиебез Риза Шәйхетдин улы белән шушы җирдә гаилә корып җибәрәләр, гөрләтеп яши башлыйлар. Әтиебез авылда колхоз оештыручы да, авыл Советы рәисе булып та эшли. Гомумән, ул бик актив кеше була. Җыелышларда ул сөйләгәнне таң калып тыңлаганнар.

1941 елны әти фронтка китә һәм 1944 елның ноябрендә Латвияне азат итү өчен барган каты сугышларда рота командиры буларак һәлак була.

Без – 3 бала: олыбыз Дамир – 8 яшендә, уртанчысы мин – 5 яшемдә һәм кечебез Энгель – 1 яшендә, әтидән калып, әниебез тәрбиясендә үстек.

Сугыш елларында ул Шөгер районының Түбән Чыршылы авылына мәктәп директоры һәм партоешма секретаре итеп билгеләнә. Агитколлектив оештырып, аны да җитәкли.

Чыршылының табигате дә матур: Шөгердәге кебек таулар. Ике Чыршылыны – Түбәнен һәм Югарысын Куак суы бүлеп тора. Бу авыллар бер бөтендәй яшиләр иде.

Авыр сугыш еллары әниебезнең кешелек сыйфатларын ныклап сынады. Ул һәрвакыт мескеннәргә, авыр хәлгә төшкән кешеләргә ярдәм кулын сузып торды, аларның зармоңнарын тыңлап, кайгы-хәсрәтләрен уртаклаша белде. Мәктәп өчен махсус җир алып, анда бәрәңге, чөгендер һәм тары үстереп, фронтовик балаларын ашату-эчертүне җайга салды. Безгә – үзенең балаларына анда йөрү катгый рәвештә тыелган иде. Шулай да кайвакыт, ул күрмәгәндә, аш пешереп торучы мәктәп җыештыручысы Минзифа апа, безне кызганып, көчләп диярлек алып кергәли иде. Рәхмәт яусын үзенә, бигрәк мәрхәмәтле, нечкә күңелле җан иде ул.

Әниебез, педагог һәм психолог буларак, укытучы халкына, бигрәк тә авыл мөгаллимнәренә төпле ярдәмче булды. Ялгышучыларны туры юлга күндерүче дә, егылганнарны аякка бастыручы да ул иде.

Әниебез кешеләрне, гомумән, халкыбызны ярата иде. Гомере буе халык иҗаты аның юлдашы булды. Күп язучыларның, шагыйрьләрнең әсәрләрен белү генә түгел, аларның шактыен яттан сөйли иде ул. Аның теле йөгерек, тормыш эпизодларын, табигать матурлыгын тасвирлавы мавыктыргыч иде.

Әниебез Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген читтән торып тәмамлый һәм мәктәптә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Укучылар аны әле дә булса сагынып сөйлиләр. Директор буларак та, сугыштан соң Шөгер РОНОсында инспектор буларак та, ул беркайчан да укыту эшчәнлеген туктатмады, киресенчә, аны бертуктаусыз камилләштерә торды.

Сугыш чоры укытучылары колхозчылар белән бергә кырда, балалар белән мәктәптә булдылар. Алар – авыл халкына дәрт һәм дәрман биреп торучылар. Үз көчләре белән концертлар оештыралар, хәтта спектакльләр дә куялар иде. Без – аларның балалары да сәхнәгә менеп җырлый һәм декламацияләр сөйли идек.

Эше никадәр тыгыз булуына да карамастан, әниебез һәрвакыт безнең өчен вакыт таба иде. Хәтеремдә, ул мәктәп китапханәсендәге китапларны алып кайта да без – балаларга кызыклы булган урыннарын кычкырып укый башлый. Әсәрнең иң кызык җиренә килеп җиткәч: «Ә инде моннан соң ниләр булганын үзегез укып белерсез», – дип, китапны үзебезгә тоттыра. Без исә, тырыша-тырыша, укуны дәвам итәбез. Китапка мәхәббәтне ул безгә Тукайның «Су анасы», «Шүрәле» кебек поэмалары, «Гали белән кәҗә» кебек шигырьләре һәм башка язучыларыбызның әсәрләре аша сеңдерә килде. Аларның шактыен кат-кат укып, яттан белә идек.

Мәктәпкәчә укый-язарга өйрәнүем әниебезнең дә әнә шул әдәбиятыбызга уяткан мәхәббәтеннән булса кирәк. (Өченче класста укучы Дамир абыебызның әтигә фронтка язган бер хатында, үзенең «отлично»га укуы турында хәбәр итеп: «Индус та язарга өйрәнә башлады инде, әле ул мәктәпкә укырга кермәде, бакчага гына йөри», – дигән сүзләр бар.)

Түбән Чыршылы мәктәбендә минем беренче укытучым Мөнәвәрә апа Чапаева булды. Гаиләбезнең якын дусты, әниебезнең сердәше Зифа апа Гыйләҗева да – абыебызның һәм минем беренче укытучыларыбыздан. Ул исән чагында без аның белән Чыршылы авылында очрашып тора идек. Кайвакыт, үткәннәрне искә төшереп, җырлашып та утыра идек. Аның үтә аһәңле, моңлы тавышы колакта һаман да яңгырап тора кебек.

Әниебез, болай да кыска булган йокыларын калдырып, безнең өчен стена газетасы чыгара, анда тормышыбызның кызыклы мизгелләре үзе ясаган рәсемнәр астында урын ала иде.

Зифа апа белән очрашканда, без шушы газетага бәйле бер кызыклы сәхифәне искә төшерә идек.

Безнең кәҗәбез бар иде. Кыш көне аның бәтиләре безнең белән өйдә. Алар сикерешәләр, әллә кайларга менәләр. Шулай бервакыт әни югында ап-ак кәҗә бәтиләре, мичкә кереп, корымга батып, кап-кара төскә кергәннәр. Кечебез Энгель, әни ачуланмасын дип, аларны юынгыч астында юа башлаган. Нәкъ шулвакыт әни кайтып керә дә: «Улым, син нишлисең?» – ди. Энгель исә аңа: «Бәтиләрнең мичкә кергәннәрен күрми калдым, син ачуланмасын дип, аларны юам», – дип җавап бирә. Стена газетасында шушы эпизод әнинең үзе ясаган рәсеме астында күрсәтелгән. Аны укытучыларның да, мәктәп балаларының да көлешә-көлешә укыганнары әле дә булса хәтеремдә.

Мәктәп китапханәсендә рус китаплары да күп иде. Тик менә без русча белмибез.

Укыйсы килә, ләкин теш үтми. Әни, шул китапларны уку өчен, безгә русча-татарча сүзлек бирә. Исемдә, кайбер сүзләрен табам, ләкин җөмләсен аңламыйм, чөнки грамматика дигән әйбернең нәрсә икәнен дә белмим. Булдыра алмагач, елыйм. Моны күреп, әни ярдәмгә килә, нәтиҗәдә, сүзләр тезмәсеннән җөмләләр барлыкка килә. Елавымнан туктыйм, шатланып, көлеп тә җибәрәм.

Русча өйрәнә башлауның беренче тәҗрибәсе әнә шундый булды. Ә инде аны ныклап үзләштерү тик Шөгергә кайткач, руслар белән аралаша башлагач кына булды. Моның өчен мин рус теле укытучыбыз Михаил Николаевич Дементьевка рәхмәтлемен. Ул бик белдекле һәм таләпчән кеше иде. Шушы безнең өчен ят булган телнең бөтен нечкәлекләрен, аның ия белән фигыльләрен генә түгел, хәтта нокта һәм өтер кебек тыныш билгеләренең кайчан һәм ничек куелырга тиешлекләрен ныклап сеңдерүче ул булды.

Ләкин Чыршылыдан кайткач, баштарак мин укуымны Шөгернең татар мәктәбендә дәвам иттем. 3 классны шунда тәмамладым. Монда аз гына укыган булсам да, укытучыбыз Асия апа Гыйльметдинова хәтеремә ныклап уелып калды. Татар теленнән диктант язганда мин «лейтенант» дигән сүзне «летейнант» дип язганмын. Асия апабыз аны кызыл кара белән төзәтеп, астына сызган. Шулай да бу бердәнбер хата булганлыктан, «5» ле билгесе куйган. Аның безгә бик җиңел ысул белән тапкырлау таблицасын өйрәтүе дә онытылмый. Соңрак үзем дә шул ысулга башкаларны да өйрәтә торган булдым.

Мин җиденче классны тәмамлагач, гаиләбез белән Әлмәткә – әниебезнең туган җиренә күчтек. Әтиебез һәм аның ир туганнарының берсе дә сугыштан әйләнеп кайтмагач, әниебезнең туганнары безнең шунда күчүебезне теләделәр. Унны шунда тәмамладым.

Әниебез анда да, Шөгердәге кебек үк, РОНО инспекторы булып эшләде. Ул чын мәгънәсендә укытучылар укытучысы иде. Нәкъ Шөгердәге шикелле, кышкы бураннарда да, көзге салкын яңгырларда да авыл мәктәпләрендә булыр, мәктәпләрнең, укытучыларның ихтыяҗларын ныклап өйрәнер һәм кулыннан килгәнчә ярдәм итәр иде. Ул беркайчан да укытучыларга авыр сүз әйтмәс, хата-кимчелекләрен, аларны һич кенә дә рәнҗетмәстән, аңарга гына хас булган осталык белән төзәтә белер. Үзен беркайчан да алардан өстен итеп күрсәтмәс.

Шушы педагогик кагыйдәләрне әниебез безгә дә сеңдерә килде. *«Укучыларга «ике»ле куярга ашыкмагыз, аларның хата-кимчелекләрен дорфа рәвештә төзәтмәгез. Күбрәк, аларга карата: «Мин синең урыныда булсам, менә болайрак эшләр идем», – кебек сүзләр кулланыгыз, аларны түбәнсетмәгез»*, – дип әйтә торган иде ул безгә.

Без, энем Энгель белән икебез дә, Казан университының тарих-филология факультетын тәмамлап, тарихчы-укытучы дипломына ия булдык. Без дә – әниебез шикелле, укытучылар. Мин – университетның тарих факультетында, энем – Культура институтында. Әшебезне әниебез васыятьләренә таянып алып барабыз.

1987 елны без әниебезне әтиебез җирләнгән Салдус шәһәрендәге туганнар зиратына алып бардык. Әни аның кабере янында намаз укыды. Гомер юлдашы белән кавышты да, хушлашты да. Кабер туфрагын Казанга алып кайтты һәм шуңа гөл утыртып үстерде.

Әниебез Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемгә, Почет билгесе орденына, башка бик күп бүләкләргә лаек булды. Әмма иң кыйммәтлесе шунда – аны укучылар да, укытучылар да, гади халык та бик ярата иде. Аның эшләгән елларын сагынып сөйләүчеләр бүген дә бар әле.

Исән булса, 2009 елның 17 июнендә ул 100 яшен тутырган булыр иде.Тик без аның юбилеен үзеннән башка үткәрдек. Бу дөньядан 94 яшендә китеп барса да, әниебез күңелләребездә һәрчак исән. Ул һаман да безнең укытучыбыз булып кала. ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

ХАЛКЫ ӨЧЕН БИРЕП БАР КӨЧЕН

Фарук Нәфиев



Исхак Мостафа улы Казаков (1876-1939) – партия һәм дәүләт эшлеклесе, ТАССРны оештыручыларның берсе

1918 елның маенда Совет хөкүмәте Петроградтан Мәскәүгә күчкәч, аның җитәкчесе В.И.Ленин, мөһим эшләрнең берсе итеп, Татар-башкорт Автономияле Республикасын оештыру мәсьәләсен күтәрә. Хөкүмәт составындагы Үзәк Мөселман комиссариаты җитәкчесе Мулланур Вахитов бу эштә якыннан катнаша, конкрет тәкъдимнәр кертә. Үзенең урынбасары Исхак Казаковны яңа республика хөкүмәтенә татарлардан мәгариф комиссары итеп тәкъдим итә.

Тәтеш татар мәктәбе укытучылары (алгы рәттә сулдан): Исхак Казаков, аның хатыны Нәфисә. 1909 ел

Аннары, шул ук елда Казанны ак чехлар басып алгач, Мулланур Вахитов фаҗигасеннән соң башланып, ике ел буена бөтен Россия буенча дөрләгән Гражданнар сугышы беренче милли республика оештыруга комачаулый.

Сугыш тәмамлангач, вазгыять үзгәрүне исәпкә алып, В.И.Ленин татар һәм башкортларның мөстәкыйль республикаларын төзергә карар бирә.

1920 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын оештыру ревкомына Исхак Мостафа улы Казаков кертелә.

Кем соң ул Исхак Казаков? Бу турыда аның улы Хаҗиморат абый (барыбызга да билгеле-мәгълүм «Бәләкәй Апуш» һәм бөек шагыйребезгә багышланган дистәләгән башка әсәрләр авторы), якын дустым, гаҗәп талантлы рәссам әтисе хакында тәфсилләп сөйләгән иде. Аның, дыңгычлап тутырылган зур сандыкны ачып, әтисенең төрле газета-журналлардагы язмалары, бастырып чыгарган китаплары, документлары, фоторәсемнәре, дәүләт бүләкләре белән таныштыруы бүген дә хәтеремдә. Мин Хаҗиморат абый белән 1968 нче елда, Тәтеш район газетасы редакторы буларак, аның әтисе 1919 елның 1 февралендә үз мөхәррирлегендә чыгара башлаган атналык «Тәтеш хакыйкате» газетасының беренче нөсхәсен эзләп баргач танышкан идем. Аннары, 1969 елда, безнең район газетасының 50 еллык юбилеенда Хаҗиморат абый да катнашты. Вакыт ничек тиз үтә – узган ел без газетабызның 100 еллыгын бәйрәм иттек.

Исхак Казаков 1876 елның 26 декабрендә Казанда туган. Әтисе, банкротлыкка төшкән сәүдәгәр, гаиләсен ташлап киткән. Исхак 4 яшьтән абыйсы тәрбиясендә үскән. Башта Нигъмәтуллин мәдрәсәсен тәмамлап, ул чорда татар зыялылары хәзерләү үзәгенә әйләнгән «Татарская учительская школа»га укырга кергән. Биредә соңыннан милләтебезнең бөек шәхесләре булып җитешкән Җамал Вәлиди, Садри һәм Әхмәтһади Максудилар, Мирсәет Солтангалиев, Гаяз Исхакый һәм тагын бик күпләр заманча югары белем алып чыккан. Мәктәп кенә дип аталса да, ул институтка торырлык югары уку йорты дәрәҗәсендә булган.

Әлеге мәктәпне тәмамлаган Исхак, 1900 елның көзеннән яңа гына оештырылган Тәтеш татар мәктәбендә, хатыны Нәфисә белән бергә, татар балаларына белем бирә башлый. Бер ел үтүгә, Исхак Казаковны мәктәп директоры итеп куялар. Ике зур, иркен, янәшә урнашкан, кирпеч нигездәге нарат бүрәнәләреннән салынган биналарның берсендә – малайлар, икенчесендә татар теле укытучысы Нәфисә Казакова җитәкчелегендә кызлар укый. Мәктәп белән рәттән генә бөтен җаен китереп салынган зур гына интернат бинасында Буа, Апас, Олы Тархан һәм Кама Тамагыннан килгән балалар яшәп белем ала.

Тәтештәге «Казаков мәктәбе»нең малайлар укыган бинасы

Тәтештә беренче тапкыр оештырылган заманча мәктәптә татар, урыс, гарәп теле һәм әдәбияты, физика, химия, география, тарих, математика, биология, зоология фәннәре укытыла.

Казаков мәктәбенең (берничә ел эшләгәч үк Тәтеш халкы аны шулай атый) зур иҗтимагый әһәмиятен аңлау өчен, соңыннан бөтен дөньяга танылган галим-химик Гыйлем Камай һәм хәрби атташе Һади Маликов исемнәрен атау гына да күп нәрсә турында сөйли.

Мәктәптә физика дәресе үткәрү өчен төрле прибор-җиһазлар, химиядән тәҗрибәләр үткәрү өчен реагент-матдәләр, торта-минзурка һ.б. да булган. Ә зоология белән биологияне нигезле өйрәнү өчен күпсанлы плакат-рәсемнәр дә актив файдаланылган.

Казан университеты ректоры булып эшләгәндә һәм аннан соң да Гыйлем Хәйри улы үзенең туган авылы Олы Тормыда (шагыйрә Маһруй Мозаффария дә шушыннан), Тәтештә еш булды, үзе укыган мәктәп коллективы һәм шәһәр җәмәгатьчелеге белән очрашты. Бөек галимнең, ул елларны искә алып, хатирәләре белән уртаклашканда: *«Заманча ныклы белем һәм тәрбия алдык без ул мәктәптә. Исхак ага Казаков һәм хатыны Нәфисә апа татар балаларын ул чорда мөмкин булган иң алдынгы ысул-методика белән укытуга, гомумән, шуның белән бергә, катлы-катлы изелүгә дучар халкыбызның артталыгын бетерүгә күп көч куйды. 1905 елдан соң халыкта алдынгы революцион караш-фикерләр таратулары өчен, аларны урындагы мулла-мунтагай яратмый иде. «Урыс фамилияле Казаков балаларыгызны, укыту белән бергә, чукындырачак та әле», – дип, алар ата-аналарны ул-кызларын мәктәптән алырга котыртып та маташты»*, – дип сөйләгәне дә хәтердә.

Әлеге җәһәттән шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Исхак Казаковның революцион эшчәнлеге беренче буржуаз демократик революция елларында башлана. Җитмәсә, шулай булырга кирәк бит, әлеге чорда Казан яшьләренең революцион әйдаманы Мулланур Вахитов – аның бертуган Өммегөлсем апасының улы! Аларны, туганлык җепләре генә түгел, татар халкын күп гасырлык милли изелүдән азат итү өчен патша самодержавиесенә каршы көрәш тә якынайта. Ул елларда Казандагы реаль училище

Тәтеш татар мәктәбендә Ислам дине нигезләре турында шәһәр мәчете имамы дәрес үткәрә. Бу балалар арасында булачак химик Гыйлем Камай белән хәрби атташе Һади Маликов та бар. XX гасыр башы

студенты Мулланур, пароходка утырып, Тәтешкә абзасы янына еш килә. Аңа, гектографта күбәйтеп, халыкка тарату өчен революцион прокламацияләр дә биреп калдыра.

Казаков мәктәбен тәмамлаганнан соң, үзенең гомерен хәрби эшкә багышлап, генерал дәрәҗәсенә ирешкән, СССРның Персиядәге (хәзерге Иран) хәрби атташесы **Һади Кәрим улы Маликов** үзенең истәлегендә болай дип яза: *«1905-1907 елларда үзем укыган Тәтеш мәктәбендә Исхак абый ачыктан-ачык революцион пропаганда алып барды. Без, укучылар, сыйныф бинасында ул өйрәткән «Марсельеза» кебек революцион җырларны хор белән башкара идек».*

Патша хөкүмәтенең тугрылыклы ялчылары – охранка һәм полиция дә йоклап ятмый. Алар И.Казаковны һәм укытучыларны даими күзәтү астына ала. Ә 1911 елның җәендә, директор фатирында тентү уздырып, В.И.Ленин брошюралары һәм прокламацияләр (барысы 169 данә) табып, үзен кулга алалар. Шуннан соң аны Оренбург далаларына гомерлек сөргенгә озаталар. Әмма ул чордагы вакыйгалар агымы кино тасмасындагы кебек алмашынып торганга, гомерлек дигәннәре өч елга да җитми – Беренче Бөтендөнья сугышы башланып киткәнгә, И.Казаковны якында гына урнашкан Юрьев полкына рядовой солдат итеп алалар.

Солдатлар арасында революцион пропаганда алып барып, ихлас большевикка әйләнгән Исхак Казаков, ниһаять, үзенең гаиләсенә, мәктәбенә, Тәтешкә сау-имин әйләнеп кайта. Ул Октябрь революциясен бередә өяз Мәгариф бүлеге мөдире һәм, бер үк вакытта, үзе укыта башлаган мәктәп директоры буларак каршылый.

1918 елның февралендә большевиклар партиясе сафына баскан И.М.Казаковны шул ук елны Мәскәүгә Үзәк Мөселман комиссариатына эшкә чакыралар, Мулланур Вахитовның урынбасары һәм коллегия әгъзасы итеп билгелиләр.

Казанда ак чехлар Мулланур Вахитовны атып үтергәч, И.М.Казаков берничә ай дәвамында Үзәк мөселман комиссариатын җитәкли, докладлар белән В.И.Ленин һәм И.В.Сталин янында була. Яшь совет хөкүмәте үткәргән чаралар һәм вакыйга-



Тәтеш татар мәктәбендә физика дәресе барган мәл. XX гасыр башы

лар үзәгендә кайный. Аннары ул, Үзәк мөселман комиссариатының коллегия әгъзасы Мирсәет Солтангалиев белән якыннан танышып, аның белән дуслаша...

1919 елның гыйнварында ул янә Тәтешкә кайта һәм, үзенә хас дәрт-көч белән оештыру мәсьәләләрен хәл итеп, 1 февральдән «Тәтеш хакыйкате» исемле татарча атналык газета (гарәп имлясында) чыгара башлый. Баштагы саннарда барлык мәкаләләрне үзе яза. Күпкырлы талант иясе, шул рәвешчә, полиграфист та, журналист та, педагог та, дәүләт эшлеклесе дә булып җитешә.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, ул бит әле 1905-1907 елларда аерым китаплар итеп басылган «Казанга сәяхәт» һәм «Замана туе» исемле комедияләр иҗат иткән язучы да!

...1920 елның 27 маенда В.И.Ленин һәм М.И.Калинин имзалаган Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзү турында карар кабул ителә. Башта аның җирлеген әзерләү, конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен 7 кешедән торган ревком оештырыла. Шунысы да игътибарга лаек: шәп хәтерле В.И.Ленин үзенең күптәнге танышы, хезмәттәше И.М.Казаковны әнә шушы революцион комитет составына кертә. Исхак Мостафа улы бу вазыйфасын да, үзенә хас тынгы белмәс холкы белән, көнне төнгә ялгап, тырышып башкара.

Ә Татарстан Республикасы оештырылгач, ул үзенең бөтен барлыгы белән эшкә чума. Башта совнархоз рәисе урынбасары, РКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы әгъзасы буларак күрсәткән зур оештыру сәләтен исәпкә алып, Исхак Казаков 1921 елның июненнән Татарстан Үзәк Башкарма комитеты (ТатЦИК) председателе урынбасары итеп билгеләнә. Өстәвенә, ул, ачлыкка каршы көрәш Президиумы әгъзасы буларак, Татарстан балаларын ачлыктан саклап исән-имин калдыру өчен конкрет чаралар күрә башлый. Бу җәһәттән, Мәскәүдә Ф.Э.Дзержинский үткәргән киңәшмәдә дә булып кайта.

Бу – тарихтан барыбызга да мәгълүм Идел буенда, аеруча Татарстанда котырынган коточкыч ачлык чоры. Классигыбыз Галимҗан Ибраһимов үзенең «Адәмнәр» повестен-

«Казаков мәктәбе»ндә бүген балык тоту өчен кирәк-яраклар сатыла торган кибет урнашкан. 11 гыйнвар, 2020 ел

да сурәтләгәнчә, чарасыздан каннибалчылыкка – кеше ашауга барып җитүләре белән тетрәндергеч очраклар да булган. Әлеге нисбәттән, Республика хөкүмәте башлыгы Сәхипгәрәй Сәетгалиевнең Татарстан халкына карата җинаятьчел гамәлләр кылуы беренче карашка бөтенләй аңлашылмый. Ул, Мәскәү алдында, аеруча Сталин каршында яхшы булырга тырышып, продразверстка ярдәмендә крәстиәннәрнең ашлыгын, хәтта орлыкка дигәнен дә калдырмыйча, соңгы бөртегенә кадәр тартып (талап) алып, заданиене арттырып үтәп, эшелоны белән Саратовка озата. Авыл һәм шәһәр урамнары ачлыктан егылып үлгән кеше мәетләре белән тула. Калганнарның аларны җирләргә хәлләре булмый.

Бу хәлләрне үз күзләре белән күреп, Исхак Казаков, Мәскәүдәге дусты Мирсәет Солтангалиевкә шылтыратып, фаҗигале хәлне аңлата. Мирсәет исә, шул ук минутта В.И.Ленин янына кереп, хәлне аңлатып, кирәкле вәкаләтләр алып, Казанга ашыга. (Миңа бу турыда этисе сөйләгәннәрне рәссам дустым Хаҗиморат абый җиткергән иде.)

Казанга килеп җитү белән, Мирсәет Солтангалиев, партия өлкә комитеты бюросы һәм хөкүмәт әгъзаларын җыеп, гадәттән тыш хәлне көн тәртибенә куеп, ашыгыч киңәшмә үткәрә. Ул, Татарстан халкын ач үлемгә дучар иткән Сәхипгәрәй Сәетгаливне кискен гаепләп, аны эшеннән алдыруга ирешә. Архивта бу киңәшмәнең беркетмәсе – стенограммасы бүген дә саклана. **Сәетгалиев** үзенең чыгышында: *«Миңа татар халкы булды ни дә, булмады ни, мин – бөтендөнья пролетариатының перманент революциясе тарафдары, ә менә син, Солтангалиев – чеп-чи милләтче, татар-башкорт, дип, юкка авыз суыңны корытучы контра!»* – дип, М.Солтангалиевне гаепләргә тырыша.

Шунысы да мәгълүм: Сәетгалиев, эшсез калдым дип аптырап тормый, Мәскәүгә барып, үзенең кадерле остазы И.В.Сталин янына кереп аһ-зарын җиткерә. Ә тегесе, Ленинның төзәлмәс авыруын яхшы белгәнгә, озакламый, дилбегәне үз кулына алгач, Солтангалиев ишеләрне нишләтергә белермен дигәндәй, мәкерле елмаеп: «Не горюй, бери себя в руки и завтра же отправляйся в Крым, где такая же татарская автономная республика, прими её под свою ответственность!» – дип, кирәкле мандатны әзерләтеп бирә.

Шунысы гаҗәп: Сәетгалиев эшли башлагач, Кырымда да ачлык тирән тамыр җәя...

Бу хәл-фактлар мин уйлап чыгарган фантазия түгел, ә аяныч чынбарлык. Күренекле тарихчы галимебез Тәэминә Биктимерованың «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыккан язмасында тәфсилләп сурәтләнгән мәгълүматлар. Әле күптән түгел генә (11 октябрь, 2019 ел) «Атна яңалыклары» газетасында басылып чыккан әңгәмәсендә дә галимә ханым Татарстандагы ачлык вакытлары, миллионлап кеше – күбесе татарларның кырылып юкка чыгуы турында әрнеп сөйли...

1929 елда (кайбер чыганакларда – 1930), Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен, И.М.Казаковка союз күләмендәге персональ пенсия билгеләнә. Әмма әле ул ял итәргә ашыкмый, тагын 8 (7) ел буе Татарстан тәэминат халык комиссарының урынбасары булып эшли. Шул чорда аның Болак һәм Кабан күлләренең суын күтәрү проектын төзүе дә мәгълүм. Аның тагын бер гаҗәеп фараз-гипотезасы – Татарстанның җир асты катламнарында промышленность масштабындагы зур нефть-битум ятмалары булырга тиеш дип санавы. Ул әлеге фаразлары турында Казан газета-журналларына гына язып калмый, СССР Фәннәр Академиясенә – әлеге мәсьәләләр белән шөгыльләнүче академик И.М.Губкин янына махсус барып сөйләшә.

«Бәләкәй Апуш» авторы, Исхак Казаковның улы Хаҗиморат Казаков (сулда) һәм мәкалә авторы Фарук Нәфиев. 1969 ел

Соңыннан, Мәскәүдән килгән геология разведкасы тикшерә башлауның беренче көннәрендә үк, И.М.Казаковның фаразы тулысынча раслана!

Иле, республикасы, халкы өчен фидакарь хезмәт куеп, олы яшькә җиткән ветеранны Сталин җәлладлары тынычлыкта калдырмый – 1937 елның июнендә, халык дошманы, дип, аны кулга алалар...

Язмам герое Исхак Мостафа улы Казаков 1939 елның 16 октябрендә Казанның Пләтән төрмәсе хастаханәсендә вафат була. Соңыннан махсус комиссия, И.Казаковның бер гаебе дә булмаганга, аны тулысынча аклый.

Халкыбыз күргән иксез-чиксез михнәтләрне онытмау белән бергә, республикабызның 100 еллыгын каршылаганда, без аны оештыручы, фидакарь хезмәтләре белән ныгытучы бөек шәхесләрне олы рәхмәт хисләре белән искә алабыз һәм исемнәрен шанлы да, фаҗигале дә тарихыбыз сәхифәләренә алтын хәрефләр белән язабыз. ■



ӘТИ

Әзһәр Шакиров

Миңа алты-җиде яшьләр чамасы булгандыр, мөгаен. Бер заманны малайлар белән кар атышып уйнаган чагында Фазыл:

– Әдһәр, Әдһәр, әнә, бабаң килә, бабаң килә, – дип, мине үртәргә тотынды.

Мин әйтәм:

– Нишләп ул минем бабам булсын, минем әти бит ул! – дим.

– Бабаң инде, бабаң! Атаң булса, ул сугышта булыр иде. Безнең әтиләр немесләрне кырып чын герой булдылар! Ә бу – синең бабаң!

– Юк, бу минем әтием! – дип, Фазылга ташландым.

Ә ул: «Үтерәм!» – дип, минем өскә ташланды. Рушан белән Фаяз көчкә аерды.

Чыннан да, мин дөньяга килгәндә әтигә – 53, әнигә 43 яшь булган. Әтине ап-ак сакаллы, ап-ак чәчле, бер якка әз генә бөкрәеп торган кыяфәтле, җиңел сөякле, зәңгәр күзле сурәттә күз алдына китерәм. Ә инде аның башка кешеләрдән аермасына килгәндә, шуны әйтә алам: күпме гомер сөрелгән дә, нинди генә кешеләр белән очрашып күрешелмәгән, ләкин аңа охшаш бүтән кешене күрмәдем; чөнки җәй көне эш эшләп тирләгәндә, әтинең уң ягы манма су, ә сул ягы коп-коры була торган иде. Әйтерсең лә, кешене икегә бүлгәннәр.

– Әти, нишләп синең сул ягың коры, уң ягың манма су? – дип сораганым хәтердә калган.

– Әй, балакаем, безнең авылыбыз янганда, мин пожарник булып эшләдем. Шул вакытны, салкын чишмәдән мичкәләргә тирләгән килеш су тутырганда, үпкәмә салкын тиде. Ике ай кан костым. Бер як үпкәм кан булып чыкты. Менә шуннан бирле шушындый чире калды инде, – диде ул.

Кышкы озын кичләрдә без тимер мичкә яга идек. Еш кына авыл яшьләре безгә җыелыша. Чөнки авылда клуб та, җыелып утырырлык нindидер бүтән урын да юк. Әти кызык-кызык хәлләр сөйләргә керешә. Гомумән, ул сүзгә оста кеше иде. Шуларның берничәсе хәтергә уелып калган. Авылда көзге эшләр беткәч, ир-егетләр, бераз акча эшләү өмете белән, Донбасска күмер чабарга чыгып китәләр икән. Әнә шул Донбасс турында сөйләгәне минем өчен иң кызыгы иде.

Әти әйтә:

– Мин шахтада сукыр атлар белән эшли идем, – ди.

– Әти, ул сукыр атлар җир астына ничек төшәләр соң? – дип сорыйм.

– Улым, алар башта сукыр булмыйлар, бер-ике ел җир астында эшләгәч кенә сукыраялар.

– Әти, сукырайгач та эшлиләрме?

– Без аларның арбаларына күмер төйибез дә, әкрен генә алларыннан җитәкләп барабыз, алар безгә иярә.

Мин исә әлеге сукыр атларны күз алдына китерәм дә, мөлдерәп күз яшьләре килә, еларга ук тотынам.

Әнкәй әткәйне:

– Төнгә каршы шундый әйберләр сөйләмәсәң, бүтән әйтер сүзең беткәнмени? – дип тирги...

– Шәфыйк абзый, теге... балык тотканың турында да сөйлә инде, – дип, яшьләр әтинең теңкәсенә тияләр.

– Без Златоуст шәһәре тирәсендә урман кисәбез. Шулай кисә торгач, бер күл буена килеп чыктык. Туктале, мәйтәм, шунда мурда салып карыйм әле, дим. Күл буендагы таллардан мурда үреп салдым. Эш беткәч, сак кына тартып чыгарган идем, кәрәкә балыгы белән шыплап тулган бу. Хәзер нишләргә инде? Иптәшләрем торакка кайтып киткән, янымда һичкем юк. Караңгы төшеп килә. Күлмәгемне салып, җиңнәрен төйнәп бәйләп куйдым. Әлеге йөгемне иңгә салып, кайтыр юлга төшү белән үк, бөтен тәнемне черки сырып алды бит. Нишләргә белмим, учым белән битемә шап-шоп сугам. Бара-бара күзем күрмәс булды. Ничек чыкканымны хәтерләмим. Бөтен тирәмдә корт күчедәй черки безелди. Үләм икән, мәйтәм, кайталмыйм икән бит болай, дим. Яфраклы ботак белән черки өерен куам. Ә тегеләр аның саен котырына, бөтен тәнемне сырып ала. Хәзер инде миңа балык комачаулый, аларны берәм-берәм ташлап калдырудан башка чарам юк. Миңа күзгә төртсәң дә күренмәс караңгы сыман булды, һични күренми. Бер күземне ачып карыйм – юлымнан язган шикелле тоела. Шунда кылт итеп исемә төште: урманда кешеләрне җәзалап үтерү өчен йә кырмыска оясына, йә черкиләргә бәйләп ташлыйлар икән, кеше, түзә алмыйча, бер көндә һәлак була икән. Хәзер инде мин шуңа тәмам ышандым. Инде нишләргә дә белмичә аптырап торганда, миңа кычкырган тавышлар ишетелде сыман. Акылымнан шашкан кебек: «Ярдәм итегез, ярдәм итегез, үләм, үләм!» – дип, бөтен көчемә кычкыра башладым. Шуннан ни булганын хәтерләмим, ике көннән соң гына аңыма килдем дә үлемнән котылып калганымны аңладым.

– Әти, – мин әйтәм, – балыкларыңны кая куйдың соң?

– И, балакаем, ул вакытта миндә балык кайгысы идемени? Әти белән әни бәхетенә исән калганмын, дип, Ходай Тәгаләгә мең-мең рәхмәтләр укыдым.

Театрдан ял акчаларын алып, иптәшләр белән җыелырга дип өйгә кайтсам, Җәннәт ападан хат килеп төшкән: «Балакаем, кайт, этинең хәле авыр, сине күрәсе килә», – дигән. Бик кайтыр идем дә, акча яклары такыррак шул, ничек булса да бераз акча эшләп алырга кирәк иде. Берәр концерт бригадасы юк микән, дип сораштырып карыйм, юк, барысы да җыелып, бергәләшеп беткәннәр, бер җүнле кеше дә калмаган. Шунда Миргалим Харисов:

– Әйдә, Искож клубы белән чыгабыз, – диде. – Көненә ун сум түлиләр, квартирный юк, ашау колхоздан.

– Мин үз исемем белән чыкмыйм, исем-фамилиямне алыштырам, – мәйтәм.

Сәхнәгә Рәшит Гарифуллин исеме белән чыктым. Концертны алып баручы матур гына бер кыз: «Хөрмәтле тамашачылар, сезнең алдыгызда – Искож клубының танылган җырчысы Рәшит Гарифуллин, кул чабып каршы алыйк. Ул сезнең яраткан иң матур җырларыгызны башкарачак. Тарсынмагыз, бердәм кул чабыгыз, монда кулларыгызны җәлләп, бер-берегездән оялышып утырмагыз. Артистларны дәррәү килеп, кул чабып каршы алалар аны», – дигәч, сәхнәгә килеп чыктым. Кул чабып каршы алучы юк. Бу авылның театр-концерт күрмәгәненә 15-20 ел узгандыр, дип сөйләделәр. Без Алексеевск районындагы иң «караңгы» татар авыллары буенча йөрдек. Монда ни филармониянең, ни күчмә театрның булганы юк икән. Шунда сәхнә артына матур гына киенгән бер укытучы килеп керде дә миннән:

– Сезнең абыегыз артист Шакиров түгелме? Мин академия театрында Сезгә охшаган бер артистны күргән идем. Сез шуны бик хәтерләтәсез, – дип сорады.

– Юк, – мин әйтәм, – академия театрында минем абыем эшләми, ләкин миңа охшаган бик талантлы бер артист бар, дип сөйлиләр.

– Шул Шакировның туганы булсагыз, мин Сезне үзебезгә кунакка чакырмакчы идем. Бик кызганыч, болай булгач, хушыгыз инде, – диде дә китеп барды.

Әтием Шәфигулла



Соңыннан: «Нигә инде шунда мин аның бертуган энесе дип әйтмәскә? Хәзер менә кунак булып, җырлап утырыр идем», – дип үкенеп куйдым.

Егерме концертка 200 сум акча кулга алгач, әти белән үги әни янына кайтып киттем (әни күптән вафат иде инде).

Минем каршымда чәче җиткән, ап-ак сакал-мыегы кырылмаган, йөзе саргая башлаган, бөкресе тагын да калкарак төшкән, бик нык ябыккан әтием басып тора иде. «Улым!» – дип күрешкәч, эчем жу итеп китте. Ничектер ул минем әтием кебек түгел иде: мин аның бөтен тәне генә түгел, ә бәлки җаны да үзгәрүен тоеп өлгердем.

Мин әйтәм:

– Нишләп чәчеңне алдырмадың? – дим.

– Сине көттем, – диде ул.

Тиз генә су җылытып, чәчен такыр итеп кырып алдым, сакал-мыегын пөхтәләп төзәттем, җылымса су белән муенын, аркасын юып төшердем. Әти, хәл алып, рәхәтләнеп китте.

– Улым, – диде ул, – иртәгә мине Азнакай больнисына алып бар әле.

– Ярый, – мин әйтәм, – бензин ташый торган машинасында абый кайта, шуның белән иртүк барырбыз.

Икенче көнне Азнакайның баш табибы янына килеп кердем.

– Исәнмесез! Мин артист Шакиров булам. Минем әти бик нык чирли, ярдәм итегез, – дим.

Ул, миңа карап торды да:

– Мин җырчы Шакировны беләм. Ә син кем буласың? – дип сорады.

Мин әйтәм:

– Илһам Шакиров филармониядә эшли ул, ә мин – артист Шакиров, академия театрында эшлим. Филармония белән академия театрының дәрәҗәсен дә белмәгәч, син ничек баш врач булып эшлисең монда? Бу турыда сөйләсәң, үзеңне мыскыл итеп көләрләр бит. Бик кызганыч кебек булып чыктың әле, артист Шакировны белмим, дисең!

– Ярый, ярый, бу турыда оныттык, – ди. – Әтиең кайда?

– Апаларда калып торды, кирәк икән, хәзер үк алып киләм.

– Әтиең ничә яшьтә?

– Сиксәннән өстә, кече йомышын үти алмыйча интегә.

– Ярый алайса, безне өегездә көтеп торыгыз, көндезге аш вакытында килербез.

– Бик зур рәхмәт мине хөрмәт итүегезгә, менә адрес, – дип чыгып киттем.

Кайтып, тиз генә аш куйдым, мунча ягып җибәрдем, җизни кабымлыклар әзерли башлады. Табибларны көтәбез. Шул арада әтине мунчада бик яхшылап юындырдым да, чиста күлмәк-ыштан киендергәч, диванга яткырдым.

Табиблар кичкә кырын гына килеп керделәр. Әтине карагач, үзләренчә киңәштеләр, ягъни консилиум оештырдылар.

– Бик өлкән яшьтә, операцияне күтәрә алмас, – диде хирург. Аның белән уролог та килеште:

– Хәзер моның сидеге тәненә тарала башлаячак.

Ә терапевт әйтә:

– Дарулар белән ярдәм итеп булмас микән? – ди.

Яңадан әти янына керделәр дә:

– Бабай, яшең бик өлкән, шуңа күрә сиңа операция ясамаска булдык. Менә, әкрен генә үләннәр, дарулар белән чәй эчәрсең. Хәлең авырайса, шалтырат, килеп алырбыз, – диделәр...

...Яхшы гына итеп сыйлангач, терапевтлары миңа:

– Бездә дару бар инде ул, син главврачтан сорап кара әле, – дип әйтеп куйды.

Мин исә бераздан баш табибтан:

– Сездә әтигә ярдәм итәрлек бернинди дә дару юкмыни соң? – дип сорадым.

– Бар инде ул, тик санаулы гына. Без аны райком секретарьларына, райисполком председателенә, прокурорга гына бирәбез, – диде ул.

– Болай булгач, первый секретарьның үзенә керергә туры килә инде. Ул мине белә, үзем сөйләшермен, – дидем мин.

Шуннан соң баш табиб, шоферын җибәреп, әлеге даруны миңа бүләк итеп бирде. Польшада эшләнгән дару икән. Башта чиреген генә, аннан соң яртысын, икенче көнне бер бөтенне кабасы икән.

Мин, зур рәхмәтләр әйткәч, тагын да сыйларга сүз биреп, табибларны озаттым. Мин кергәндә, әти теге дару төймәсен бөтен килеш капкан да куйган. Төн буена берөзлексез кысталып, җәфаланып чыкты.

– Үләм, балакаем, нигә эчтем икән? – дип, тәмам өзгәләнде.

– Нигә бер бөтенне эчтең, алай кушмадылар ич сиңа.

– Түзмәдем инде. Тизрәк ярдәм итмәсме, янәсе...

Ике-өч көн узгач, әти мине үз янына чакырып алды.

– Кил әле, балакаем, утыр әле яныма, – диде ул. – Сиңа әйтәсе сүзләрем бар иде... Мин үлгәч, әниең белән минем каберләрне карарга тырыш. Юкса, Шәфигулланың бала-

лары әти-әнисенең каберен дә карый белмиләр, дип әйтерләр. Үзеңә бик уңайсыз булыр, кеше алдында абруең төшәр. Азнакайда күрдем синә ничек караганнарын, авторитетың бик зур икән. Аны сакла, бер югалтсаң, гомерең буе үкенерсең... Бәйрәмнәрдә әниең белән мине искә алып, хәер бирергә онытма. Хәер бирсәң, җаның тынычланыр, әниең белән мине искә төшерерсең. Шул чагында кылган гөнаһларыңны ярлыкавын бер Ходайдан сора. Менә әле исемә төште: үткән көз көне Буралыдан җомга намазыннан кайтканда, бурилщиклар казыган чокырга ялгыш аягым таеп төшеп киттем. Үзең беләсең, хәзер бит минем күзләр начар күрә, чокырны абайламаганмын. Ә чокыр бик тирән булып чыкты. Аяк астында нефтьле су иде. Мин чокырдан чыгарга тырышып карыйм. Күтәрелгән саен аяк тая да китә, тая да төшә. Кул белән тотынырлык бер әйбер юк. Бик озак азапландым. Бу юлда кеше йөрми инде, мәйтәм, шушында көз көне үлеп калам икән дип уйладым. Бөтен гомерем, бөтен яшьлегем күз алдымнан узды. Ходай Тәгалә минем җанымны алырга шушы урынны әзерләгән икән дип уйладым. Эх, мин әйтәм, балаларымны күрмичә, бәхилләшмичә, шушында үлеп калам икән, дип, җан ачысы белән кычкырган сыман булдым. Белмим, мине нинди көч этәргәндер инде, үз-үземне белештермичә көчәнгәч, чокыр кырыена менеп ятканмын. Сөенечемнән мөлдерәп яшем ага. Әллә, мин әйтәм, Ходайның фәрештәләре күтәреп чыгарганмы? Бу бәладән нинди кодрәт белән котылдым, дип, җылый-җылый Ходайга рәхмәтләр укыдым. Әҗәлең килеп җитмәсә, гомерең бетмәсә, Ходай Тәгалә яшәргә көч бирә икән. Хәзер инде, балакаем, менә мин үләм, озак яшисем калмады. Кулыңнан килгәнне эшләдең, рәхмәт сиңа...

Мин, түбән караган килеш, бер сүз эндәшмичә утырам, күземнән бертуктаусыз яшь ага. Мине укытыр өчен, Чалпы мәктәбенә – 175 сум, фатирда тотар өчен аена 30 сум акча түләп, егерме чакрымга бер йөк утын китереп, ашатып, киендереп, бөтен рухын, көчен укырга бирсен, дип, җан атып йөрде. Гомерендә мине авыр сүзләр әйтеп тиргәмәде-сүкмәде, кулын күтәреп беребезне-бер рәнҗеткәне булмады. Үз гомерендә биш вакыт намазны калдырмады; яңгыр дими, кар дими, дүрт чакрымдагы Буралыга җомга намазына йөрде. Югыйсә, аңа инде 87 яшь иде. «Аллаһы Тәгаләгә ышансаң, үлемне җиңел кичерерсең, үлемнән курыкмассың», – дия торган иде ул. Чыннан да, Ходай Тәгаләнең барлыгына ышанган кеше үлемне җиңел кичерә, диләр.

...Арча төбәгендә Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» әсәре нигезендә куелган спектакльне уйнарга әзерләнәбез. Аны районның беренче секретаре карый, Хәй абый банкет ясый икән, дип, барыбыз да күтәренке күңел белән кичке мәҗлескә әзерләнәбез. Ул вакытта банкетлар бик кадерле, чөнки аны киң күңелле авторлар гына эшли иде. Шунда театрыбызның директоры Рәшидә апа Җиһаншина телефоннан шылтыратты: «Әзһәр, әтиеңнең хәле авыр, кайтып җитсен, диделәр. Ничек уйлыйсың, бүгенге спектакльне отменять итәбезме, әллә инде иртәгә генә кайтырсың микән?»

Белмим, нишләптер спектакльдә катнашырга булдым. Бәлки, билетлар сатылып бетүен, бүген «хуҗалар»ның тамашага килүен, Хәй абыйның банкеты булуын искә алыпмы, шушындый матур көнне артистларның күңелләрен төшерергә көчем җитмәгәнгәме, спектакльдә уйнадым, банкет та булды. Ә төнлә үземне кая куярга белмим: нишләп мин мондый начар эш кылдым, дип, үземнең җанымны, йөрәгемне талыйм, җүнле кеше мондый эшне гомер эшләмәс, дип, үз-үземне битәрлим – сүгәм.

Икенче көнне «Әтине җирләдек» дигән телеграмма килеп төште. Хәзер соң инде: шагыйрь әйтмешли, үкен, үл син, җыла! Барыбер мәңге төзәлмәслек хата.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Милләтпәрвәр шәхес, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты* ***Әзһәр ага Шакировның*** *февраль аенда гомер бәйрәме –* ***80 яшь****! Аны юбилее белән ихлас котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез!* ■

Истә, һаман да истә!

Композитор
Рафаэль Биляловның
туына 80 ел

* * *

Композитор, пианист, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1980) Рафаэль Нури улы Билялов 1940 елның 1 февралендә Казанда туган.

Р.Билялов 1966 елда Казан консерваториясен тәмамлый. Аның шәкертләре арасында танылган композиторлар Р.Абдуллин, Р.Ахиярова һәм Л.Батыр-Болгари бар. Композиторның М.Хөсәеннең «Ак шәһәр» һәм Р.Кутуйның «Батырлык турында баллада» исемле шигырьләренә язылган җырлары төрле конкурсларда күп мәртәбә җиңү яулады.

Шагыйрь
Тәүфикъ Камалиевның
туына 80 ел



* * *

Шагыйрь Тәүфикъ Камалиев (Тәүфикъ Салих улы Камалетдинов) 1940 елның 3 февралендә Татарстанның Буа районындагы Ташкичү авылында туган.

«Ромашкалар эзлим» исемле беренче җыентыгы 1967 елда басылып чыга. Шуннан соң дөнья күргән «Сабыр канатлары сынмый» (1968), «Озата бармагыз» (1969), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972), «Яшьлеккә кайту» (1978) исемле җыентыкларында шагыйрь, үз темасына тугрылыклы калып, гади хезмәт кешеләренең уй-хисләрен шигъри юлларга салырга омтыла.

Т.Камалиев 1971 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде. Ул 1980 елның 13 февралендә вафат булды.

Актриса
Ания Фәттахованың
туына 80 ел

* * *

Актриса, Татарстанның атказанган (1974) һәм Татарстанның халык артисты (1990) Ания Гарифулла кызы Фәттахова (Шәрифуллина) 1940 елның 5 февралендә Минзәлә районының Аю авылында туган.

1960 елда Алабуга культура-агарту училищесын тәмамлагач, ул Минзәлә театрында эшли башлый. А.Фәттахова уйнаган рольләрнең кайберләре: Хәят – «Хәят» (Ф.Әмирхан), Мәйсәрә – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Сәрвәр – «Башмагым» (Х.Ибраһимов), Розалия – «Соңгы хат» (Х.Вахит), Галия – «Гармун һәм скрипка» (Т.Миңнуллин), Хәдичә – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).

А.Фәттахова 2000 елның 10 мартында Түбән Кама шәһәрендә вафат булды.

Әдәбият галиме
Хәсән Хәйринең
туына 110 ел

* * *

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1970) Хәсән Хәйри (Хәсән Фәхретдин улы Хәйруллин) 1910 елның 5 февралендә Россиянең элеккеге Урал губернасына кергән Лбищенск дигән өяз үзәгендә (хәзерге Казакъстан Республикасының Көнбатыш Казакъстан өлкәсе) керәстиян гаиләсендә туган. Ул, сигез-тугыз яшьләрендә әти-әнисез калып, 1925 елның көзенә кадәр Җаек (Казакъстан) шәһәрендәге балалар йортында тәрбияләнә, шунда башлангыч белем ала.

Х.Хәйри «Татар совет әдәбияты тарихы» китабында (1960), автордаш буларак, Һ.Такташ иҗаты һәм 1945-1960 нчы еллар татар поэзиясе турындагы хезмәтләре белән катнаша.

Х.Хәйри 1936 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде. Ул 1994 елда Казанда вафат булды

Актриса
Рабига Шакированың
туына 110 ел

* * *

Актриса, ТАССРның атказанган артисты (1957) Рабига Нигъмәтҗан кызы Шакирова 1910 елның 10 февралендә Арча районының Яңа Кенәр авылында туган.

Р.Шакирова 1937 елда Минзәлә театрында эшли башлый. Ул уйнаган рольләрнең кайберләре: Галчиха – «Гаепсездән гаеплеләр» (А.Островский), Ана – «Шатлык җыры» (Г.Кутуй), Фекла – «Өйләнү» (Н.Гоголь), Майлыбикә – «Язылмаган законнар» (Ю.Әминев), Биби – «Кара чәчәкләр» (С.Җамал).

Р.Шакирова 1996 елның 17 октябрендә вафат булды.

Язучы
Газиз Нәбиуллинның
туына 100 ел

* * *

Балалар язучысы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Газиз Нәбиулла улы Нәбиуллин 1920 елның 15 февралендә Татарстанның Саба районындагы Керәнле авылында туган.

Г.Нәбиуллин – дистәдән артык китап авторы. Шулардан кайберләре: «Безнең авыл балалары» (1948), «Әнем турында шигырьләр» (1957), «Пьесалар» (1964), «Яшел эстафета» (1968), «Үрләрем» (1970), «Тын елга җыры» (1980).

Г.Нәбиуллин 1961 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы иде. Ул 1986 елның 14 маенда вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Милли музейда – ПО-2 САМОЛЕТЫ

Казан авиатөзелеш заводында җитештерелгән ПО-2 самолеты – легендар экспонатларның берсе, халкыбызның Бөек Ватан сугышындагы батырлык символы.

1941 елның августында Ленинград авиазаводы Казанга эвакуацияләнә, тиздән анда Н.Н.Поликарпов У-2 конструкцияле очкычны чыгару эшен җайга сала. Башта бу самолетлар очучылар әзерли торган мәктәп һәм аэроклублар курсантларын өйрәтү өчен кулланылган.

Соңрак У-2 самолеты җиңел бомбардировщик сыйфатында серияле җитештерелә башлый. Алар, Кызыл Армиянең авиаполкларына, аерым алганда, легендар 46 нчы хатын-кызлар авиация полкына тапшырылып, төнге һөҗүмнәр өчен файдаланыла.

Вакытлар узу белән, ПО-2 исемен алган самолет разведка, партизан отрядлары белән элемтә урнаштыру, хәтта ягулык ташу өчен «танкер» буларак файдаланыла башлый. Бу машинаның элемтә, штаб, санитар һәм башка модификацияләре булдырыла.

Казан авиатөзүчеләре тарафыннан сугыш ахырына кадәр 11 меңнән артык ПО-2 самолеты җитештерелә.

1951-1987 елларда самолет ТР Милли музее экспозициясендә зур кызысыну уятса да, соңгы берничә дистә елда, мондый төр машиналарны төзекләндерүче реставратор-белгечләр булмау һәм бу эш гаять кыйммәт булу сәбәпле, фондта саклана. Ул музеебызга килгән кунакларга һәм туристларга күрсәтелми.

Ленар Нәгыймов,
ТР Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре ■

Авиаконструктор Н.Н.Поликарпов

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

КЫЛ-КУБЫЗ

Яулыгын кыя салып,
Күргәннең исен алып,
Хур кызыдай утырган
Сылуны күрде Идегәй.
Алтын башлы чаң кубыз
Кыз кулында чыңлыйдыр.
Кыл кубызны чыңлатып,
Елый-елый җырлыйдыр.

«Идегәй» дастаны

Кыл-кубыз – гомум төрки, ике кыллы, сызгычлы уен коралы. Кыска гына итеп ясалган сабында лад аралыклары юк. Беренче калын кыл кече октаваның *ля*, икенче кыл беренче октаваның *ре* тавышларына, кайбер очракларда ике кыл да беренче октаваның *ре-соль*, ягъни кварта тавыш аралыгына көйләнә. Диапазоны ике октавага кадәр. Кыл-кубыздан чыккан музыкаль тавышның төп үзенчәлеге шунда – биредә кылга да, сызып уйный торган җәягә дә (смычок) ат кылын бөтереп тарттыралар. Ике ат кылының ышкылуы аркасында шомлы, серле авазлар хасил була. Кыл-кубыз ике өлештән тора: юка тактачыклардан җыйналган кузов һәм 40 см. лы сап өлеше. Сызгычны ясау өчен агач ботагын җәя кебек бөккәннәр һәм аңа, бөтереп, ат кылы тарттырылган. Кыл-кубызны утырган килеш, тезгә куеп, басып уйнаганда исә, корсакка терәп уйныйлар.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Төрки халыклар бер-берсенә охшамаган берничә төрле уен коралын **кубыз** дип йөртә. Мәсәлән, кыргызлар өч кыллы чиртеп уйный торган уен коралын – **комуз**, казакълар ике кыллы сызгычлы уен коралын – **кылкобыз**, диләр. Әле тагын авызга куеп уйный торган сөяк, агач һәм металлдан ясалганнары да бар. Мондый уен коралларының һәммәсендә дә имчеләр, камнар үзләүгә кушылып уйнаган. Шуңа да «кубыз» сүзе камлау һәм үзләү сүзләреннән килеп чыккан да. Ә инде соңрак казакълар гармунны – **тел**

кубыз, чуашлар скрипканы – **сирме купас**, татарлар җәяне **җәя кубыз** дип тә йөртә башлыйлар.

Татар халкы бу уен коралында уйнаганмы, уйнамаганмы – тарихи истәлекләр бик аз. Шулай да татар фольклор музыкасында кыл кубыз булмаган, дип, без берничек тә әйтә алмыйбыз. Бәлки, ул, уен коралы буларак, кулланудан вакытлыча төшеп кенә торгандыр. Ерак китмичә генә тарихка күз салыйк әле. 17 нче йөзләрдә беренче скрипкалар безнең якларда күренә башлагач, татар музыкантлары көчле, матур тавышлы скрипкада бик җиңел генә уйнап китәләр. Чөнки гасырлар буе кыл-кубызда уйнаган халык өчен, скрипкага күчүнең бер читенлеге дә булмый. Әле 1950-70 нче елларда да авыл агайлары скрипканы тезгә, билгә куеп уйныйлар иде. Бер кылда көй уйнаганда, икенче кылда гел төп тоник тавыш яңгырап тора. Бу да – кыл-кубызга хас сыйфатлар. Әлеге уен алымы бигрәк тә бию көйләрен уйнаганда матур яңгырый. Сызгычны да (смычок) скрипка уйнагандагы кебек түгел, ә нәкъ кыл-кубыз уйнагандагы кебек сул кул белән учлап, кыл ягын үзеңә каратып тоталар иде.

Күренекле сәяхәтче **П.Паллас** үзенең хезмәтендә бер күренешне тасвирлый. *«Семипалатинск крепосте янында эшләүче ялланган татар казаклары арасында бер татар «орфее, уен коралында уйнап ташларны биетмәсә дә, безнең күңелләрне күтәрде»*, – ди ул. Аннан соң, бу татар кешесе уйнаган уен коралы турында әйтеп үтә. Ат кылы тарттырылган кыллардан сызгыч ярдәмендә аккош кычкырган тавыш чыгарган һәм ул уен коралының аккошка охшаган булуын әйтә. Сүз монда кыл-кубыз турында бара. Дөрестән дә, кыл-кубызның ясалышы аккошка охшаган, анда төрле кош кычкырулары, сыер мөгрәүләре, табигать тавышлары бик килешле яңгырый. Әгәр дә әлеге татар кешесе элек бу уен коралы белән таныш булмаса, шулай оста итеп уйный алыр идеме?!

Миңа калса, кыл-кубызның кулланылыштан төшеп калуына төп сәбәпләрнең берсе – алда әйтеп киткәнемчә, татарның ачы язмышы, ягъни аның мондый катлаулы уен коралларын ясарга мөмкинлеге булмау. Икенче сәбәп – көчле, матур тавышлы срипканың көнкүрешкә килеп керүе. Скрипка безнең якларда 17 нче йөздә күренә башлый. Өченче сәбәп – кыл-кубызның иң беренче килеп чыгышы дини максатлардан булган, дидек. Анда имчеләр уйнаган. Татар халкы исламга тирәнрәк кергән саен, бу уен коралының инде кирәге калмый башлый. Шуңа да, керәшеннәрдә, чуаш, удмурт, коми халыкларында шундый ук уен кораллары озаграк сакланган.

Татар милли музыкасында кыл-кубыз үз урынын тизрәк тапсын иде, чөнки сызып уйный торган милли уен коралларыбыз бүтән юк.

ҖӘЯ-КУБЫЗ

1983 елда Казан-Мәскәү поездында, очраклы гына, 76 яшьлек Нигъмәтҗан Галимов дигән бер абзый белән очраштым. Сүз ара сүз чыгып, ул миңа үзенең җәядән кубыз ясап уйный белүе турында сөйләде. Аннан соң без алдан билгеләнгән вакыт буенча аның туган ягы – Биектау районының Дөбьяз авылында очраштык. Һәм ул үзенең умарталыгында төрле зурлыктагы кулдан ясалган берничә җәя күрсәтте. Карама агачыннан бөгеп ясалган җәя, аңа умарта кәрәзе рамына чорный торган металл кыл тарттырылган. «Өлкәннәр аны болай уйныйлар иде», – дип, бер аягы белән җиргә тезләнде һәм уң кулның имән бармагы белән кылларга сугып, төрле ритмнар уйнап күрсәтте. Икенчесе кечерәк итеп эшләнелгән, шундый ук металл кыл тарттырылган. Кече җәяне уйнаганда, аның бер башын сул кул белән тоталар, икенче башын (агач өлешен), авызга куеп, тешләргә териләр. Һәм авыз куышлыгы ярдәмендә эчтән генә көйләп, нәкъ тимер-кубыз кебек уйныйлар. Ә уң кулның имән бармагы белән кылга

йомшак кына сугарга кирәк. «Бу уен коралын безнең якта «җәя-кубыз» дип тә, «кыл-кубыз» дип тә йөртәләр», – дип, үзе белгәннәрне сөйләде Нигъмәтҗан ага.

1984 елда Дөбьяз авылында Фәрит Барыев оештырган кыл-кубызларда уйнаучы ун кешелек кызлар ансамбле дә бар иде.

Казанга кайткач та без бу уен коралын сәхнәдә уйнарлык итеп ясатып алдык. Шул вакыттан бирле җәя-кубыз Сорнай ансамбленең алыштыргысыз бер уен коралы булып тора. Аның бер башына, тавышны көчәйтү өчен, акустик җайланма куелган. Идәнгә куйгач таеп китмәсен өчен, кыл-кубызның бер башына очлы кадак беркетелә. Шул ук кадакка кылның бер башын бәйлибез, ә икенче башы, алдан беркетелгән гитара боргычы ярдәмендә, җәянең икенче башына борып тарттырыла. Кылы 0,8 мм. калынлыкта капрон леска.

Бер генә кыллы әлеге җәя-кубыз карап торышка гади генә кебек. Әмма, уйный башлагач, аның үзенә генә хас мөмкинлекләре зур икәне ачыла. Аны уйнаган саен уйныйсы гына килеп тора.

Уйнау өчен иң элек кылны билгеле бер тавыш югарылыгына көйлибез. Үзеңә җайлы итеп, уң аяк белән идәнгә тезләнәбез. Җәянең бер башы идәнгә терәлгән. Сул кул белән җәя-кубызны өске башыннан тотабыз, ә уң кулның имән бармагы белән ике яктан да кылга сугып уйныйбыз. Башкара торган көйгә карап, сул кулның имән һәм урта бармаклары белән кылны сүндереп алырга һәм шул ук вакытта, җәяне аз гына басып, тавыш югарылыгын үзгәртеп була. Катырак баскан саен, тавыш түбәнәя бара.

Тагын бер уен алымын әйтеп китәм. Шундый ук тәртиптә утырабыз. Як-якка селкенмәсен өчен, сул кулның терсәге белән җәянең кәүсәсен билгә терәп кысабыз. Сул кулның имән һәм баш бармаклары белән кылны кысып тотарга һәм акрын гына кыл буйлап аска-өскә күчереп йөртергә була. Шул ук вакытта уң кул белән кылга сугып, төрле ритмнар уйныйбыз.

Җәя-кубызда шулай ук скрипканың сызгычы (смычок) ярдәмендә сызып та уйнарга мөмкин. Сызгычны ук рәвешендә үзгәртеп ясасаң, фольклор ансамбльләре өчен тагын да үтемлерәк була. ■

Сулдан уңга: Илдар Мәҗитов, Рәшит Ваһапов, Салих Сәйдәшев, Әсма Шәйморатова һәм Фәйзи Биккенин. 1949 ел

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

ИКЕНЧЕ 10 ЕЛЛЫК
(1947-1957 ЕЛЛАР)

Вакыйгалар:

▪ **1940-1950** нче еллар – җырчы Рәшит Ваһаповның сокланырлык популярлык казанган еллары.

▪ **1949** ел – күренекле музыкант Рокыя Ибраһимова филармониядә эшли башлый.

▪ **1950** нче еллар уртасы – филармониянең эстрада бүлегендә Олег Лундстрем җитәкчелегендәге джаз оркестры эшли башлый.

▪ **1950** нче еллар азагы – тамашачыларның классика һәм халык җырлары белән кызыксынуы арта. Филармония әзерләгән концерт-лекцияләрдә булган тамашачыларның саны меңнәр белән исәпләнә. Профессиональ музыка барлык уку йортлары укучыларын, студентларын үзенә тарта. Классик һәм халык музыкасы белән көчле мавыгу 15 ел дәвам итә.

▪ **1947-1950** нче еллар – филармония артистлары Мәскәүнең Колонналар залында, Урал, Удмуртия, Себер, Каспий буе, Урта Азия, Пермь өлкәсе шәһәрләрендә чыгышлар ясый.

▪ **1950** нче еллар – Әзәл Яһүдин филармониягә эшкә килә.

▪ **1952** елның көзе – филармония составындагы Җыр һәм бию ансамбленең балетмейстеры итеп татар бию сәнгатенең классигы Гай Таһиров билгеләнә.

▪ **1955** ел – Әлфия Авзалова филармониядә Гани Вәлиев җитәкләгән бригадада эшли башлый.

▪ **1958** ел – атаклы балетмейстер Әхмәт Кәлимуллин ансамбльгә эшкә килә.

▪ **1957** ел, май-июнь – филармония артистлары Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша.

▪ **1957** елның июле – Җыр һәм бию ансамбленең биючеләре, Алтынчы бөтендөнья яшьләр фестивалендә катнашып, II дәрәҗә дипломга һәм көмеш медальгә лаек була.

Сулдан уңга (беренче рәттә): Мохтар Әхмәдиев, Фәйзи Йосыпов, Разия Тимерханова, Ф.Маннапов, икенче рәттә: Әлфия Авзалова, Петр Загудаев, Гамилә Рәхимкулова, (...). 1953 ел

Урта Азиядә гастрольләр вакытында (сулдан): Р.Ваһапов (икенче), Ә.Яһудин (өченче). 1950 нче еллар

1937-1961 ЕЛЛАРДА ЭШЛӘГӘН ДИРЕКТОРЛАР:

Л.А.Галиев (20.07.1937 – 31. 03.1938);
И.М.Колесов (01.06.1938 – 11.07.1938);
А.Г.Садриев (10.11.1938 – 09.03.1939);
Б.Н.Абдуллин (13.03.1939 – 24.08.1941);
З.С.Әхмәтова (24.08.1941 – 02.10.1944);
Җ.Х.Фәйзи (12.10.1944 – 12.06.1946);
Б.Н.Абдуллин (04.07.1946 – 22.10.1946);
Җ.Х.Фәйзи (25.10.1946 – 12.02.1947);
А.Юрусов (25.03.1947 – 25.07.1947);
М.М.Хессин (29.07.1947 – 29.11.1947);
К.Гайсин (23.11.1948 – 12.07.1951);
Н.Г.Бадамшин (12.07.1951 – 18.11.1952);
М.Ф.Боголюбов (19.11.1952 – 20.10.1961).

1937-1964 ЕЛЛАРДА ЭШЛӘГӘН СӘНГАТЬ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ:

А.М.Райский (15.10.1937 – 21.10.1938);
И.М.Колесов (10.11.1938 – 05.05.1939);
А.С.Ключарев (22.11.1939 – 1946);
Җ.Г.Садрижиһанов (16.08.1946 – 15.07.1949);
Ә.Х.Хәбибуллин (15.07.1949 – 04.08.1950);
А.Г.Яковлев (04.08.1950 – 21.09.1950);
А.С.Ключарев (21.09.1950 – 21.07.1952);
Н.З.Степанов (21.07.1952 – 12.01.1953);
А.М.Исмәгыйлев (01.02.1953 – 09.04.1953);
Җ.Х.Фәйзи (09.04.1953 – 02.01.1959);
Р.К.Волкова (02.01.1959 – 17.10.1964).

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2020

МАНКОРТ

Рәис Сәфәров

Бу сүз татар теленә (әйтергә кирәк, фәкать татар теленә генә, бәлки, соңрак бездән башкорт теленә дә күчкәндер) атаклы язучы Чыңгыз Айтматовның 1981 елда урыс телендә нәшер ителгән «Буранный полустанок» («Гасырга тиң бер көн») романындагы бер образның кушаматы буларак килеп керә һәм, тора-бара, аерым мәгънәгә ия мөстәкыйль төшенчә сыйфатында йөри башлый.

Әсәрдә шундый риваять китерелә. Борынгы заманнарда казакъ далаларындагы Сарыкүл төбәген җуан-җуан дип аталган күчмә кабилә явы басып ала. Алар әсир алынган казакъларга карата мәрхәмәтсез булалар, өлкәнрәкләрен коллыкка саталар, ә яшьләрен, үз яннарында калдырып, иң авыр эшләрдә файдаланалар. Әлеге яшь коллар үзенең хуҗасыннан тыш башка беркемне дә белмәскә-танымаска, хуҗа нәрсә боерса – шуны берсүзсез үтәргә тиеш булганнар. Алар, үзләренең кешелек сыйфатларын югалтып, мөстәкыйль рәвештә фикерләү, нечкә хис-тойгылар кичерү сәләтеннән мәхрүм калганнар. Гади генә итеп әйтсәк, һәр боерыкны сукырларча үтәүче хайвани затларга әверелгәннәр.

Хуҗалар моңа ничек ирешкәннәр соң? Роман авторы **Чыңгыз Айтматов** әлеге хәлне болай бәян итә: *«Аны сүзсез хайван шикелле итү өчен, җуан-җуаннар менә шундый экзекуция – тән җәзасын башкаралар: башта яшь-җилкенчәк колның чәчен үткен пәке белән кырып, башын шоп-шома итәләр, шуннан соң тәҗрибәле кассаб, ягъни мал суючы җуан-җуан, якын тирәдәге утлап йөргән дөяләрдән иң картын сайлап алып, егып суя. Дөяне тунаганда аның муен тиресеннән иң калын җирен ала, аны, суынмас борын, җылы килеш тиз генә әлеге яшь колның такыр башына каплый һәм, су коенганда кия торган хәзерге резин башлык шикелле итеп, бик ныклап тарттырып кидертеп куя. Бермәл әлеге башлык колның башын чыдап булмаслык итеп кыса-җыера башлый... Бу экзекуция җуан-җуаннарда «шири кидерү» дип атала. Мондый хәлдән соң кол, авыр газапка – авыртуга чыдый алмыйча йә җан бирә, йә, исән калып, гомерлеккә акылын, зиһенен югалткан, үзенең үткән тормышын, якыннарын хәтерләми торган колга – МАНКОРТка әверелә. Ул инде үзенең кайдан, кайсы нәсел-ыругтан икәнен дә, үзенең исемен дә, балачагын да оныта, ата-анасының кем икәнен дә, төс-битен дә исеннән чыгара. Кол инде бүтән үзен адәми зат итеп тоя алмый. Ул инде җәзалар нәтиҗәсендә хайван дәрәҗәсенә китерелгән, телсез, сүзсез калган мәхлук җан иясенә әйләнә».*

Риваятьнең ахыры фаҗига белән тәмамлана. Нәйман Ананың иң кадерле төпчек улы Җомалан, ил-йортын саклап, җуан-җуаннарга каршы сугышта катнаша һәм яу кырында хәбәрсез югала. Хәсрәткә баткан Нәйман Ана аны эзләп чыга. Бик күп җәфа-михнәтләр чигеп, озын юллар үтә Нәйман Ана. Ниһаять, ул аны җир читендәге бер



далада дөяләр көтеп йөргән хәлдә таба. Ана, хисләрен тыя алмыча, елый-елый улына таба йөгерә, кочагын җәеп аңа ташлана. Нинди шатлык! Нинди бәхет! Әмма аның манкортка әверелгән газиз улы үз анасын танымый. Җуан-җуаннар аның баш миенә фәкать бер генә боерык салып калдырганнар: дөяләрне сакларга, көтүгә якын килүчеләрне юк итәргә. Егеткә анасы дөя урларга килгән угры булып күренә һәм ул аны үтереп ташлый.

Җомаланның ничек манкортка әверелүе дә, «манкорт» сүзенең ачы мәгънәсе дә ачыкланды кебек, роман авторының нәрсә, ни әйтергә теләвенә дә төшендек бугай.

Ә менә «манкорт» сүзен лексик йә этимологик яктан тикшереп карасак, ни гаҗәп, бу сүз төрки телләрнең берсендә дә юк икән! Каян килеп чыккан соң бу атама? Каян тапкан аны Чыңгыз Айтматов? Бу хакта миңа Айтматовның үз авызыннан ишетергә насыйп булды.

1982 елда Мәскәүгә командировкага баргач, буш вакыт табып, Переделкинода ял итүче туганнан-туган абыем, татар булса да, танылган башкорт әдибе дип саналган Гайнан Әмиринең хәлен белергә кагылган идем. Бераз утырып хәл-әхвәл сорашкач, кичкырын ул: «Әйдә, Рәис, үзеңне бер өйгә алып барам, анда һәр атнаның җомгасында таныш-белеш язучылар, шагыйрьләр, үзара җыелып, әңгәмә уздырабыз», – диде.

Без килеп кергәндә, бер мөлаем йөзле кеше нәрсәдер сөйләп тора иде. Абый колагыма пышылдады: «Чыңгыз Айтматов!» Газета-журнал, китап битләрендә рәсемен күргәнем булганга, мин аны шунда ук таныдым. Калын гына гәүдәле, чалара башлаган куе чәчле берәү (абый тагын колагыма: «Евгений Долматовский», – дип пышылдады) әдипкә шундый сорау бирде:

– Чыңгыз, каян казып чыгардың син манкортны? Мин күп халыкларның риваятьләрен беләм, ә менә мондыен укыганым да, ишеткәнем дә юк иде әле.

Мин үзем Айтматовның ул чакта бик шаулаган «Гасырга тиң бер көн» романын яңа гына укып чыккан идем, шуңа күрә аның бу сорауга җавабын колак торгызып көттем. Ул елмаеп куйды, бераз уйланып торды да болай диде:

– Дөрес сорыйсыз, Евгений Аронович, мондый риваять юк иде, мин аны романны

язу барышында үзем уйлап чыгардым, дөресрәге, моңа шул чакта күргән бер кинокадр этәргеч бирде. Бу турында соңыннан. Ә инде риваятькә килгәндә, бу жанр миңа бик ошый, әсәрләремдә аны еш файдаланам, чөнки бу миңа, язучы буларак, үз фикеремне әйтергә иркенлек бирә, әсәрне җанландыра, укучыга мәгънәне тирәнрәк, аңлаешлырак итеп җиткерергә булыша. Минем әсәрләрнең барсында да диярлек риваятькә урын бирелә. Мәсәлән, моннан берникадәр алданрак язылган «Пегий пес, бегущий по краю моря» дигән әсәрем тулысынча риваятькә нигезләнгән.

– Ә шулай да, «Буранный полустанок»тагы МАНКОРТ образы риваятькә охшамаган, ул әкияткә тартымрак, укучыны ышандырмый, моны ничек аңларга? Аннары ул уңай образмы, тискәреме? – дип бәйләнде Долматовский.

– Мин образларны менә монсы уңай, ә менә монсы тискәре дигән категорияләргә, кара белән акка бүлү ягында түгел, мондый бүленеш укучыга уйланырга, фикер йөртергә мөмкинлек бирми, әсәрнең дәрәҗәсен төшерә, стереотипка әйләндерә, оргинальлегенә зыян китерә. Образ – образ инде ул, автор аны үзенчә ничек бирсә, сурәтләсә – укучы да аны шулай үзенчә кабул итәдер дип уйлыйм. Ә Җомалан-манкортның үзенә килсәк, ул риваятьтән түгел, чынбарлыктан, тормыштан алынган.

– Тормышта мондый хәлнең булуы мөмкин түгел! – дип каршы төште арадан берәү.

– Мөмкин, – диде Чыңгыз. – Монда утыручыларның, ышанам, моны үз күзләре белән күргәннәре дә бардыр. Немецлардан трофей итеп алынган бер документаль-хроникаль фильмда берничә секундлык кына җан тетрәткеч бер мизгел бар: коры сөяккә калган карт чырайлы бичара бер яшь кенә әсир, җиргә чүгәләп, кабалана-кабалана, хайваннарча умырып, тузан эчендәге үләнне ашый. Фашист табип-галимнәре бик тә канәгать булып, елмаеп күзәтеп торалар. Фәнни сынау, димәк, уңышлы бара, көткән нәтиҗәләрне бирә. Димәк, кеше өстеннән төрле тәҗрибәләр үткәреп, аерым препаратлар, физик һәм психик көч кулланып, акылын, хәтерен юып була. Аны эт шикелле өйрәтелгән, буйсынучан, хуҗасы кушкан боерыкны үтәүдән башканы белми торган хайвани зат дәрәҗәсенә төшерергә мөмкин. Мондый акылын югалткан әсирләрне, үзләрен дә һәлакәткә китерәчәк диверсия, террор актлары башкаруда кулланып була. Япон камикадзелары үз ватаны өчен үзләрен аңлы рәвештә корбан итсәләр, болар исә моны бөтенләй аңсыз рәвештә башкарачаклар. Менә каян ясалды минем манкорт – әнә шул берничә секундлы кадрдан. Калганы – язучы хыялы, аңа чик куеп булмый.

Ә менә манкорт сүзе каян килеп чыкты, дисәгез, бу да минем иҗатым, – дип дәвам итте Ч.Айтматов. – Аңлатам: фашист-немец табиб-галимнәре мондый тәҗрибә өчен сайлап алынган яшь әсирләрне КУРТМАН диләр. Ул сүз якынча «тәҗрибә үткәрү өчен» (тәҗрибәгә дучар ителгән хайван) дигән мәгънәне аңлата. Төрки телләрдә дә МАНКОРТка охшаш һәм мәгънә ягыннан якын МАКУМ дигән сүз бар, ул «обреченный» (үлемгә дучар ителгән) сүзенә туры килә. Мин немецча «КУРТМАН» сүзендәге иҗекләрнең урыннарын алмаштырдым да, төркичәгә охшаш яңгыравыклы МАНКОРТ атамасы ясадым.

Минем Манкорт-Җомалан – трагик образ. Үз анаңны үтерүдән дә зуррак җинаять юк, моны эшләгән кеше иң каты җәзага хөкем ителергә тиеш. Ләкин без Җомаланны гаепле алабызмы соң? Юк. Чөнки анасын үтерүче Җомалан түгел, ә аның хуҗасы – баскынчы, илбасар Җуан-җуан, ул аны акылыннан яздырган, аның аркасында ул шул хәлгә төшкән. Без МАНКОРТНЫ кызганабыз-җәллибез, аның фаҗигасенә ачынабыз. Ул анасын үтерүче җинаятьче дә, бер үк вакытта бичара корбан да.

Менә шуларны сөйләде ул кичне безгә Чыңгыз Айтматов.

Текстны журналга, «Тел күрке – сүз» тапшыруында яңгыраган чыгышка нигезләнеп,
***Рөстәм Акъегет** әзерләде.* ■

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Каза бәрабәренә ахирәттә савап каршы алачак. Шушы эшләрне фикерләүче адәм кайгыга түзәр. Кайгы юк урынга тоташырга бердәнбер булган сәбәп – дөньядагы кайгыларга түзү вә сабыр итүдер.

● Изгелеккә өйрәтү, телдән бигрәк, фигыль белән булу лязим. Гамәле усаллыкка өйрәтүче адәмнең теле яхшылык өйрәтүендә файда булмас.

● Бурычка алмау лязим. Инде мәҗбүр булып алгансыз икән, рәнҗетми тапшырырга тиешле. Фәкыйрь булу сәбәпле бурычны вакытында түли алмау золым түгел.

● Мөселман карендәшкә хыянәт кылу, алдау, ярдәмсез ташлау кебек нәрсәләрнең һәрбере ахирәттә зарар бирә торган нәрсәләрдәндер.

● Ислам диненең рухы карендәшлек вә мәхәббәттән гыйбарәт.

● Бездә хакыйкый галимнәр, тәкъва вә тәрбияле адәмнәр аз. Әгәр дә ислам дөньясында хакыйкый галимнәр вә дөрес тәрбияле кешеләр җитәрлек булса, алдаучылык вә зарар итүчелек, хәйлә вә мәкер коручылык, иман вә көферлек турында үлчәүсез сүз сөйләүләр ошбу дәрәҗәдә мул булмас иде.

● Ислам динендә берәүгә зарар итү, кешенең йөз суын түгү, аның турында начар уй уйлау катгый тыелган. Безнең хәлебез гаҗәп итәрлек: гомеребез буена дус булып йөргән кешеләребездән аз гына салкынлык күрү белән, мөнәсәбәтебезне кисәбез, намусына тиеп рәнҗетәбез вә кулыбыздан килгән кадәр аны кимсетәбез.

● Тәкъвалык күңелдә буладыр. Тышкы ягына карап, кеше хакында хөкем итәргә ярамый.

● Безнең үз арабызда дуслык дигән нәрсә бармы? Хакыйкый дуслык – шикаять итмәү, зарланмау вә һәртөрле мөгамәләгә риза булып торудыр. Дуслык булса, аннан зарлану булмас, зарлану булса, дуслык булмас. ■

Көлке куа килә...

Сәгыйть Рәмиев

Думада татар депутаты җырлый

Мәңгәрләрнең өе зәңгәр,
Без дә шулай буятыйк.
Депутатлык ике килмәс,
Уйнап күңел җуатыйк.

Йөзә үрдәк, йөгрә каз,
Боты озынга күрә,
Бу Думаны без сөябез
Гомре озынга күрә.

Галиәсгар Камал

«Зәңгәр»ләр[1]

(Эпиграмма)

Зәңгәр күлмәк зәңгәре,
Үтә күренә тәннәре:
Тинчуринга бик ошаган
«Зәңгәр шәл»нең тәмнәре!

Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр,
Без дә шулай буятыйк:
«Зәңгәр шәл»дән төшем яхшы –
Әйдә, тагын уйнатыйк!

Кәрим «зәңгәр»не ярата,
«Зәңгәр» куяр баласын;
Тик нигәдер бу ел куймый
Әле «Зәңгәр палас»ын[2].

Тинчуринга язарга
Тагы «зәңгәр»ләр бик күп:
Зәңгәр күз бар, зәңгәр күл бар,
Зәңгәр чәчәк, зәңгәр күк!

– Кара әле, син, ни кылуың инде бу? Сине ярмаркада яңадан дүртенче хатын алган, диләр. Дөрес сүзме ул?

– Бер дә хафаланмагыз! Моннан соң бишенчене алмам инде.

(«Ялт-йолт» журналыннан.
Рәйсә Шәрәфиева тәкъдим итте.)

---

[1]Бу эпиграмма «Каләм» имзасы белән «Чаян» журналында 1927 елның 4 нче (апрель) санында басылган. Эпиграмманың Г.Камалныкы икәнлеген ул вакытта «Чаян» журналының җаваплы редакторы булган Г.Толымбай күрсәтә. Ул «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы (№6, июнь) санындагы «Комедия атасы Г.Камал» исемле мәкаләсендә эпиграмманың өченче строфасын китереп, Г.Камалның Кәрим Тинчурин иҗатындагы кайбер тенденцияләрне ошатып бетермәвен һәм «Чаян»да аңа эпиграмма язып бастырганлыгын әйтә.

[2] «Зәңгәр палас» – К.Тинчуринның 1924 елда язылган пьесасы.

Хәсән Туфан. Б.Урманче рәсеме

Туфан җыры[3]

«Ант», дидем мин, «Ант», дидем,
«Ант»ны бар да көттеләр,
Җиде ел буе төзедем,
Җиде елда сүттеләр.

Тмин (Туфан Миңнуллин)

Хикмәтле котлаулар

***

Туфан Миңнуллин. Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Бурсык авылында яшәүче алдынгы карашлы, берничә буын яшь буынны тәрбияләгән укытучы, яраткан бабаебыз Колсәетов Гыйбадулла Коләхмәт улына 80 яшь тула. Кадерле бабаебыз, Сине олы юбилеең белән котлыйбыз. Киләчәктә дә үрнәк татар гаиләсенең куанычы булып яшә!

Улың Фердинант, киленең Гертруда, оныкларың Эрик, Варвара, Лимузин.

***

Любимуй внучик Рубчик! Жилаем тибя агромного ысчастия. Мы надиемся, что ты будиш дастуйным прадалжателем нашиго замичатилново рода.

Твоя любимая дедушка Солимгарей и бабушка Хуббуниса.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан алынды.)

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

---

[3] Бу эпиграмма-шаяру «Чаян» журналында 1936 елның май ае (№8) санында басылган. «Ант» дигәндә, биредә Хәсән Туфанның шул елларда (1935) «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән поэмасы күз алдында тотыла. Әлеге эпиграмманың авторы мәгълүм түгел.
«Шагыйрь Туфан ике сәгать буенча шигырь сөйләде һәм залда утыручыларга туп-туры карап, сез минем шигыремә дә, минем «Ант»ыма да ышанмагыз, бары минем йөрәгемә генә ышаныгыз, диде. Һәм, соңгы сүзе итеп, мондый декламация сөйләде: «А... ул минем йөрәгем... Ул әле язның җилкәсен байтак шрапнельләп йөрер!»
(Бу өзек-шаяру «Миндә бер гаеп тә юк» дигән язмадан алынды. Язма авторы Кош псевдонимы белән бирелгән. «Чаян», 1936 ел, № 8.)

ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Гыйнвар башында Югары Ослан мөхтәсибәтенең Аксакаллар шурасы рәисе, Кызыл Байрак авылы имамы Тимур хәзрәт Ибраһимов, Татарстан Республикасының җәмәгать эшлекләләре берлегенең йомгаклау утырышында катнашып, әлеге иҗтимагый оешманың һәм Татарстан Спорт министрлыгының Мактау грамотасына лаек булды.

● 13 гыйнварда Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары имам-мөхтәсибенең урынбасары, «Ярдәм» мәчете имамы Хәбир хәзрәт Ханов Милли гвардия гаскәрләренең 5561 нче хәрби частенда кышкы әзерлек чоры ачылышында катнашты.

● 14 гыйнварда язучылар Ә.Хәсәнов, Л.Лерон, М.Закир, Р.Сафин һәм Әсхәт хәзрәт Җиһаншин Вознесение бистәсендә яшәүче милләттәшебез Римир Сәлимгәрәев өендә танылган шагыйрь Госман Садәне искә алды.

● 15 гыйнварда Мамадыш районында күренекле язучы Шәйхи Маннурның тууына 115 ел тулу уңаеннан чаралар булып узды. Мәдәният йортында узган тантанада язучылар Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Рәдиф Сәгъди һәм Рәкит Әбделмәновка Ш.Маннур исемендәге премия тапшырылды.

● 16 гыйнварда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе хезмәткәрләре, язучылар, сәнгать һәм дин әһелләре Яңа бистә татар зиратында Илһам Шакировның каберен зиярәт кылды.

● 16 гыйнварда Арча районының Яңасала авылында ТАССРның халык язучысы Гомәр Бәширов туган нигездә «Әдәби бакча» һәм истәлек тактасы ачылды. Чарада ТР Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллин, Арча районы хакимияте башлыгы Илшат Нуриев, язучылар, журналистлар һәм Яңасала халкы катнашты.

● 16 гыйнварда Казан Кремлендә ТАССР төзелүнең 100 еллыгы әләмен күтәрү тантанасы булып узды. Әлеге чараны ТР Президенты аппараты җитәкчесе Ә.Сәфәров ачты.

● 16 гыйнварда бер төркем зыялылар, Ш.Мәрҗани мәчетенә җыйналып, мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировны искә алды.

● 17 гыйнварда «ТАТМЕДИА» бинасында, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевнең «Мин шулай күрәм» дигән китап-альбомы басылып чыгу уңаеннан, авторның «Бабамның борынгы бишеге – Алтай» дип исемләнгән фотокүргәзмәсе ачылды. Чарада «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Ш.Садыйков, әдипләр, сәнгать әһелләре, сәясәтчеләр, журналистлар һәм фотографлар, аерым алганда, Р.Вәлиев, Р.Батулла, Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Д.Салихов, Ф.Сафиуллин, Л.Лерон, В.Нуриев, Г.Морат, Р.Аймәт, Ш.Җиһангирова, А.Хәмзин, Ф.Сәлахов, А.Гафиятов, Р.Галиев һ.б. катнашты.

● 17 гыйнварда Нью-Йоркның Карнеги-холл концерт залында «Үзгәреш җиле» татар җыры фестивале булып узды. Чарада ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, җырчылар Алинә Шәрипҗанова, Айдар Сөйләйманов, Эльза һәм Артур Исламовлар, Илнар Миранов, Гөлнара Гатина, Илгиз Шәйхразиев, баянчы Айдар Гайнуллин (Германия) һәм башкалар катнашты.

● 17 гыйнварда Баулы районында туган тел һәм әдәбият укытучыларының төбәкара семинар-киңәшмәсе үтте. ТАССР оешуга 100 ел тулу кысаларында узган әлеге чарага Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Мөслим, Сарман, Ютазы һәм Лениногорск районнарыннан мөгаллимнәр җыелды.

● 20 гыйнварда «Өч авыллы Икшермә» китабы басылып чыкты. Әлеге саллы хезмәтнең төзүче-авторы – язучы Гөлүсә Закирова. ■



Мирасворд

Байлык, ризык, мал (иск.)

Гаяз Исхакый повесте

Тропик куак

Очкыч

Кирәкле, тиешле (иск.)

... елан

Жанна д'...

Җәләлет-дин ... (урта гасыр фарсы шагыйре)

Әрмәнстанның борынгы башкаласы

Татар халык әкияте

Горурлык, масаю, әрелек (иск.)

Хәким Хәйруллин романы

... Арагон

Аквариум балыгы

Алтын (иск.)

Игътибар, әһәмият (иск.)

Язучы Рәфкать ...

Дагыстан халкы

XX йөз француз фәлсәфәчесе

Уганда мәркәзе

Кәҗә бәтие (диал.)

Бәрәңге төбенә өю (диал.)

Үзәнлек (диал.)

Ташкүмер калдыгы

Шагыйрь ... Идиятуллин

Эшнең алга баруы, үрчүе (диал.)

«... таңнары» романы (Якуб Зәнкиев)

Ныгытма, вал (иск.)

Әмирхан Еникинең һөнәре

Җиңү авазы

Өйдә түшәм белән түбә арасындагы урын

Элек крестьяннардан алынган салым

Йошкар-...

Рәссам ... Гог

Габдулла Тукайның 1912 елда язган шигыре

Агач йорт каркасы

Идел буе Болгарындагы шәһәр

Язучы ... Хафизова

Төркиядәге тау

Коры елга

Һинд халык уен коралы

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: «Бичура», аш, Бату, Тажи, бриг, Колый, «Сынау», Арей, чам, чыт, тума, «Аргамак», ачу, ирү, Утыз, кып, кем, Сәгыйди, Аид, аноа, өйлә, син, отыры, Зәки.

Өстән аска: биана, өяз, ырай, Исергәп, илек, Бәдигый, дә, Амик, чабагач, Арес, ушат, уа, күмә, Габон, Ахунов, урын, чуат, Йосыф, ырымчы, даир, Тауз, нык.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

«Безнең мирас» елъязмасы /февраль

660 ел элек (1360)

Шәйбанилар ыруы (Шәйбан – Бату ханның энесе) Себер ханлыгына нигез сала. Ханлыкның башкаласы Чыңгыз-Тура (хәзерге Төмән) була.

490 ел элек (1530)

Захиреддин Мөхәммәт Бабур (1483-1530) – Бөек Магул империясенә нигез салучы, «Бабурнамә» исемле мәшһүр истәлекләр мәҗмугасының авторы – вафат була.

145 ел элек (1875)

Хәрби адвокат, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Шаһхәйдәр улы Сыртланов (1875-1912) дөньяга килә.

125 ел элек (1895)

Казанда «Комедия – Чистайда!» дип аталган беренче татар комедиясе сәхнәгә куела.

110 ел элек (1910)

Баку каласында «Шиһаб сакыйк» (Көйдергеч кисәү) дип аталган рәсемле көлке-сатира журналы чыга башлый.

90 ел элек (1930)

Һади Такташ «Камил» исемле кинокартина либреттосын язып бетерә.

75 ел элек (1945)

19 февральдә Бөек Ватан сугышы фронтында, Көнчыгыш Пруссия җирендәге хәлиткеч биеклекне яулаганда күренекле шагыйрь вә яугир Фатих Кәрим (1909-1945) каһарманнарча һәлак була.

60 ел элек (1960)

«Совет әдәбияты» журналының икенче санында галим Җәвад Алмазның «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны» исемле мәшһүр мәкаләсе дөнья күрә.

50 ел элек (1970)

1 февральдә «Социалистик Татарстан» газетасында Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» исемле яңа романыннан өзекләр басыла башлый.

10 ел элек (2010)

26-27 февральдә Пермь өлкәсенең Барда районында галим, мөгаллим, шагыйрь вә күренекле җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәров истәлегенә багышланган «Ягъфәров укулары» булып узды.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

СОДЕРЖАНИЕ. ФЕВРАЛЬ 2020

И останется в мире слово моё...: Сагит Рамиев.
Историческое наследие: «Этруски – римские умельцы». С.Шамси; «История Гуляйзы». Г.Хисамиев; «Стамбульские воспоминания». М.Рахмат Паташева; «Газета «Тәтеш оешмасы». («Тютешская организация»). Р.Шарафиева, Л.Губайдуллин.
Татарский мир: «Судьбы, связанные с музыкой». М.Гараев.
Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.
Литературное наследие: «Татарская книга в эмиграции». Х.Миннегулов.
В глубине памяти: «Народный Ильгам». Г.Рахим; «Мои первые учителя». И.Тагиров; «Отец». А.Шакиров; «В памяти, до сих пор в памяти!»; «Самолёт ПО-2 в национальном музее».
Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязов; «Татарская государственная филармония в 100-летней истории ТАССР». З.Гильметдинова.
Слово – украшение языка: «Манкурт». Р.Сафаров; «Изречения Ризаэддина Фахруддина».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. FEBRUARY 2020

There will be left my word in the world...: Sagit Ramiev.
Historic heritage: «The Etruscans are the Roman craftsmen» by S.Shamsi; «Gulyaza's legend» by G.Khisamiev; «The Istanbulian memoirs» by M.Rakhmat Patasheva; «Tetyush society» newspaper» by R.Sharafieva, L.Gubaydullin.
Tatar world: «The fates created by music» by M.Garaev.
Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.
Literary heritage: «The Tatar book is in the emigration» by Kh.Minnegulov.
From the deepest store of memory: «Ilgam for our folk» by G.Rakhim; «My first educators» by I.Tagirov; «Father» by A.Shakirov; «Still keeping in the memory, still keeping!»; «The airplane Po-2 is the National museum».
Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazov; «The Tatar state philharmonic is in the 100 aged history of TASSR» by Z.Gilmetdinova.
The word is the language's decoration: «Mankurt» by R.Safarov; «The aphorisms of Rizaeddin Fakhreddin».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

Еракка китеп кара...

ИКЕ КАЗАН

Яшерен манара – Кремльнең төньяк капкасы

Яшерен манара. Хәзерге күренеш

А Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынды

Болгар. Кече манара

М.Дмитриев (Түбән Новгород) фотосы. 1894 ел

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.